PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

№ 2 / 2022

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ир-атларны сыйлыйбыз ИТ РУЛЕТЫ

айның икенче ягы БЕЗ ҺӘМ СТРЕСС

ТАПШЫРЫЛМАГАН *хатлар* юлы саен – сагыш

Светлана ЯНТУГАНОВА:

«Яхшылыкның бер-беребезгә күчүен телим!»

PRESSA

Әниемнең туй күлмәге...



Әниемнең туй күлмәге...
Сезнең гаиләнең матур
бер ядкаре.
Кадерле кешегезнең
яшьлегеннән бер кайтаваз.
Аның иң бәхетле бер көненең
шаһиты.
Сакланамы ул сездә?
Аны кулга алгач, йөзе балкып
киткән әниегез нәрсәләр искә
төшерә, нинди истәлекләр
сөйли?
Бездә яңа проект: әниегезнең
туй күлмәген киеп көзге
алдында бөтерелгән
мизгелне сурәтләгән
фотосурәтләрегезне көтәбез.
(«Минем кыз чагым син,
кызым!» – дип әйтәдер
әниегез сезгә карап.
Яратып, сөенеп, аз гына
моңсуланып...)
Тагын – аларның туй көненнән
бер мизгел дә көтәбез!

– Яшьлекнең иң кадерле истәлеге бит ул, кызым! – ди әни. – Сатам дигән уй башыма да килмәде. Минем яшьтәшләр һәркайсы диярлек туй күлмәген саклый. Аклык, пакьлек, гаилә кыйммәтләренең гомерле булуына ышану чоры иде ул.

...Әни күбәләк булгандыр ул көнне. Әти – бөркет. Икесе дә матур. Никтер менә аларны күз алдыма китергәч, «Ак майларда ак вәгъдәләр» җыры исемә төшә.

Уртак тормышларын ак майларда башламасалар да, вәгъдәләре ак булгандыр.

Булган, булган, шигем юк!

...Күлмәкне киеп, көзге каршында бөтерелгәндә, әни:

– Безнең яшьлек, безнең дәвам сездә инде, – диде.

Газизләребезнең яшьлеген без кабатлыйбыз!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА.
Кайбыч районы, Кошман авылы.

Фото: Анна Арахамия.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2022



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова, Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева, Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова, Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Алсу Шакирова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррире
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Светлана Янтуганова
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Виталий Матвеев

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 1.02.2022 ел.
Чыгу көне: 8.02.2022 ел.
Заказ О-0308
Тираж 10333

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+





Фото: Анна Арахамия

Кадыйр СИБГАТУЛЛИН

Карлар

Көтмәгәндә
(әллә көткәндәме?)
бер болытсыз ява карларым.
Дөньяларга бүген тагын бер кат
ап-ак карлар аша карадым.
Рәхмәт әйттем мин күкләргә карап,
рәхмәт әйттем ап-ак карларга.
Мин кулымны куйдым тагын бер кат
«Яшәү матур!» дигән карарга.
Кемнәргәдер, бәлки, гади кардыр,
минем өчен гади кар түгел.
Яусын әйдә сезнең иңнәргә дә,
минем күңел алай тар түгел.
Кар яуганын бик күп күргәнем бар,
көткәнем бар карлар яуганны.
Бу тормышта минем иңнәремә
чиста карлар гына яумады.
Барысын да юды шушы карлар,
пычрак тормый минем өстемдә.
Рәхмәт сезгә
яуган өчен
миңа
шатлык, юанулар китереп.
Кар бөртеге очып йөри күктә,
безне уйлы-моңлы иттереп.
Бик сөенеп күккә карап торам:
рухым бүген түгел ялангач;
бу дөньяның шушы карлары да
куандырып мине ява алгач!

Безнең тышлыкта

«Мин Яшел Үзәндә үземнең фикердәшләремне таптым. Алар – шәһәребезнең тынгысыз, янып торган егет-кызлары.»



10

«Янарга икән – янарга, Янарга азаккача!»
Эльмира Закирова

14



«Туган җанлы булсыннар иде»
Чулпан Галиәхмәтова

16



Айның икенче ягы
Гөлнур Сафиуллина

20



Берсе – ут... Берсе – су...
Алсу Шакирова

Заман һәм без

Ана күңеле – далада... 6
Мәдинә Авзалова

«Синең балаң!» 19

Татар дөньясы

Шәленең ак әбисе ул 24
Гөлшат Әюпова

Иргә кем якынрак: әнисеме, хатынымы? 27

Алма абый 28
Гөлнур Сафиуллина

Кешенең исеме – аның язмышы 32

Мәдәни тормыш

Күккә егыласы килә! 36
Галимҗан Гыйльманов

Ана-казна 38
Сәйдә Зыялы

Яшәеш

Ни хәлең бар, кеше туганым 44

Ялгыз канат 46
Чулпан Галиәхмәтова

Хуҗабикә

Яшь әни: сорау—җавап 56

Мускуллар барысын да сөйли 58


Баллы массаж 59

Өйнең яме — гөлләрдә 62

Тест&йолдызнамә 63

Кайнар эмальдә – салкын кыш 64
Зилә Нигъмәтуллина

50



Гомерләр юрасын, бәхетләр сорасын
Рафис Корбан

52



Хатлар язам, әни, сиңа хатлар...
Чулпан Галиәхмәтова


60



Ит рулеты
Венера Арсланова тәкъдим итә

»

АНА КҮҢЕЛЕ – ДАЛАДА...



«...Кемнедер рәнҗеткән, үпкәләткән булсам, гафу итегез. Хаталарым күп булды. Төрле хәлдән чыгып була. Мин бик арыдым. Берегезгә дә комачаулыйсым килми. Барысына да үзем гаепле».
(Бер яшүсмернең үз-үзенә кул салыр алдыннан язып калдырган соңгы сүзләре.)



Мәдинә АВЗАЛОВА

...Аның турында төрле сүзләр йөри: уку аңа авырдан бирелгән. Тәртип ягы бик чамалы булган. Балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясендә каралган... Ни өчен «булган», «каралган»мы? Ни өчен үткән заманда сөйлибезме? Чөнки ул юк инде.

Җан өшеткеч бу вакыйгага инде шактый вакыт үтеп китсә дә, күңелне тырнап торган сорауларның берсенә генә булса да җавап табып карыйк әле.

Күз ашыга-ашыга кышларга кереп барган бер мәлдә, кара төн уртасында кыз баланың үле гәүдәсен элмәктән алалар. «Ашыгыч ярдәм» машинасы да, ясалма сулыш та коткарып кала алмый. Соң була. Яшүсмернең кем баласы булуын шундук беләләр, әлбәттә. Әнә, ул яшәгән йорт... Кул сузымында гына. Бөтен авыл халкын аякка бастырган шушы фаҗига, инде биш айлап вакыт үтеп китсә дә, һич истән чыкмый. Гомере әле башланып кына килгән 16 яшьлек кыз бала ни өчен кире әйләнеп кайта алмастай юлны сайлаган? Моңа аны ни-нәрсә этәргән? Хәзер тикшерү органнары, судмедэксперт, балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясе әгъзалары, психологлар бу катлаулы, гаять четерекле сорауга җавап эзли. Баланы соңгы адымга – билгесезлеккә этәрү сәбәпләрен ачыклый. Кызганыч, моның өше хәтәр очракларны вакытында туктату юлларын әлегә берәү дә белми. Ә инде булган хәлләрдән тиешле нәтиҗә ясарга кирәк, бик кирәк. Ни өчен дигәндә, суицидлар, башкача әйтсәк, баланың, яшүсмернең (бигрәк тә 10–19 яшькәчә күзәтелә) аңлы рәвештә үз-үзенә кул салу очраклары арта бара. Башында шундый куркыныч уй йөртүчеләр күпме тагын?

Республиканың балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе сәркатибе Илсөяр Гарифуллина әйтүенчә, былтыр Татарстан Республикасында 14 суицид очрагы теркәлгән. Шуның 6 сы – ир бала, 8 е – кызлар. Моннан тыш, үз-үзен үтерергә омтылыш ясап караган 77 яшүсмернең ярдәм сорап медицина оешмаларына мөрәҗәгать итүе мәгълүм. Җитди уйланырга мәҗбүр итә торган әлеге хәлләрдән мөмкин кадәр азрак югалтулар белән чыгу юлларын ничек табарга? Баланың үзенә генә мәгълүм булган эчке дөньясына ничек үтеп керергә?

...Бу дөньядан китәргә теләп, яшүсмернең үз-үзенә кул салуы ата-ана өчен зур фаҗига. Бу хакта әйтеп торасы да юк. Ләкин бәланең иң хәтәре, иң зурысы шунда: ни өчен баласының мондый куркыныч адымга баруын ата-аналар белми. Ә бәлкем, сизеп тә, таныйсы килмидер. Психологлар, бала суицидын ярдәм сорап ялваруның соңгы баскычы дип аңлата. Үз эченә бикләнгән ул бәхетсезләрне якыннары да, тирә-ягындагы кешеләр дә ишетми, күрми. Үзен белдерер, танытыр өчен ул соңгы чикне сайлый. Болай дигәндә, суицид турында кыска метражлы бер фильм искә төшә. 10 яшьләр тирәсендәге бер малай, әнисенең кибеттән кайтканын тәрәзәдән карап тора да, әзерләп куйган элмәккә муенын тыгып, аның ишеккә ачкыч тыкканын гына көтә. Ишек ачылып китә, әнисе коткарып калыр дип, бала элмәкне тарта... Үч иткәндәй, нәкъ шул минутта күршеләре дә килеп чыга, алар сөйләшеп китә... Ә әнисе фатирына аяк атлап кергәндә, инде соң була...

Ни әйтергә теләгән?

Үз гомерен үзе өзгән кыз баланың нияте, уй-теләкләре нинди булды икән? Һәрхәлдә, коткарырлар, ярдәм итәрләр диген уй булмагандыр анда. Үз-үзен белештермичә, аффект хәлендә эшләве дә ихтимал. Әйе, фаҗигагә китереп җиткерү сәбәпләре бихисап. Гадәттә, соңгы вакыйгалар белән бәйләргә күнеккәнбез. Тик монысы баланың мөлдерәмә тулы сабырлыгының соңгы тамчысы гына. Бу хәлләр белән якынрак танышкан саен, шуңа инана бардым. Чәчәк атарга да өлгермәгән кыска гомерендә Алия дә (*авт. – исемнәр үзгәртеп бирелә*) михнәтне күп күрә. Бәлкем, бу авырлыкларны, балалыгы белән, табигый хәл, шулай булырга тиеш дип кабул иткәндер. Чөнки тормышның башкасын – тигез-тату гаиләдә, әти-әнинең назлы кочагында, борчу күрми генә яшәүнең ни икәнен белми ул. Белми дә, күз алдына китерә дә алмый.

Ире үлгәндә ике бала белән калган хатын, икенче иргә кияүгә чыгып, Алияне таба, аннан тагын бер кызлары дөньяга килә. Гаиләдәге дүрт баланың икесе хәзер үз тормышлары белән яши, аларның үз гаиләләре, үз проблемалары... Кечерәкләре исә әти-әни янында. Бер уйлаганда, өйдә утыручы әни бөтен көчен, тырышлыгын балалар тәрбияләүгә биреп, алар дип яшәргә тиеш тә соң. Әмма, юк... Хәл биредә күпкә катлаулырак, хәтта сәеррәк тә...

Бу гаилә турында социаль авыр хәлдәге гаилә, диләр. Әти-әни эчәргә ярата. Алар икесе дә 2016 елдан бирле районның балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясендә исәптә тора. Әти кешенең даими эш урыны юк, әнисе бөтенләй эшләми. Өстәвенә, әниләре бик еш өйдән чыгып китә, кайтмый башлый. Баксаң, ул читтә тагын бер ир-ат белән очраша икән. Андый әнинең балада нинди гаме булсын инде? Ана күңеле балада түгел, ана күңеле – далада очрагы бу. Әниләр барысы да бертөрле: бала өчен җанын фида кылырга әзер дип әйтергә яратсак та, алай түгел. Инде беләбез, тәҗрибә моны кат-кат раслады: безнең арада баласыннан читләшкән, бар да, юк та булып шәүлә сыман йөргән, сабыена салкын карашлы битараф әниләр дә бар. Мондый әниләр белән бала арасында элемтә сүнгән. Бала инде аннан ярдәм дә, җылы сүз дә, наз да көтми, аңа ышанмый да. Һәм көннәрдән бер көнне ул үзен ташландык итеп хис итә башлый. Психологлар әй-түенчә, бала бер мәлдә өметсезлеккә бирелә.

Үзен кирәксез итеп саный, аны курку биләп ала. Яшүсмерлек чорына ул инде үз эченә йомылып, якыннарыннан, дусларыннан читләшеп,



Илсөяр ГАРИФУЛЛИНА,
Республиканың балигъ булмаган балалар белән эшләү һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе сәркатибе

Ананың баласы өчен ни дәрәҗәдә якын һәм кадерле, кирәкле һәм газиз кеше булуын искәртеп тормыйм. Болай да аңлашыла. Миңа калса, карында чагында баланы әнисе белән бәйләп торган кендек җебе ул беркайчан да өзелми. Шуңа да бәләкәй чагында да, үсеп җиткәч тә әни кирәк. Гомер буе ул синең белән бергә, янәшәдә, кул сузымында гына булырга тиеш. Бала үз-үзенә кул салган, дип сөйли башласалар, шундук күз алдына гомерен кискән баланың әнисе килеп баса. Ул нинди хәлдә икән? Ничек күрми-сизми калды икән? Ә бит бөтен проблема, бөтен хикмәт шунда. Гаугалы, низаглы гаиләдә баланың эчке кичерешләренә берәү дә игътибар итми. Әти-әнинең үз кайгысы үзендә. Өстәвенә, әле эчкече дә булсалар... Ул чагында безгә «аяк астында буталган» баланың хәленә керергә генә кала.

Бала тәрбияләү ул – ана вазыйфасы дисәм, яңалык әйтмәм. Гаиләнең язылмаган төп законы бу. Ә тәрбияләү өчен, беренче чиратта, үзеңә тәрбияле булырга кирәк. Әгәр син сабыеңа үрнәк була алмыйсың, үзеңнең гамәлләрең, үз-үзеңне тотышың белән аны хәйран итә алмыйсың икән, син аңа беркайчан да терәк була алмаячаксың. Моның ише йөрәк тетрәткеч, сискәндергеч хәлләрнең килеп чыгуында иң элек ата-ана, хәтта, әйтер идем, ана кеше гаепле. Кабатлап әйтәм: ана балага һәрнәрсәдә үрнәк булырга тиеш! Әгәр дә инде ул эчкән өчен исәптә торса... Аның белән хокук органнары шөгыльләнсә, нәрсә дияргә инде монда?

Баланың үз-үзенә кул салуы – зур фаҗига. Бер генә җәмәгать оешмасы да, мәктәп тә бу вакыйгага битараф калырга тиеш түгел. Мондый хәлнең килеп чыгуына алар да гаепле. Күреп җиткермәгәннәр, чарасын күрмәгәннәр. Эш узгач, гаепне бер-береңә аударудан мәгънә юк. Ә без һаман да аны читтән эзлибез. Чит бала юк, баланы чолгап алган чит мохит бар. Шуны онытмаска кирәк! Әти-әни бала сүзенә колак салырга тиеш. Һәм тәрбия, әлбәттә инде, бары яхшы мисалларда гына булырга тиеш. Баланың яхшы якларын күрмәсәң, ул үз-үзен якларга тырыша. Бер сүз белән әйткәндә, балаларга кисәтү ясаганчы, башта үзеңә карарга кирәк. Үзеңнең тәртибең дөрес түгел икән, балага әйткәнең җилгә очкан сүз кебек. Һичшиксез, бөтен нәрсә – яхшысы да, яманы да гаиләдән башлана. Баланы гаиләдә аңламыйлар икән, ул әнә шундый фаҗигагә килеп җитәргә мөмкин.

Фото: www.pixabay.com



Бала өчен ана ул – яктылык-җылылык, ярату-наз бөркелеп торган ачык ишек, үзе бер дөнья. Әгәр ул ишекләр ябык булса...



Наталья САБИРОВА,
Казан шәһәре «Доверие» үзәгенең «Сердәш» психологик-педагогик хезмәте җитәкчесе

Узган ел «Ышаныч» телефонына ике меңнән артык яшүсмер мөрәҗәгать иткән.

Мин үзем дә «Ышаныч» телефонына килгән хәбәрләрне тыңлыйм. Кызлар, малайлар шалтырата. «Яшисем килми», «Миңа бик авыр», «Мине беркем тыңламый» ише йөрәк әрнеткеч сүзләрне еш ишетергә туры килә. Кайчак алар белән сәгатьләр буе сөйләшәм. Балага тормышның дәвам итүен, ул сөйләгән проблемаларның хәл ителерлек булуын, моның өчен нәрсә эшләргә, нәрсә эшләмәскә кирәклеген тәфсилләп аңлатам. Алар аңлый, инде чарасыз, өметсез тоелган ситуациядән чыгу юлы табылуына һәм аның, бер караганда, шундый гади булуына үзләре дә гаҗәпләнә. Әгәр ул каһәрләүнең югары ноктасына җиткәндә шалтыратса, исән кала. Аны бу куркыныч уеннан кире кайтару өчен бөтенесе эшләнә.

Әти-әниләре эчәргә яраткан гаиләдә атмосфера, үзара мөнәсәбәтләр кызган табаны хәтерләтә. Үзегез, беләсез, эчкече кешенең аңы, чынбарлыкны кабул итүе ватык пыяла шикелле. Ул аны бөтенләй башкача күрә. Шуңа күрә баланың кечкенә генә бер үтенече, ялварулы карашы анда зур канәгатьсезлек, ачу-ярсу тудырырга мөмкин. Бөтен бәла шунда бит. Исерек әти яисә әни өчен тиктомалдан баласын кыйнап ташлау да берни тормый. Изелеп, җәбер-золым күреп яшәгән бала көннәрдән бер көнне сына. Яшәү мәгънәсен тапмый башлый. Ахыры ни белән бетәсен чамалау кыен түгел. Бер генә ата-ана да, хәтта хәмер сөремендә йөзгәннәре дә, газизенең үлемен теләми. Баланы өметсезлектән, кирәксез кеше итеп тоюдан, үз дөньясына бикләнүдән бары без – өлкәннәр, иң беренче чиратта, әти-әниләр коткарып калырга бурычлы.

Сүз уңаеннан: балалар өчен безнең «Ышаныч» телефоннары:
8 (843) 571 35 71; 8 800 200 01 22 (Россия буенча кайнар линия).

дөньясыннан ваз кичеп керә. Бертуктаусыз үзен «кыздырып» тору, стресста тоту ата-анасы тарафыннан кире кагылган бала өчен яшәү нормасына әверелә. Алия дә үзен «артык кашык» сыман хис иткәндер. Һәркайсы үз эше белән мәшгуль гаиләсендә, җыелып килә-килә, бәләкәй җилкәсенә күтәрә алмастай йөк булып төшкән проблемаларын хәл итәрдәй ышанычлы терәк юклыктан өметләре өзелгәндер.

Кыз белемгә тартылмаган, еш кына дәресләр калдыра торган булган. Әти-әнисе ата-ана җыелышларына йөрмәгән, баланың укуы белән кызыксынмаган. Мәктәп директоры, социаль педагог, балигъ булмаган балалар комиссиясе инспекторлары алып барган сөйләшүләр дә тиешле нәтиҗәне бирмәгән, күрәсең. Алияне аралашучан, яшьтәшләре белән бик тиз уртак тел таба белгән, эмоциональ һәм мөстәкыйль булган, дип сөйлиләр. Хокук тәртибен бозарга, җинаять кылырга һәвәслеген дә искәртәләр. Танышлары әйтүе буенча әлеге сыйфатлар хәзер кече кызларында да чагыла. Яшүсмер балаларын укыту һәм тәрбияләү буенча бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен әти-әнисе административ җаваплылыкка тартылган. Гаиләне полиция хезмәткәрләре даими тикшереп тора хәзер. Ләкин фатирга эләгү, әти-әнинең өйдә чагын туры китерү мөмкинлеге генә сирәк була. Гомумән, бу гаилә белән эшләмәгәннәр түгел, эшләгәннәр инде. Файдасы гына юк.

«Тагын бер кызымның үлүен телисезме?»

Районның балигъ булмаган балалар комиссиясе утырышында Алиянең әти-әнисен ата-ана хокукыннан мәхрүм итү мәсьәләсе күтәрелгәч, әни кеше шулай дип гаҗәпкә калдырган. Бер уйласаң, бәлкем, куркыныч фаҗиганең кабатланмавы өчен бердәнбер юлы да шулдыр аның. Бала хокукларын санга сукмаган гаиләдән әллә ни көтеп булмый.

Сүз дә юк, бу – гаять четерекле мәсьәлә. Һәм без биредә аның бер ягына гына, баланы суицидка этәргән сәбәпләрнең берсенә – гаилә хәлләренә генә тукталдык. Баланың үз-үзенә кул салуын беркайчан да очраклы хәл дип бәяләргә кирәкми. Дөнья белән хушлашырга карар кылган бала бу уйны башында бик озак йөртә. Нәрсә этәрә, дисезме? Күргәнебезчә, гаиләдәге низаглар, җавапсыз мәхәббәт, төрле секталар, интернетта суицидка чакыручы төркемнәр... Яла ягу, куркыту-кимсетүләр, җәбер-золымнар, сексуаль көчләүләр... Болары әле без белгән кадәресе генә. Суицидның иң югары ноктасы 14–17 яшькә туры килә икән. Психологлар моны гормональ үзгәрешләр булуы белән дә аңлата. Яшүсмернең, бер яктан, зур һәм мөстәкыйль буласы килә; ә икенче яктан, тәҗрибәсе җитми. Шулай итеп, аның эчке дөньясы икегә бүленә. Кечкенә генә бер негатив очрак та баланы сындырырга мөмкин. Өстәвенә, өлкәннәр дә аны тәнкыйтьләп, «бастырып» тотсалар... Бала күңеле – үзе бер утрау. Аңа үтеп керү өчен үзенә бер осталык, сабырлык, әти-әнинең чиксез яратуы сорала. Әзерме без моңа? Упкыннан бер адымда торган баланы бары якыннары гына алып кала ала. Балада проблема башланганны сизү өчен психолог булырга кирәкми. Игътибарлы булу, аның белән ачыктан-ачык сөйләшү, хәленә керү дә бик җитә. Югыйсә суицидның «үтерүче» булуына тетрәндергеч мисаллар арта гына торыр.



Белгеч фикере

КАЙБЕР ӘНИЛӘР НИГӘ КАТЫ БӘГЫРЬЛЕ?

Айсылу НӘГЫЙМОВА, социология фәннәре докторы, профессор, психолог

Бөтен җәмгыятьне тетрәндерә торган вакыйгалар арасында иң авыры, иң куркынычы балаларга карата кулланылган җәбер-золым белән бәйледер. Бигрәк тә җәберләүче – баланың үз әнисе, үз әтисе булса… Мондый мөнәсәбәтләрне китереп чыгарган ике төркем сәбәпләрне атарга кирәктер: психологик һәм социаль сәбәпләр. Социаль сәбәпләр дигәндә, яшь гаиләләрнең тормыш шартлары авырлашу, эшсезлек, торыр урын булмау, гаиләнең кереме кимүне атап булыр иде. Ләкин болар гына балаларга карата рәхимсезлек уята дип әйтергә ярамый. Бүген социаль катламнарга бүленү һәм алар арасында керемнәрнең чагыштыргысыз дәрәҗәдә аерылуы психологик яктан зур басым ясый. Массакүләм мәгълүмат чаралары, социаль челтәрләр берөзлексез матур, бай тормыш үрнәкләрен алга куя, ә чынбарлык күпләрдән иң кирәкле ихтыяҗны канәгатьләндерү өчен дә бик зур көч таләп итә. Кайбер очракта ата-ана баланы үзенең авыр матди хәленең сәбәбе итеп күрергә мөмкин.

Әмма, минемчә, беренче урында психологик сәбәпләр тора. Алар арасында иң әһәмиятлесе – гаилә традицияләре. Ата-ана үзе нинди гаиләдә тәрбияләнгән, җитәрлек дәрәҗәдә ана назы, ата кайгыртучанлыгы күргәнме? 90 нчы елларда туып-үскән балалар – бүген инде әти-әниләр. Ул вакытта еш кына ата-аналар көне-төне акча табу хәстәрен кайгыртты, балалар әби-бабай карамагында яки, гомумән, үзләре генә калды. Нәкъ менә шундый мөнәсәбәтләр «бала тәрбияләү – ашату-эчертү, киендерү генә» дигән модельне тудыра да инде. Ана белән бала арасындагы табигый мөнәсәбәтләр чылбыры өзелә, гаилә бер түбә астында аерым тормыш белән көн күрүчеләр җыелмасына әйләнә… Еш кына моңа сабый чакта үзе дә көч куллануга дучар ителгән ата-ананың үткәне килеп кушыла, һәм бала тәрбияләү бары тик боеру, тавыш күтәрү, тән җәзасына тартуга гына кайтып кала – бала әти-әнинең дөньядан аласы бөтен үчен кайтару объектына әйләнә…

Соңгы елларда килеп чыккан тагын бер проблема турында да әйтеп үтми мөмкин түгел. Бу – психологик бәйлелек проблемасы. Һәм аның иң киң таралганы – телефонга, интернетка, гомумән, гаджетларга бәйлелек. Психологик бәйлелектәге кешене әлеге объекттан аерган һәр сәбәп чыгырыннан чыгара, бигүк адекват булмаган адымнарга этәрә. Чөнки бала аңа рәхәтләнеп телефонына чумарга комачаулый! Шуннан инде контрольсез калган балалар (кайда йөрсә, нәрсә эшләсә дә ярый – комачауламасын гына!), сабый чактан ук әлеге дә баягы телефонга ияләшкән, телефоннан башка ашый да, йоклый да алмый торган балалар килеп чыга. Ә бит бу бала да берзаман, үсеп, әти-әни булачак... Бик куркыныч феномен алдында торабыз: моннан 20–30 еллар элек эчкече, наркоман әти-әни генә баланың тормышына, гомеренә куркыныч тудыра иде. Ә бүген бөтенләй башка күренеш белән очрашабыз: беренче карашка социаль яктан имин гаиләләрдә дә балаларга карата рәхимсез мөнәсәбәт күзәтелә, ә кайбер очракта бала тормышы куркыныч астына куела.

Шул уңайдан, әти-әниләргә берничә киңәш бирәсем килә:

1. Балалар үскән гаиләдә әти-әни үзе өчен дә гаджетлардан файдалану вакытын чикләргә һәм балаларга да билгеле бер режим урнаштырырга тиеш. Мәктәпкәчә яшьтәге бала өчен иң файдалы шөгыль – актив уеннар, вак моториканы үстерү өчен рәсем, аппликация ясау, пластилиннан сыннар әвәләү. Бергәләп китап уку бала белән ата-ана мөнәсәбәтләрен якынайта, аралашу өчен уртак темалар тудыра.

2. Әти-әниләргә тиз кызып китү, ярсу, ачу хисләрен йөгәнләргә өйрәнү зарур. Еш кына артык кызып китүчәнлекнең нигезендә ару, йокы һәм ял җитмәү ята. Димәк, гаиләдә ял һәм хезмәт режимы җайга салынмаган. Шулай ук мондый хәл ниндидер чишелеше катлаулы ситуация алдында торган кешеләрдә күзәтелергә мөмкин. Бу очракта проблеманы хәл итү юлларын эзләргә кирәк. Үзегезгә психологик ярдәм күрсәтү юлларын да табыгыз: аутотренинг яки башка төр психологик алымнар алыштыргысыз ярдәм күрсәтергә мөмкин. Агрессия һәрвакыт гормоннар бүленеше белән бәйле. Ә деструктив гормоннарны «яндыру»ның иң яхшы ысулы – спорт. Гаилә белән берлектә актив спорт белән шөгыльләнү нерв системасын чыныктырып, бушандырып кына калмый, ә сәламәтлеккә дә уңай йогынты ясый. Гомумән, тормышта бертөрлелектән качарга тырышыгыз – төрле походлар, кунакларга йөрешү, табигать кочагына чыгу – барысы да иң яхшы профилактика чаралары.

PRESSA

ЯНАРГА ИКӘН – ЯНАРГА, ЯНАРГА АЗАККАЧА!



Эльмира ЗАКИРОВА

«Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесенең Буада узган зона туры безнең өчен тагын яңа исемнәр ачты, тагын яңа талантлары белән сокландырды. Республикабызның Тау ягында – Югары Ослан, Кама Тамагы, Тәтеш, Яшел Үзән, Кайбыч, Апас, Буа, Чүпрәле якларында – хатын-кызларның уңганнары-булганнары, янып торганнары яши шул! Ә менә Яшел Үзән кызлары таң калдырды дисәм дә, һич арттыру булмас. Шулай булмыйча! Иң күп баллар – аларда, җиңүчеләр пьедесталында – алар! Һәм барысы шундый кызыклы шәхесләр! Аларда мәктәп директоры – фән кандидаты да, төзүче-инженер – туган авылында туристлар маршрутына юл ачучы да, мәдәният йорты режиссёры – үзе актриса да, «Иҗат үзәге» җитәкчесе – шәһәр советы депутаты да, волонтёрлар үзәге җитәкчесе – үсмерләр дөньясы илчесе дә, кадетлар мәктәбе директоры – чып-чын полковник та!.. Менә шулай. Һәркайсы – зур шәхес. «Янарга икән – янарга, янарга азаккача!» девизы белән яши алар! Язмышлары да, башкарган эшләре дә кызыклы. Һәм алар матур мизгелләре, күңелгә уелып калган якты төсләре, шәп энергетикалары белән гүзәл затларыбызны зурлый торган республика бәйгесе елъязмасына кучә, аның битләрен баета бара.

Мин яратам сине, Татарстан!

Ул үзен тулысынча балаларга багышлаган. Сахалин дәүләт университетында технология һәм эшмәкәрлек белгечлеге алган кыз, кияүгә чыгып бала тапканнан соң, башта балалар бакчасына эшкә урнаша. Төрле күңелле бәйрәмнәр оештырырга хирыс, янып торган Светлананы балалар да, әти-әниләр дә ярата. Ә аңа һаман нидер җитми. Күңеле һаман каядыр талпына, эзләнә, әллә кайларга ашкына. Сахалиннан меңнәрчә чакрым ераклыкта Татарстан дигән җанга якын ил бар. Башкаласы Казан, әбибабаларының туган җире Яшел Үзән яклары, Идел буйлары, Сабантуйлар уза торган яшел болыннары, ягымлы, ачык йөзле кешеләре... Светланага балачактан ук таныш, кадерле җирләр. Шуңа да каникуллар башлану белән җәй саен Татарстанга оча ул. Ә кышын хатларында һаман бер сүзне яза: «Мин барыбер Татарстанга күчәм!» Һәм күчә дә! Башта – әти-әниләре кайта, аннары үзе дә. Кыю, шат күңелле, тәвәккәл, актив кызны шундук күреп тә алалар, үсмерләр клубына эшкә дә чакыралар. Клубка килү белән үк күңеленә хуш килгән дөньяга эләгүен аңлый.
«Мин булдырам!» – дигән уй тагын бөтен барлыгын биләп ала. «Бездә тренажер залы, теннис өстәле бар, килегез, рәхәтләнеп шөгыльләнегез», – дип ымсындыра ул үсмерләрне. Шул малайларны ярты сүздән аңлый торган үз кешеләренә дә әйләнә. 100 гә якын яшүсмер күзенә карап торсын әле! «Йөриләр-йөриләр дә, берара югалып та торалар. 9 нчы класстан соң күбесе техникумнарга керә бит. Каникулларга кайткач, барыбер кабат киләләр. Сагыналар!» – ди Светлана сөенеп. Ләкин Янтуганова өчен бу клуб эше генә дә аз тоела башлый. Тотынса, ул зуррак эшләрне дә колачлый ала бит! Яшел Үзән кебек шәһәргә волонтёрлар үзәге бик кирәк, мәсәлән. Шәһәрнең яшьләр эшләре бүлеге җитәкчесенә шул хакта җиткерә. Светлананың тәкъдимен ишетеп, күтәреп кенә алмыйлар





Михаил АФАНАСЬЕВ,
Яшел Үзән муниципаль район башлыгы,
Яшел Үзән шәһәре мэры

Үзебезнең Яшел Үзән хатын-кызлары белән чиксез горурланабыз! Кайсын гына алма, һәркайсы җиңүче инде безнең өчен! Гүзәл ханымнар, кайгыртучан әниләр, үз эшләренең чын осталары, тиктормас тынгысыз затлар... Яшел Үзән районы үсеше өчен үзләреннән әйтеп бетергесез зур өлеш кертеп, алар яңа үрләр яулыйлар, районыбызны, шәһәребезне, республикабызны матур эшләре белән бизәп данга күмәләр.

үзен! Һәм шул җаваплы эшне ышанып тапшыралар да. 2021 елның сентябрендә Яшел Үзән муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре бүлегендә Үсмерләр клубы базасында Волонтёрлар штабы эшләп китә. Беренче сынауны да уңышлы үтәләр: халык санын алуда 30 волонтер катнаша. «Ярдәм янәшәдә» акциясенә кушылып, өлкәннәргә азык-төлек, дарулар илтәләр. Гуманлы, кешелекле, киң күңелле, башкаларга һәрчак ярдәм итәргә әзер ачык йөзле, кылган игелекле эшләрдән күзләре янып торган егетләр-кызлар җитәрлек икән бит Яшел Үзәндә! Светлана шуңа сөенә. Ул үзенең лидер булуын, үзендәге бар җылыны, яхшылыкны башкаларга күчерә алуын аңлый. Юкка гына аны позитив, креатив, кояшлы, талантлы, шат күңелле, үз дигәненә ирешә торган яшьләр лидеры, безнең Алтынчәч дип атамыйлар инде! «Великолепный век» сериалы героена охшатып, безнең Хюррем дип тә йөртәләр икән әле! Светлананың җаваплы вазыйфалары болар белән генә дә чикләнми. Дистә еллап инде җәйләрен «Исток» яшьләр берләшмәсенә караган Муса Җәлил исемендәге лагерьда спорт, хәрби-патриотик, экологик сменаларда эшләү, наркотикларга каршы комиссия секретаре булу, Яшел Үзәннең Яшьләр парламенты, доброволецлар командасы башлангычларына юнәлеш бирү... Тикмәгә генә: «Мавыгуларым – яраткан эшем!» – димидер инде! Казан педколледжында укучы кызы Виолетта да әнисен кабатлый: волонтёр да ул, «Свияга-фест»ка да бара, халык санын алуда да катнаша, әле әнә «Дөнья – учымда» дигән бер проектны эшләп, клубта мультимедиалы зона булдыру идеясен тормышка ашырып йөри. «Күзләре янып тора! Аның да яшьләр сәясәте буенча эшлисе килә», – ди әнисе.

Ерак Көнчыгыш кызы Сахалинын, андагы янартауларны, сопкаларны, хисапсыз күлләрне, Татар бугазындагы тормышны, юл аркылы гына җәйрәп ятучы Охот диңгезен дә юксынып куя. Татарстан белән Сахалинны йөрәге аша үткәреп, бизмән тәлинкәләренә ничәмә-ничә салып караганы булды инде! Яшел Үзәнгә килгәч, озын төз наратларны күреп хәйраннар калуын, мәчетләрдән яңгыраган азан тавышыннан күзләренә яшьләр килүен, «Мин яратам сине, Татарстан!» дигән җырны ишетеп, җаннары чымырдап китүен искә төшерә дә, елмаеп куя. «Миңа хәзер Сахалиндагы дусларым син татарча акцент белән сөйләшәсең диләр инде! – дип яңгыратып көлә дә, – Татарстаннан, Яшел Үзәннән башка яши алмыйм икән мин», – дип куя.



Андрей КРАТКОВ, Васильеводагы кадет интернат-мәктәбе директоры

Иптәш полковник, кадет мәктәбе өйрәнүләргә әзер!

Советлар Союзы Герое Николай Волостнов исемендәге Васильево кадет интернат-мәктәбендә көн саен шулай хәрбиләрчә рапортлар яңгырый, анда – тәртип, дисциплина. Малайлар гына түгел, кызлар да хәрби киемне ярата. Ә кадет мәктәбе директоры Андрей Николаевич Кратков үзенә бер хәрби утрау, чын патриотлар мәктәбе ясый алган. Чып-чын хәрби кеше, полковник ул. Погонында өч зур йолдыз балкый. Кызыл байраклы Казан югары хәрби команда училищесын, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре академиясен тәмамлаган. 2010 елда отставкага чыккач, аны Васильево кадет мәктәбенә чакырып алалар. Егетләр үзләрен, Ватаннарын саклый белергә тиеш, ди полковник Кратков. Ә никадәр укучысы хәрби училищеларны, хәрби югары уку йортларын сайлаган! Хәрбиләр кырыс, төгәл була, салкын акыл белән эш итә, диләр. Әмма Андрей Николаевичта шаянлык та, җылылык та бар. Бик компетентлы, иҗади җитәкче, диләр аның турында. Дәресләрен һәрчак көтеп алалар. Укучыларны «Юнармия» хәрәкәтенә алып кереп китүче дә, тормыш куркынычсызлыгы нигезләре буенча Бөтенроссия олимпиадаларында призлы урыннар яуларга, «Иң яхшы кадет мәктәбе» номинациясендә җиңүче булырга канатландыручы да, хәрби-патриотик чараларны оештырырга өйрәтүче дә – ул.

Фото: Анна Арахамия



Асия ГОБӘЙДУЛЛИНА, «Акведук» ҖЧҖ проект компаниясе директоры

Каюм Насыйри нәселенең бишенче буыны

Асия Наил кызы Гобәйдуллина – төзүче-инженер, «Акведук» ҖЧҖ проект компаниясе директоры, Татарстанның атказанган төзүчесе. Соңгы вакытта Асия ханым зур эшкә тотынды: 2015 елда «Каюм Насыйриның туган җирен яңадан торгызу» фондын оештырып җибәрде. Бердән, ул Каюм Насыйри исемен популярлаштыру максатын үти; икенчедән, күренекле мәгърифәтченең туган авылын саклап калу, аны яңарту белән дә бәйле. Мәгърифәтче, галим, язучы, этнограф Каюм Насыйриның авылдашы, Кече Шырдан кызы Асия тырышлыгы белән авыл төзекләндерелә, Каюм бабай коесы да, матур итеп бизәлгән чишмәләре дә үзенә чакырып тора. Заманында Каюм Насыйри акча биреп төзеткән мәчетне дә яңадан торгызганнар. Кунакларны сыйлар өчен чәйханә дә бар хәзер. Музей-китапханә ачу да Асия Гобәйдуллина идеясе була. Каюм Насыйри китапларын, сирәк китапларны, бүгенге матур әдәбиятны киштәләргә тезәләр. 2021 елның февралендә музей-китапханә ишекләрен ача. Шырданлылар танылган татар мәгърифәтчесе туган авылда яшәүләре белән горурлана. Бу якларда Шырдан исемле авыллар дүртәү. «Болгар ханлыгы таркалганда, абыйлы-энеле дүрт туган килеп урнашып, әлеге авылларга нигез салган», – дип язган Каюм Насыйри. «Аның үзенең дә, гаиләсенең дә нәселе шул Болгар бабаларыбызга тоташа, – дип сөйли Асия Наил кызы. – Мин үзем дә Каюм бабайлар нәселенең бишенче буын вәкиле! Безнең шәҗәрәбез 1640 елдан башлана. Әни ягыннан без Насыйрилар нәселенә тоташабыз».

Бүгенге көндә К. Насыйри әсәрләре, хезмәтләре буенча видеороликларга конкурс бара. Анда Татарстанда яшәүчеләр генә түгел, төбәкара мәктәпләрдән дә катнашалар. Чараларны Бөтендөнья татар конгрессы булышлыгы белән уздыралар. «Мин күп кенә эшләремне башлап кына куям, миннән соң килгән буыннар минем эшемне дәвам итәрләр һәм татар халкын халыкара мәйданга алып чыгарлар», – дип язып калдырган күренекле мәгърифәтчебез. Каюм баба, һичшиксез, Асия кебек фидакарьләрне күздә тотып, шундый васыять калдыргандыр.



Ирина ФЕСЕНКО, Яшел Үзән муниципаль районы Иҗат үзәге директоры

Супергеройлар туплаган лидер

Балалы хатыннар ни өчен төнлә йокламый? Ирина уйга калды. Күптән түгел уздырылган тикшеренүләрдән соң, галимнәр шундый нәтиҗәгә килгән: балалы хатыннар төнлә йокламый икән! Ләкин ни өчен йокламаганнарын аңлатмаганнар менә! «Миннән сорасыннар иде. Мин, мәсәлән, төнлә планнар корып, исемлек төзеп ятам», – ди өч бала анасы Ирина Фесенко. Ирина Владимировна – өстәмә белем бирү үзәге директоры, Яшел Үзән шәһәр советы депутаты, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиленең Яшел Үзән буенча җәмәгать ярдәмчесе, «Гаилә канаты астында» республика иҗтимагый оешмасының Яшел Үзән филиалы җитәкчесе. Күпләр өчен ул – «Максатчан Нечкәбил» дә әле! Эшен «Көмеш тавыш» вокал студиясен оештырудан башлап җибәргән (Әүһәдиев исемендәге музыка училищесын, аннары ТГПУның музыка факультетын тәмамлаган!), 1 нче лицейда оештыручы-педагог булып таныткан үзен, дәрестән тыш эшләр буенча директор урынбасары эшләрен башкарган, мәгариф өлкәсендә менеджмент белгечлеге алган, Яшел Үзән муниципаль районы Иҗат үзәге директоры вазыйфасына кадәр күтәрелгән ханым да хыяллар, бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләр белән яши икән бит! Йокларга ятам дип башын мендәргә салса да, башкарыласы эшләрен керфек тә какмыйча күздән кичереп таң аттырган тәҗрибәле җитәкче планнары нинди була икән? Укучылары аны видео аша сурәтләп бирде. Ирина Фесенконың планнары конкрет: шәһәр чарасын уздырырга; депутат инициативасы белән чыгарга; Бала хокуклары көненә әзерләнергә; яңа проектлар, яңа уңышлар, грантлар яуларга; эш дип, үз балаларымны да онытып бетермәскә – өч малайны кайгыртырга: кечкенәсенә киез итек алырга, уртанчысының дәресләрен карашырга, олысы белән КВНга әзерләнергә... «Ләкин боларны берүзең генә башкарып чыгу мөмкин түгел. Шуның өчен синең командаң булырга тиеш, – ди ул. – Кешеләрне үз артыңнан ияртергә кирәк. Лидерлар шулай эшли. Лидер – чын супергеройларны үз артыннан ияртеп баручы ул. Андый команданың капитаны булу җиңел түгел. Ә минем артымда зур командам тора. Эштә – хезмәттәшләрем, өйдә – ирем һәм улларым, депутат эшчәнлегемдә – сайлаучыларым. Аларның һәркайсы өчен иң әйбәт капитан буласым килә. Миңа калса, барып чыга!»

Мәктәбе – фәнни-тикшеренү лабораториясе!

Советлар Союзы Герое Н. А. Катин исемендәге 17 нче мәктәпне Яшел Үзәндә нәкъ менә шулай дип йөртәләр! Мәктәп директоры Ирина Николаевна Маршалова үзе – фән кандидаты, 50 ләп фәнни мәкаләләр авторы булсын да! Педагогик эшчәнлеген 12 нче мәктәптә пионервожатый булып башлаган кыз Яшел Үзән механик колледжында тәрбия эшләре буенча директор урынбасары да була, «Социаль партнерлык – булачак инженерларда корпоратив культура формалаштыру чарасы» дигән темага диссертация яклап, педагогика фәннәре кандидаты дигән исемне дә яулый ул укучыларын фәнни-тикшеренү эшләренә җәлеп итә. Беренче карашка таләпчән, принципиаль күренгән директор күңелендә әле һаман нечкә зәвыклы, хыялый, мәктәбе, укучылары өчен җан атып йөри торган, соклана белгән, антиквар курчаклар җыю белән мавыккан, автомобильдә ире белән сәяхәт итеп бөтен Россияне айкаган Ирина яши. Син бәхетле икән, димәк, әйләнә-тирәңдәгеләр дә бәхетле, ди ул. Бәхетле булырга остазы, КХТИда укытучы профессор Петр Николаевич Осипов шулай өйрәткән. «Кичә интернетта бер психолог фикерен укыдым. Хыяллар тормышка ашсын өчен, үзегезнең 300 идеягезне языгыз, дигән ул. Уйланып утырып язган идем, минем 102 генә булды әле, – Ирина Николаевна елмаеп куя. – Тагын язарга кирәк. Ә иң зур теләгем – туганнарым, якыннарым, дусларым исән-сау булсыннар! Менә шул!» «Көтелмәгән кызыклы хыялыгыз бар идеме?» – дип кызыксынгач, ул: «Армиядә хезмәт итәргә хыяллана идем... – дип серен чишә. – Кызларны гадәттә медицина, элемтә юнәлешенә генә алалар иде бит. Ә минем разведчик буласым килде! – ди ул тәмам шаккаттырып. – Кем булырга, нишләргә кирәген тормыш үзе хәл итә, күрәсең. Ә директор барыбер разведчик булырга тиеш, ул барысын белеп торырга, бар нәрсәдән хәбәрдар булырга тиеш!» Менә шундый да икән әле директор Маршалова!



Ирина МАРШАЛОВА, Яшел Үзәндәге 17 нче мәктәп директоры

Яшел Үзәннең атказанган артисты

Елена Скрябинаны, яратып, шулай дип йөртәләр. «Яшел Үзәннең рәсми тавышы» дип тә атыйлар икән әле үзен! Васильево бистәсендә «Большой день» вокал студиясе җитәкчесе һәм режиссёр булып эшләгән бу яшь кенә ханым барысына да ничек өлгерәдер?! Яшел Үзәннән көн саен Васильевога, яраткан эшенә йөри. Бер генә бәйрәм дә, бер генә музыкаль чара да аннан башка узмый. Ул әле концерт алып бара, әле җырлый, әле спектакльләрдә уйный. Мальвина, төлке Алиса, Убырлы карчык, Кар кызы әкият геройлары образында балаларга бәйрәм ясау Лена өчен берни тормый. «Бик талантлы шәп педагог безнең Елена Робертовна! Декрет ялында да безне ташламады!» – дип, әти-әниләр сөенеп бетә алмый. Федераль Сабантуйларның да йөзек кашы булган ә‌нә! «Минзәләдә, Ык буйларында туып-үсим дә, ничек җырламыйм инде!» – ди ул, үзе саф татарча сөйләшүгә күчеп. Татар телен Әдия һәм Фәйрүзә әбиләре өйрәткән икән. Бәләкәйдән татар балалар бакчасына йөргән. Җырчы булырга хыялланган. Музыка мәктәбеннән соң Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетына укырга кергән. Җырчы Лидия Әхмәтова классында укыган кыз «Сәлам» керәшен ансамблендә җырлап йөри, остазыннан сәхнәне яратырга, вокал нечкәлекләренә өйрәнә. Лена Рөстәм Яхин романсларын җырларга, фортепианода уйнарга ярата. «Зәңгәр томан» җыры тавышына аеруча килешә. «Уңышларымның сере – тормышта барысы да гармониядә минем: гаилә дә, эш тә, өй дә, – ди Лена. – Иртән рәхәтләнеп эшемә, яраткан укучыларым янына чыгып китәм. Шундый талантлы балалар! Алардан әйбәт энергия, позитив күчә миңа. Без – бер дулкында! Эштән соң сөенеп, сагынып өйгә кайтам. Ирем миндә хатын-кыз идеалы күрә. Улыбыз Аяз зур инде: 9 яшь аңа! Минем булышчым! Ә бәләкәчебезгә әле 7 ай гына! Яраткан гаиләм, балаларым, әти-әнием, дусларым, укучыларым – минем тормыш пазлымда...»

Ленаның җыры да үзе турында. Йомшак тембры, илаһи тавышы белән күңелләрне иркәли. Ә эчтәлеге менә болайрак яңгырый: «Мин – хатын-кыз! Димәк, йомшаклыгым белән көчле мин... Үзем – фильм авторы, үзем – актриса, үзем – тамашачы, яңалыклар чыганагы... Мин – хатын-кыз! Күп әйбергә – яратуга, яратылуга, бәхеткә лаекмын...»



Елена СКРЯБИНА, Васильево мәдәният йорты режиссёры

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА



Сезнең гаиләдә кем баш? Әтиме? Әниме?

Рамазан: Әлбәттә, әти. Ул һәр гаиләдә шулай булырга тиештер. Ирләр бит алар ике төрле сөйләшмиләр, ә хатын-кызлар фикерләрен үзгәртеп тора. Гаилә белән идарә итәр өчен нык сүзле булырга кирәктер.

Нурсолтан: Абый белән тулысынча килешәм. Әти – баш, әни – аның терәге.

Нәрсәдер эшләргә кирәк булганда кемнән рөхсәт сорыйсыз?

Нурсолтан: Безнең ватсапта гаиләбезнең уртак чаты бар. Шунда язып сорыйбыз. Кая барасың, кем белән буласың, ничәдә кайтасың, өй эшләрен эшләдеңме дигән стандарт сорауларга җавап биргәч, рөхсәт итәләр.

Әгәр «юк» дип әйтсәләр...

Рамазан: Өйдә каласың инде.

Нурсолтан: Башта фикерләрен үзгәртеп карарга тырышабыз. Әнине күндереп була әле, әгәр әти юк дисә, димәк, юк инде, өйдә утырабыз.

Малайлар булгач төрле хәлләр була. Кем беләндер сугышып кайттыгыз ди. Бу хакта өйдәгеләргә әйтәчәксезме?

Нурсолтан: Әнигә әйтмибез, нигә аны борчырга, ул бит хатын-кыз! Әтигә әйтергә мөмкинбез. Әтинең беренче соравы: «Кем башлады? Җиңдеңме?» Җиңгәнбез икән, «Молодец», ди. Әни, нигә сугышып йөрисең, берәрсенә зыян салсаң, әниләре килсә, дия башлый.

Сезне ачуланаламы?

Рамазан: Күп очракта күз йомалар. «Малайлар, минем җыелып бара, тиздән түгеләчәк», – ди әти. Шуннан аңлыйбыз инде.

Ничек уйлыйсыз, әтиегез сезгә татуировка ясарга рөхсәт бирәчәкме?

Нурсолтан: Һичшиксез, юк! Мәктәптә берәр нәрсәне онытмас өчен кулыма ручка белән язып кайтсам да: «Күпме әйттем – кулыңа язма!» – дип шелтәләп ала.

Рамазан: Әни, 17 яшьләр җиткәч сөйләшербез, диде. Әтинең, белүемчә, безнең кебек чакта татуировка ясатасы килгән, әмма аңа ризалык бирмәгәннәр. Бәлки, ул без үскәч, тормышындагы шул хәлне исенә төшерер дә, рөхсәт бирер. 18 яшь тула да, тату салачакмын дигән максат юк. Кызыкмыйм да.

Сез икегез дә спортта. Спорт белән шөгыльләнү кемнең идеясе иде?

Рамазан: Беренче класстан бишенче класска кадәр самбога йөрдем. Икенче класстан футбол белән шөгыльләнәм. Хәзер үземә яңа клуб таптым. Бу хакта әти-әнигә әйттем. Барысын да үзем хәл иттем.

Нурсолтан: Тхэквондо белән шөгыльләнергә әти тәкъдим итте. Миңа ошады. Кара-кызыл пояска барып җиттем. Әлегә ташлап торырга туры килде. Хәзер минем йөрисем дә килми. Әти кара пояс көтә инде, беләм...

Егетләр, армия турында нәрсә уйлыйсыз?

Рамазан: Армиягә барам. Барасым килә! Мәктәптә алтынчы класстан бирле «Юнармия» хәрәкәтендә катнашам. «Дедовщина», «Бер елыңны бушка уздырасың», – диләр, ә шул бер ел эчендә армиядән чын ир-егет булып кайтасың.

Нурсолтан: Барамдыр инде, әлегә белмим. Әмма миңа «Не служил – не мужик», дигән фикер бөтенләй ошамый...

Үсмерлек чоры. Ата-ана өчен иң зур сынау вакытыдыр бу, мөгаен. Сүзеңне тыңлап, һәрвакыт янында сырпаланган бала көннәрдән бер көнне бөтенләй үзгәрә дә куя. Аның инде үз дөньясы... Бала белән бәйләнешне ничек саклап калырга? Үсмер белән үзеңне ничек тотарга? Бәлки, безнең геройларыбыз тәҗрибәсе дә сорауларыгызга җавап табарга ярдәм итәр. Әнинең генә түгел, әтинең дә, үсмерләрнең үзләренең дә фикерләрен тыңлап карыйк әле. К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры актеры, Татарстанның атказанган артисты Рөстәм ГАИЗУЛЛИН һәм аның уллары РАМАЗАН, НУРСОЛТАН белән сөйләшәбез.

«ТУГАН ҖАНЛЫ БУЛСЫННАР ИДЕ»

Рөстәм, хәзерге заманда күп гаиләләрдә балалар өчен әни – баш. Әти кеше абруйны ничек яуларга һәм ничек сакларга тиеш?

– «Мин – әти!» – дип әйтеп кенә, күкрәк кагып абруй яулап алып булмый. Баланың әтигә карата хөрмәте баштан ук булырга тиеш, чөнки ул – әти. Шуннан соң әни дә әтиегез дип торсын инде ул. Әти кешенең игътибары да бик мөһим. Бала, янына килеп, ихлас нидер сөйли икән, ә син һаман шул телевизор йә телефоннан аерылмый, баш кагып, әйе, әйе, дип кенә утырасың икән, ул башка янына килми инде, үзен тыңлардай башка кешене эзли. Көч белән дә абруй казанып булмый. Еллар үткәч, алар көчлегә әйләнә бит. Абруй гаиләдәге кагыйдәләрне саклаудан, вак детальләрдән җыела ул!

Рөстәм, син тәмәке тартасың, улларыңнан ул ис килсә, нишләячәксең?

– Бу хәл булмады әле, әмма мин моны уйлап йөрим. Училищеда укыган елларым искә төшә... Дөресен әйтәм, үземне ничек тотачагымны белмим. Әмма миндә өмет бар. Яшьләр хәзер башкачарак. Безнең заманда малайлар белән тәмәке тарту, сыра эчү модада иде. Малайлар икесе дә спорт белән шөгыльләнгәч, тәмәке тартмаслар дип, бик ышанам. Тагын шунысын да әйтим әле: әлегә кадәр әни алдында тәмәке тартканым юк. Кыенсынам!

Ике улың да спорт белән шөгыльләнә шул. Бармыйм, ташлыйм дигән чаклары булгандыр. Ничек мотивацияләдең?

– Берсендә Нурсолтан белән тренировкадан соң кайтып киләбез. Баш тренер: «Син ярышка барасың», – диде аңа. Юл буе эндәшмәде, кайтып җитәрәк: «Әти, минем барасым килми», – ди. «Ничек инде барасың килми? Син бит җыелма командада! Тренер әйткәч барасың», – дим. Авыз-борыны салынды моның. Бераз баргач: «Әти, тренер әйтер ул, әмма мин дә бит кеше. Минем бит үз фикерем булырга тиеш», – диде. Сүзсез калдым. Улыма ул вакытта бары 7–8 яшь тирәсе иде! Уйлыйм: бала бит хаклы. Нурсолтан җиңде, бармады, әмма икенче тапкыр барасың дигән шарт белән. Аның еракка йөрисе килмәгән икән. Нурсолтанның тхэквондога йөрү теләге азая башлагач, сөйләшеп бер фикергә килдек. Кара пояс ала, аннан соң шөгыльләнүдән туктаса да, каршы килмим. Ул бит аның үзенә бер һөнәр булып торачак. Әле расписаниеләр туры килмәү сәбәпле тренировкага йөрүдән туктады. Әмма ул барыбер кара пояс алачак! Әйткән сүзе бар – ә егет сүзе бер була ул! Рамазан юлны үзе ярды. Үзе йөри, ошамый икән, туктый. Ә менә футбол җене нык кагылган аңа. Спортта булгач, икесендә дә лидер сыйфатлары бар инде.

Хәзер бит инде психологлар үсмерләргә юк дияргә ярамый, диләр? Бу кагыйдәгә ничек карыйсың?

– Сафсата бу! Бала бераз аңлый башлаган икән, юкны белеп үсәргә тиеш инде ул. Формалашып беткәч, аңына моны ничек кертәсең? Профилактика өчен булса да, кайвакыт юк дип тә әйтергә кирәк.

Егетләр нәрсәнедер яшереп калалар дип уйлыйсыңмы?

– Бардыр инде анысы да дип уйлыйсың. Әмма беркөнне шундый очрак булды, коелып төштем. Кичкенә малайга шалтыратам. «Мин мәктәп янында», – ди, ә мин бу вакытта бер кафе яныннан үтеп барам, карыйм – Нурсолтан утыра. Тагын шалтыратам, ул шул ук сүзне кабатлый. Алдалый бит! Күз алдыңа китер, ялганлый! Икенче көнне кичен барысын да җыйдым. Тыя алмыйм үземне, калтыранам. «Кая булдың теге көнне?» – дим. «Әйттем бит мәктәптән кайтып бара идем», – ди. Ә мин машинадан гына видеога төшереп алган идем. «Бу нәрсә?» – дим. «Бу бит мин түгел, әти», – ди. Инде кызарга әзер идем. Рамазан да: «Әти, аңа охшаган, әмма Нурсолтан түгел», – ди. Әнисенә күрсәтәм. «Ул түгел, әтисе», – ди. Прическа, кара кофта нәкъ Нурсолтан инде менә. «Хәзер бөтен үсмер шулай йөри бит», – ди әниләре. Якынайтыбрак карыйм, чынлап та охшаган гына икән. Аллага шөкер, алдамаган булып чыкты улым. Үпкәләү түгел иде ул, гарьләнү иде. Югыйсә бер вак әйбер генә бу. Ә балалардан зуррак ялганлау ишетсәң, бик авыр булыр, мөгаен.

Уллары әти каешын беләме?

– Каеш белән куркыта гына идем, әмма гомеремдә бер генә тапкыр икесен дә яңаклаганым булды. Йөрәгем әрнеде әрнүен. Уенчык аркасында сугыша башлаганнар иде. Аннан соң кабатлыйм бит, малайлар, дигән сүз генә дә җитте. Мин берүзем үстем, уйнарга беркемем юк иде. Ә алар – иң якын кешеләр! Бертуганнар! Минем өчен бик принципиаль булган бер сыйфат бар: туганлыкны белү. «Бишле»гә укыймы, «өчле»гә укыймы, сугышып кайтамы, анысы мине алай ук борчымый. Иң мөһиме: алар бер-берсен яклый белсен! «Брат за брата» дигән төшенчә бар. Алла сакласын, туганлыкны белмичә яшиләр икән, ул минем өчен иң зур йөрәк әрнүе булачак!

Улларыңны тәрбияләүдә биш мөһим сүз?


– Яхшы гына тембр белән «Малайлар!» дип, вакытында әйтеп куя белергә кирәк. Әнигә, хатын-кызга карата хөрмәтне әти кеше тәрбияләргә тиеш. «Әниегезне бераз уйлагыз инде», дип әйтү җаваплылыкны үстерә. «Әти-әни, мин кайттым», «Әти-әни, мин киттем» дигән сүзләр. Моны балаларда тәрбияләү мөһим. Мин үземне оста куллы кеше дип әйтмәс идем. Әмма үзебезнең фатирга кучкәч, нидер эшлисе, ясыйсы килә. Миңа ярдәм кирәк булмаса да: «Малайлар, килегез әле, менә бу чүкечне тотыгыз әле», – дип чакырам. Эш коралы тотарга өйрәнеп, шуның белән эшләү теләге булырга тиештер инде ул гаилә башлыкларында. «Сез – бертуганнар, иң якын кешеләр!» Әйткәнемчә, бу минем өчен үтә дә мөһим. Абый-эне дигән хөрмәт, абыйларча мәхәббәт булсын. Аны без тәрбияләмәсәк, кем сеңдерә инде.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Фото: Анна Арахамия

АЙНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯГЫ



Аяк астында каты җирне тоймыйм... Соңгы ике елда – коронавирус белән бәйле пандемия башланганнан бирле мондый халәтне безнең һәр-беребезгә кичерергә туры килгәндер. Бөтен дөньяга килгән бу афәтне беренче мәлдә аңлый алмый аптыраулар; «безнең белән хәзер нәрсә булыр» дип куркулар; һәр иртәне рәсми мәгълүматларны караудан башлау: тагын ничә кеше чирләгән, күпмесе терелгән; телләрдә яңа сүз – «локдаун» сүзе барлыкка килү; моңарчы күз алдына да китермәгән чикләүләргә ияләшергә тырышу; якын кешеләрне, таныш-белешләрне югалту; вакцинация ясатыргамы-юкмы дип икеләнү; вирусның яңа штаммын шөбһәләнеп көтү... Кемдер: «Яңача яшәүгә – бу халәткә инде күнектек кебек, беренче көннәрдәге кебек борчылулар күптән юк бит хәзер», – диярgә мөмкин. Әйе, безгә шулай тоела, ә чынлыкта... «Чынлыкта, инде ике ел буе Җир шарындагы бөтен халык бик нык стресс халәтендә яши. Без әлегә сизмибез генә, әмма өзлексез дәвам иткән стрессның кеше организмына зыяны шактый зур аның», – ди психолог, кинезиолог, хатын-кыз программалары тренеры Зөлфия МАКСУТОВА. Стресс халәтендә яшисеңме, әллә юкмы икәнен ничек ачыкларга? Өйдән урамга чыгу, кешеләр белән аралашу күңелдә курку тойгысы тудыра икән, моннан ничек котылырга? Стресс вакытында үз-үзеңә ничек ярдәм итәргә? Әңгәмәдәшебез шушы сорауларга җавап бирер.

Фото: www.pixabay.com

– Күптән түгел миңа бер ханым килде. Икенче баласын көтә. Читтән караганда – хатын-кызның иң бәхетле чагы... Борчулар белән килгән, әлбәттә. «Бизнесым бармый», ди. Мондый чакта, махсус алымнар ярдәмендә, башта кешенең эчке халәтен тикшерәм. Ә аңарда – депрессия һәм шактый җитди: «минем үләсем килә» дигән программа тора. «Нинди куркыныч әйберләр сөйлисез сез?» – ди ул аптырап. Куркытырга теләп әйтүем түгел, әмма әлеге программаны алып ташларга кирәк – ул кешене эчтән җимерә. Бу очракта әлеге ханымның туачак баласына да күчәргә мөмкин... Узган ел миңа тета-терапиягә килүчеләр ике сорау буенча гына мөрәҗәгать иттеләр дисәм дә була: берсе акча турында – анысы аңлашыла инде, икенчесе – депрессия, яшисе килмәү. Элек мондый хәл юк иде... Казына башлагач, хәтта күп вакыт «бизнес туктады, акча килми» диючеләрнең организмында да шушы программа килеп чыга. Яшәргә теләмәгәч, акча кайдан килсен инде ул? Андый чакта акча, гомумән, кирәкми – чемодан җыелган бит инде... Дөрес, стрессның барысын да пандемия белән генә бәйләп булмый. Тормыш бернигә карамый дәвам итә, шуңа күрә стрессның сәбәпләре дә күптөрле булырга мөмкин. Әйтик, гаиләдәге мөнәсәбәтләр (гел акырып-бакырып торган деспот ир һәм боларның барысын «йотарга» мәҗбүр булган хатын), эштәге киеренкелек, төрле конфликтлар, чынга ашмаган теләкләр, үз-үзеңә биргән бәянең түбән булуы, перфекционизм (бөтен нәрсәне идеаль итеп эшләргә омтылу), яшәү урынын алыштыру, кияүгә чыгу яки аерылышу, якын кешеңне югалту, илдә, дөньяда булган фаҗигале хәлләр... Инде шулар янына пандемия үзе белән алып килгән борчылу, хафалану, тынычсызлануны да кушыйк. Ике ел буе көн туган саен яңа хәвеф көтәбез: өйдә бикләнергә мәҗбүр булу, вирусның яңа дулкыны, вакцинация, куар-код...

Стресс кичергәндә, кеше тормыш режимында түгел, ә исән калу режимында яши. Беренчесендә энергия кайнап торса, икенчесендә ул бик аз – бүген, хәзер яшәргә генә җитә. Энергия булмагач, эчтә «яшисе килми» дигән программа кабына... Стресс кичергәндә тән кысыла, куырылып килә. Һәм стрессның берсе дә эзсез узмый – ул тәнебездә кала. Кызганыч, соңгы ике елда тәнебездә мондый үзгәрешләр – психологлар телендә ул блок, «зажим» дип атала – шактыйга артты. Даими стресс халә-

тендә булганда кешенең организмы көчсезләнә – ул бөтен вирусларны үзенә тартып китерә башлый. Иммунитеты төшкәч, энергиясе дә бетә. Максатларга алып бара торган энергиясе... Эшләргә, нәрсәгәдер ирешергә теләге калмый. Аңарда апатия, депрессия, төшенкелек башлана, нык ярсучанга әйләнә.

Стресс халәтендә яшәгәнеңне ничек аңларга соң? Кайберәүләр моны белмәскә, «миндә юк ул» дияргә дә мөмкин. Моның өчен тәнеңә, гәүдәңә игътибар итәргә кирәк. Стресс халәтендә яшәүнең бер билгесе теш казналыгы белән бәйле. Әгәр тешләрне кысып йоклыйбыз, тешләрне төнлә «ашыйбыз» – шыгырдатабыз, йокыдан теш казналыгын кыскан килеш уянабыз, көндез дә тешләрне кысканыбызны сизәбез, казналык авырта икән, димәк, даими стресс кичерәбез дигән сүз. Киеренке халәттә булмаганда, без аларны кысмыйбыз. Авыр чакта, үзебезне кемдер кыерсытканда, түбәнсеткәндә, тәрбияң башкача булганлыктан, аларга нәкъ шундый итеп җавап бирә алмыйча дәшми калганда, эчтәге ачу, ярсу, нәфрәтне тыеп калырга тырышканда кысабыз... Стрессларны «саклау урыны» – астагы теш казналыгы. Барыбызныкы да шунда туплана: ирләрнеке дә, хатын-кызларныкы да. Тешләрне кысып йоклыйбыз икән, йоклаганда ял итмибез, кыйналган кебек торабыз, арып, көн буе хәлсез йөрибез, көндез ятып карасак та, йоклап китә алмыйбыз. Менә ни өчен күпләребезнең 40 яшькә җиткәндә яңактагы мускуллары панцирьга – каты сөялгә әйләнә. Теш табибына баргач, авызын зур итеп ача алмый хәтта. Ә яңактагы бу мускул әллә никадәр башка мускуллар белән идарә итә: алар да киеренке халәткә килә дә, баш, муен, иңбашы авырта башлый. Менә ни өчен даими стресс халәтендә яшәү – ул чир кебек, дибез.

Әгәр стресс бик тирән түгел икән, кеше үз-үзенә ярдәм итә ала. Ничек итепме?

■ Торып басарга һәм килеп туган шул проблеманы – негатив ситуацияне уйлый-уйлый, бертөрле хәрәкәтләр ясарга кирәк: урыннан кузгалмыйча, бер яктан икенче якка селкенергә, үз-үзеңне кулларың белән «кыйнарга»... Бу хәрәкәтләр 10–15 минут, аннан да озаграк дәвам итәргә мөмкин. Башта берни дә булмаган кебек тоела. Аннан әкрен генә күңелдән авырлык китә – нульгә килеп чыгасың. Бераздан инде позитив башлана. Бу – стрессны тән аша алып ташлау. Күрәсез, ул бик гади.

■ Кулларны биткә куябыз да, яңакларны җылытабыз: ике минуттан соң, кулларны урыннан алмыйча гына, ике минут авызны ачып торабыз. Бу күнегүне берничә тапкыр кабатларга – иртән дә, кичен дә эшләргә кирәк. Әйткәнемчә, стресс вакытында киеренке халәткә киләбез һәм үзебез дә сизмичә, теш казнасын кысабыз. Шуның аркасында «зажим» барлыкка килә – мускуллар кысылган килеш кала. Бу урынга кан килми. Мускуллардагы әлеге «зажим»нарны, шушы рәвешле җылытып, әкрен-әкрен генә йомшартырга мөмкин.

■ Стресс кичерәсез икән, шунда ук кайнар су эчегез һәм бөерләрне җылыта башлагыз. Стресс булганда суны, гомумән, күп эчәргә кирәк, әмма берьюлы биш стакан түгел – бөерләргә артык көч китерү кирәкми. Көчле стресс вакытында аларга болай да кыенга туры килә. Организм бик күп итеп адреналин бүлеп чыгара, һәм бу процесста бөерләр дә катнаша. Салкын суны да җылытып тормасыннар дип, аларның эшен азрак җиңеләйтү өчен кайнар су эчәргә кирәк тә. Бигрәк тә – аллергия җәфаласа, томау төшкән, баш авырткан чак булса.

Инде бөерләрне җылытуга күчәбез. Моның өчен бөер урнашкан җиргә туры китереп, бер кулыбызны – алга, икенчесен артка куябыз: «сэндвич» ясыйбыз. Өйдәгеләрнең берәрсе дә булыша ала: сез бөерне алдан җылытсагыз, ул кулын куеп, арка ягыннан җылытырга мөмкин. Әлеге процедура өч яки биш минут дәвам итәргә тиеш. Бөерләр җылына башлауга, стресс китә. Үз-үзеңә ярдәм итүнең кытай медицинасына нигезләнгән бу алымы кинезиологларда бик актуаль.

Сүз уңаеннан әти-әниләр өчен бер лайфхак: әгәр бала мәктәптән нindидер сәбәп аркасында ярсыган халәттә кайтып керә икән, аңа эчә алган кадәр кайнар су бирегез һәм бөерләрен җылытырга керешегез. Бала бик тиз тынычланачак.

■ Магнийлы тоз салып, 15–25 минут ваннада ятып торырга кирәк. Стресс кичергәндә үз-үзеңә «ашыгыч ярдәм» күрсәтү бу. Чөнки мондый вакытта организмнан магний юылып чыга. Ул җитми икән, гел хәлсезлек, күңел төшенкелеге тоясың, баш әйләнә, авырта, күңел болгана, аппетит югала, эч ката, аяк-куллар ойый, чәч коела, тырнаклар сына... Организмда магнийның дәрәҗәсен нәкъ менә магнийлы ванналар ярдәмендә көйләп була, чөнки ул кешегә тән аша сеңә, һәм организм аны бик тиз үзләштерә. Бу тозны интернет аша заказ биреп сатып алырга була. Әгәр андый мөмкинлегегез юк икән, диңгез тозыннан файдаланыгыз. Диңгез ярында ял иткәч, диңгездә коенганнан соң кешеләрнең юкка гына кәефләре күтәрелми, энергияләре ташып тормый шул! Диңгез тозы безне һәръяклап чистарта – аның сере шунда. Ваннада



Зөлфия МАКСУТОВА,
психолог, кинезиолог,
хатын-кыз
программалары тренеры

Хатын-кыз юк кына сәбәптән, ире, баласы яки хезмәттәше бер кыек сүз әйткәнгә дә кабынып китә икән, димәк, ул стресс халәтендә яши дигән сүз. Стресска – киеренкелек хәлендә яшәүгә күнеп булмый. Мондый чакта эшли алу сәләте кими. Йокысызлык интектерә – бүген бик күпләр шуның белән тилмерә. Хәтер начарлана, таркаулана. Игътибарны туплау авырлаша. Пессимизм, хроник ару сизелә. Җәмгыятьтән качасы килү теләге барлыкка килә – кеше белән сөйләшү, аралашасы килү теләге бетә. Аппетит югала. Баш, арка, иңбашы, тезләр, эч авырта. Күкрәктә аңлашылмый торган авырту барлыкка килә. Йөрәк еш-еш кага, тән кычыта... Еш кына кешедә моңарчы булмаган гадәтләр килеп чыга: ул үзе дә сизмичә иренен чәйни башлый, муенын боргалый, чәчен төзәтә...

Хатын-кыз өчен стресс икеләтә куркыныч: ул тиз картая. Стресс аркасында балага узмаска да мөмкин.

ятарга уйлыйсыз икән, башта суда 1–2 килограмм тозны эретегез. Тозлы судан чыкканда җиңеләеп киткәнегезне шунда ук сизәрсез. Ваннага керү мөмкин түгел икән, ләгәндәге суга бер-ике уч тоз салып, 20–25 минут аякларыгызны шунда тыгып утырыгыз. Моны телевизор каршында сериаллар караганда да эшләп була. Һәр кич саен кабатласагыз, нәтиҗәсен тоймый калмассыз: тынычланырсыз, юк-бар борчуларны да зур итеп кабул итми башларсыз – кабынып та китмәссез.

■ Җәяү йөрү. Стресcның нинди ен генә кичерсәң дә, әйтик, ирең белән сүзгә килдең яки җитәкчең белән аңлаша алмадың икән, күңелдә кузгалган давыл бәреп екмасын өчен, иң яхшысы, киенеп, саф һавада – урамда, йөреп керү. Җәяү йөрү – стресстан котылуның иң табигый юлы. Ярсудан туктауның, тынычлануның – иң тиз ысулы. Йөрү – безнең организмда кортизолны бер дәрәҗәдә тотарга ярдәм итә, зыяны ачабыз. Атнасына өч сәгать җәяү йөрү депрессия билгеләрен җиңеләйтә. Атнасына биш тапкыр, көн саен 35 әр минут җәяү йөрсәң, җиңел һәм уртача авырлыктагы депрессиядән котылырга мөмкин.

■ Эфир майлары куллану. Әмма моның өчен даруханәләрдә, кибеттә сатылган эфир майлары ярамый: аларга «100 процент табигый» дип язылса да, бу чынлыкка туры килми. Бик сыйфатлысын – профессиональ ароматерапевтлар куллана торганын алырга тырышыгыз. Иң беренче чиратта, эфир маеның исе сезгә ошавы кирәк – бу бик мөһим. Шул очракта гына ул сезнең эмоциональ халәтегезне җайга салырга булышачак. Исе күңелегезгә хуш килеп бетми икән – нәтиҗә көтмәгез. Әгәр сезгә шатлык хисе, кояш җитеп бетми икән, эфир маеның әфлисун ислесен куллана аласыз. Күңелсез уйларны юып кына төшерәчәк. Грейпфрут ислесен сайласагыз, нерв системасын тынычландырыр, кәефегезне күтәрер, депрессия халәтеннән чыгарга булышыр. Грейпфрут – көчле адаптоген санала. Адаптоген исә организмның барлык төр стрессларга, негативка каршы тору сәләтен арттыра. Тагын литсея кубеба исле эфир маен кулланырга була. Ул – иң көчле адаптогеннарның берсе. Арыганлыкны бетерә, акыл һәм физик активлыкны арттыра, яхшы кәеф, шатлык хисе тудыра. Алдан ук әйтеп куям: эфир майларын ятар алдыннан кулланырга ярамый – төнне йокысыз үткәрәчәксез. Мин үзем аларны уч төбенә бер тамчы тамызам да, ышкыйм һәм 2–3 минут исним – шул җитә. Кабинетта эшләп утырганда, бер пыяла стаканга өч тамчы эфир мае тамызып, компьютер янына куя аласыз. Үзегезгә аннан бер ис тә килми кебек тоелса да, эфир мае үз эшен эшләячәк.

Ике-өч тамчы эфир маен бер-ике грамм диңгез тозы өстенә тамызып, шуны иснәргә дә мөмкин. Ә иң көтелгән нәтиҗәне диңгез тозы белән эфир мае кушылган ванна бирәчәк. Бу очракта өч-биш тамчы эфир маен башта куе сөт өсте яки каймакка кушып болгатырга кирәк. Турыдан-туры суга салырга ярамый: эфир мае суда эреми – пешүегез бар.

■ Негатив мәгълүмат җиткерүче чыганакларның барысын туктатабыз: радио тыңламыйбыз, телевизор карамыйбыз, интернетны сүндереп үк куябыз. Яңалыклар килеп ирешмәсен! Берсе дә! Аларны без берара ишетми, белми торганнан дөнья ишелеп төшмәячәк. Җир шарының кайсыдыр почмагында вирусның тагын яңа штаммын тапканнар икән, аны подъезд төбендә утыручы әбиләр булса да артыгыздан әйтеп калачак.

■ Кәефкә начар тәэсир итәрдәй барлык нәрсәләрдән үзебезне аралыйбыз: үтереш, сугыш күрсәткән фильмнарны карамыйбыз, йөрәккә тиярдәй сериалларны да туктатып торабыз. Таныш-белешләр белән: «Бүген коронавирус белән шуның кадәр кеше авырый башлаган, шуның кадәресе үлгән икән», – дип сөйләшүләрдән качабыз.

■ Кәефне нәрсә күтәрә? Онытылып көлү! Димәк, көлү ярдәмендә дәваланабыз – бер-бер артлы комедияләр карый башлыйбыз. Көлү бигрәк тә күкрәк мускулларындагы «зажим»нардан котылырга ярдәм итә. Рәхәтләнеп, чын күңелдән көлү – стрессны җиңелрәк кичерергә булыша.

■ Үзегезгә ешрак ял итәргә рөхсәт итегез. Арыган, көче калмаган организм стрессларга ныграк бирешә.

■ Массажга барып кайтыгыз. Массаж ясаганда стресс аркасында барлыкка килгән блоклар шулай ук тәннән алына.

■ Күңелегезгә якын, рәхәт, сездә киеренкелек хисе тудырмый торган кешеләр белән аралашыгыз.

■ Үзегезгә нинди дә булса бүләкләр алыгыз – үз-үзегезне беренче урынга куегыз, яратыгыз.

■ Догалар уку да – дәва. Кемдер алар белән дә стресс халәтеннән чыга ала.

■ Иртән үзегез өчен нинди дә булса яңа бер йола – ритуал кертегез. Әйтик, йокыдан торуга тәмле үлән чәе пешереп эчәргә гадәтләнегез. Мондый ритуалны башкарганда сез аның кайчан башланганын һәм кайчан тәмамланганын төгәл беләсез. Һәм бу сездә «мин үз тормышыма үзем хуҗа» дигән тәэсир тудырачак. Аның белән бергә күңелгә иртәгәге көнгә ышаныч тою, стабильлек киләчәк. Американың атаклы бизнес-коучы Тони Роббинсның, мәсәлән, иртәнге ритуаллары өчәү икән: ул башта сулау белән бәйле күнегүләр эшли, аннан тормышта ирешкән бар нәрсәсе өчен Раббысына рәхмәт әйтә, соңыннан һәр көнне аңардан ярдәм, көч сорый – догалар укый.

Күрәсез, ярдәмне еракта эзләргә кирәкми. Күңелдәге тынычсызлыктан – гел каяндыр хәвеф көтеп яшәү хисеннән үзебез дә арына алабыз. Организмга кергән стресс күзгә күренми, әмма ул бар. Айның икенче ягы булган кебек... Вакытында стресс тудырган блоклардан, «зажим»нардан котылмасаң, алар нинди дә булса чиргә әйләнергә, депрессия булып килеп чыгарга да мөмкин. Аларны организмдагы атом бомбасы белән чагыштырып була. Ә бомбалар, беләсез, шартламаса хәерлерәк.

Гөлнур САФИУЛЛИНА

«СИНЕҢ БАЛАҢ!»

Танышларыбыз арасында үрнәк гаилә саналабыз. Талашып, ызгышканыбыз да юк. Әмма күңелемне кытыклап торган бер хәл бар. Без ике бала тәрбиялибез. Икесе дә зурлар инде. Улыбыз институтта укый, кызыбыз мәктәптә соңгы сыйныфларда белем ала. Бала-чаганың төрле вакыты була бит. Алар сүзне тыңламагада, йә соңлап өйгә кайтканда ирем гел «кызың белән сөйләш», «улыңны бераз тый», ди. Баштарак бу сүзләренә бик үпкәли идем. «Минем ияртеп килгәм балам юк, ул синеке дә», – ди идем, хәзер эндәшмим инде. Әмма бу сүз һаман да ачуымны чыгара. Ул бит әтиләре! Аның да балаларга шундый ук хокукы бар, ул да аларны тәрбияләүгә өлеш кертә ала югыйсә.

Люция.
Нурлат районы.

Зөфәр БИЛАЛОВ,
Татарстанның халык артисты:

– Гаиләнең бөтен проблемаларын әти кеше күтәрергә тиеш. Дөресен генә әйткәндә, хәзер замана үзгәрде бит. Элек мондый хәл булмагандыр. Халык гадирәк яшәгән. Хәзер, кызганыч, ирләрдә ир-ат башлангычы көчсезрәк. Тормышка җиңел карау аркасында җавапсызрак ирләр күбәйде шул. Шуңа күрә күп очракта җаваплылыкны хатын-кызга аударып калдыралар. Болай эшләү бик җиңел бит. Ә гаилә проблемаларының иң авырын ир-ат үзенә алсын инде ул.

Зәйнәб ФӘРХЕТДИНОВА,
Татарстанның халык артисты:

– Бездә мондый хәл булмады. Һәрвакыт уртага салып сөйләшәбез. Гаиләсенә җанын бирмәгән ирләр шулай эшли торгандыр. Җавапсызлык инде бу. Бөтен эштә җаваплы булырга кирәк, гаиләдә бигрәк тә. Ул бит кечкенә генә безнең дәүләт. Без Зөфәр белән синеке, минеке дигән әйбергә бөтенләй каршы. Ул яктан Зөфәр абыегыз бик тәртипле, тәрбияле кеше. Аңламый торган кешене сүгеп тә, кыйнап та аңлатып булмый ул. Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән керми, диләр. Шулай да сөйләшеп карау кирәк. Хатын гаиләсе өчен янып яши, ике арада хөрмәт бар икән, ире аңларга тиеш, миңа калса. Гаилә проблемаларыннан ата кеше берничек тә читләшергә тиеш түгел. Без дә ике малай үстердек. Әтиләре белән генә утырып сөйләшкән вакытлар да булды, анысы инде ирләрчә сөйләшү. Малайлар тәрбияләгәндә ул бик кирәк.

Белгеч фикере



Солтания ГАТАУЛЛИНА, психолог

– Консультация барышында йорт һәм балалар мәшәкатен үз өстенә алган әниләр белән еш очрашырга туры килә. Шунысы кызганыч, алар әтине тәрбия процессына җәлеп итүне кирәк дип санамый. «Үзем барысын да булдырам. Мин уңган, булган», – дип уйлыйлар. Миңа калса, бу хат очрагында да балалар кечкенә чакта әти тәрбия процессына җәлеп ителмәгән. Моның төп сәбәбе – әнинең куркуында. (Ул булдыра алмаячак, ул арып кайткан, ял итсен, һәм башка сәбәпләр.) Бу, үз чиратында, әти белән бала арасын ерагайта. Мондый әниләргә, ирләренең сабый бала түгеллеген искә төшереп, әти кешегә балалары белән аралашырга мөмкинлек һәм ирек бирергә кирәк. Бала үскән саен ирләрне балага якынайту кыенрак. Ул баласын ярата, әмма аралаша белми, чөнки аңа өйрәнмәгән. Ә хат язучы ханымга иң беренче киңәшем: үзегезне яратырга өйрәнегез. Һәм балалар белән аралашканда әтине дә читтә калдырмагыз. Гаиләне җыеп тотыгыз. Моның өчен кичке ашлар, ял көннәре бар. Бәйрәмнәр оештырыгыз, табигатькә чыгыгыз, гомумән, бергә булырга тырышыгыз.

PRESSA

БЕРСЕ – УТ... БЕРСЕ – СУ...



Гадәттән тыш хәлләр – алар өчен гадәти күренеш. Һәр туган көннәре диярлек гадәттән тыш хәлләр алып килә... Тик боларның берсе дә шәхси тормышларына кагылмый.
Аларның берсе – ут. Дөрләп яну – Дилүс турында.
Икенчесе – су. Җайлап кына ялкынны басучы, борчуларны юып төшерүче – монысы Наилә турында.



Алсу ШАКИРОВА

Янгыннар бер-берсенә охшамый, бер-берсен кабатламый.

Сайлап алмаган юл

– Беренче янгынга чыкканымны әле дә хәтерлим. Ничек кайтканнарга кадәр хәтерлим... – ди эчке хезмәт подполковнигы Дилүс Мирзегалләмов.

Курку булмаска тиеш дисә дә, тәүге сынавына чыкканда нәрсә уйлады икән япь-яшь янгын сүндерүче? Үзе сайлап алган юл да түгел бит. Авыл малае янгын сүндерүче булып эшләргә хыялланмыйдыр да ул... Авылда ут-фәлән чыкса, бөтен халык бергә сүндерә янгынны. Тракторлар белән су ташып торалар, курыкмыйча ут эченә дә керә авыл абзыйлары. Янгын сүндерүче машинасын күргәне бар иде анысы. Бер көнне мәктәптән кайткач, әти-әнисе: «Улым, янгын сүндерүче булырсың», – диләр. Шунда баргач, өйрәтерләр, имеш. Әти-әни сүзенә каршы килми укытучы булырга уйлаган егет. Тырышып укый башлый. Математика, физика гына түгел, физкультура да бик көчле булырга тиеш икән, белешәләр. Бер ел ныклап әзерләнгән егеткә Екатеринбургтагы янгын сүндерүтехник училищесына укырга керү бер дә кыен булмый. Саба районы Шекше авылыннан өч егет бергә чумалар курсант тормышына.

– Укып бетергәч, юллама буенча Чаллыга, КАМАЗ заводына җибәрделәр. Беренче янгын белән подвалда очрашырга туры килде. Кыска ялганыш аркасында кабельләр яна иде. Разведка ясар өчен подвалга төштек – автоматик янгын сүндерү системасы эшләп торган, билдән күбекле су җыелган. Кабельләрнең барысын да өзмиләр, чөнки бу заводны ике атнага утсыз калдыру белән яный. 50 метр барганнан соң, бер кабельдә ялганыш барлыкка килеп, очкыннар чыкты. Алга да, артка да барып булмый, шундук чүгәләдек. Үзебез дә, алып кергән приборлар да су астында калды. Ярый ул кабель өзелеп төшмәде – эленеп калды. Менә шулай янгынны сүндереп, куелган бурычны үтәдек, – дип искә ала Дилүс.

– Ә кабель су өстенә өзелеп төшкән булса... – диюемне сизми дә калам.

– Нишләтәсең, шуңа да хәтәр, куркыныч хезмәт санала бит, – ди ул тыныч кына. – Янгынны сүндереп чыккач, өс киемнәрен салып машинага элдек тә, көзге салкынча һаваны сулап, җәяү частька кайтып киттек. Безнең смена тәмамланган иде инде...

Билгесезлек эчендә

Дилүс Мирзегалләмов – Казан шәһәренең 7 нче янгын сүндерү-коткару отрядында җитәкче урынбасары. Беренче сынауларына чыккан хезмәттәшләре бүген лаеклы ялда инде. Дилүснең хезмәт стажы да 25 елдан артып киткән. Тик ул әле дә булса куркынычсызлык сагында.

– Әйе, инде туктасам, ялга китсәм дә була. Янгын сүндерүчеләр лаеклы ялга шулай иртә чыга. Әмма тәҗрибә дигән әйбер дә бар бит әле. Аны яшь буынга биреп калдырасы килә. Кызганыч, яшьләр генә бик токтарланмый хәзер. Гадәттән тыш хәлләр хезмәтенә тыныч эш эзләп килмиләр. Наилә бик үгетли, тынычрак эш тап, – ди әңгәмәдәшем, хатынына җылы карашын ташлап ала.

Җитәкче урынбасары булгач, Наиләгә тынычрактыр, кабинет эше, дигән уйны да Дилүс шунда ук юкка чыгара.

– Беренче дәрәҗәдәге янгынга гадәттә ике машина җибәрәбез. Әлеге сан өскәрәк менгән саен, янгын сүндерү машиналары да күбәя, янгынның афәте дә арта бара.

Әнә шул икенче дәрәҗәдән башлап Дилүс үзе дә ярдәмгә ашыга: «Курку хисе, кызгану белән янгын сүндерүче булып булмый. Ут мине көрәшергә чакыра кебек. Беренче көннәремнән бирле әнә шулай кабул итәм», – ди ул.

Фатирлар, йортлар янса, җәрәхәт алучылар, үлүчеләр булса, Дилүс Дәүләт улы беренчеләрдән булып вакыйганың үзәгендә кайный. Тәүлекнең кайсы вакыты булуына карамастан... Шәһәрдән читтә булса да, кичекмәстән бер сәгатьтән эш урынына килеп җитәргә кирәк аларга. Иркенләп туган авылына кайтулар, онытылып ял итүләр дә тәтеми бу гаиләгә. Ә менә «Кайда яна?», «Сүндердегезме?», «Үлүчеләр юкмы?», «Барысы да исән-саумы?» дигән сораулар алар гаиләсендә еш яңгырый. Разведка ясау да күп очракта Дилүс җилкәсенә төшә. Чөнки бу язылган һәм шул ук вакытта язылмаган да закон – янгынга килеп җиткән беренче җитәкче янгын сүндерү буенча җаваплылыкны үз өстенә ала. Ул туп-туры ут эченә атлый. Ә анда разведка ясаучыны нәрсә көтәме? Билгесезлек: караңгылык, ишелеп төшүләр, шартлаулар, көтелмәгән хәлләр, ярдәм көтүче кешеләр...

«Әти! Абый юк...»

25 ел эчендә ничә янгын белән очрашырга туры килгәнен исәпләргә тырышабыз... Санап кына да бетерерлек түгел. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы структурасына карагач, янгыннарга гына түгел, юл-транспорт һәлакәтләренә, су, җылылык трассаларындагы аварияләргә дә ашыга алар. Берара көн саен диярлек янгын чыгып торырга мөмкин. Андый очракларда инде гаиләсен берничә көн күрми Дилүс... Уларының иртән беренче сораулары: «Әти кайтмадымы әле?» – була. Борчылалар... Чөнки һәр янгын әтиләренә куркыныч белән яный.

Үлем ничә тапкыр янәшәсеннән узып киткәнен күп вакыт Дилүс үзе дә аңламый каладыр. Исәбен дә югалткандыр. Казанда булган бер генә зур масштаблы гадәттән тыш хәл дә аннан башка узмаган: газ чыгып шартлаган йортлар, «Булгария» теплоходы баткач, аэропортта самолет шартлагач эзләү-коткару эшләре, заводлардагы зур янгыннар... Бу вакыйгаларның кайберләре гомергә йөрәк түренә кереп калуы гаҗәп түгел.

– Мин катнашмаган бердәнбер янгын «Адмирал» сәүдә үзәгендә булгандыр. Ул вакытта Казаннан читтә – чираттагы ялда идем. Безнең егетләр янгынга беренчеләрдән булып барып җиткәннәр. Хезмәттәшем, подполковник Сергей Костин шул көнне һәлак булды...

Ә менә гаиләне чынлап сынаган икенче фаҗига Дилүсне дә урап узмый. Ул аның үзәгендә кайный:

«Матур гаиләнең төп сере – бер-береңне аңлаудадыр, мөгаен».

гадәттән тыш хәлләр хезмәткәре буларак та, әти буларак та...

– Иртәнге разводтан – киңәшмәдән кабинетларга таралышканда диспетчер мәктәптә атыш турында хәбәр итте. Бу – безнең хезмәт өчен дә гадәти хәбәр түгел. Бәлки, өйрәнүләр барадыр дигән уй килде. Ул арада икенче шалтырату да килеп ирешә. 175 нче мәктәптә атыш! Безнең малайлар укый торган мәктәп икәнен дә тиз генә аңышмадым әле.

Баланы югалту куркынычы, гадәттә, кешенең фикерләү сәләтен тоткарлый. Курку аңны томалый, начарын гына уйлыйсың, паникага биреләсең. Уллары укыган мәктәпкә ашыкканда Дилүстә бу хисләр берсе дә калмый. «Андый вакытта баш икенче төрле эшли», – ди Дилүс. Телефон шалтырый. Ислам! Малай үзенең исән-сау булуын, беренче кат тәрәзәсеннән чыкканын хәбәр итә. «Әти, мәктәп тирәсен әйләнеп килдем, Дамир юк...» – ди олы улы...

Машина мәктәпкә бик тиз барып җитә. Дилүсләр үз эшләренә керешә. Алардан алдарак килеп җиткән янгын сүндерү частьлары ситуацияне контрольдә тота, инде үз эшләренә тотынганнар да. Алар чыгарырга өлгергән сыйныф балалары каршыларына очрый. Шунда араларыннан берсе:

– Әти, мин исән! Абый юк! – дип кычкырып, янына бер малай йөгереп килә. Дамир!

«Бар да әйбәт, улым, абыең чыккан», – дип кенә әйтергә өлгерә дә Дамирга, мәктәп эченә ярдәмгә ашыга.

– Дамирларны юлның теге ягына – балалар бакчасына алып кереп киттеләр. Моны әле дә онытып бетереп булмый, искә төшсә, калтырата башлый... Менүгә, теге сыйныфка эләктем. Носилкалар соратып алдык... Җитмәгәненә ишекләрне салдырдык...

...Аннары мәктәп директоры белән һәр ишекне ачып – тикшереп йөри алар. 200 дән артык баланы чыгаралар шулай. Барлык укучыларны чыгарып бетергәч, сәгать ярым вакыттан соң гына уйлый башлый, хисләренә ирек бирә әти кеше...

Ә кичен Дилүс мәктәп янында дежур торганда, уллары белән Наилә дә шунда килә. Балалардагы куркуны ничек тә җиңәргә, сөйләшергә, кешеләр арасында булырга кирәк дип хәл итәләр. Мәктәпкә укырга барудан баш тарткан уллары белән дә Дилүс егетләрчә үзе сөйләшә:

– Сез ул көнне җиңдегез, бер-берегезне коткардыгыз, башкаларга ярдәм иттегез. Сез дә бармасагыз, башкалар да килмәсә... Дөрес булырмы? Сез – геройлар. Сез ул көнне нык булдыгыз, иртәгесе көнне дә нык булырга кирәк. Бу тарихны онытып булмый, әмма мәктәпне дә калдырырга ярамый, – ди. Малайларга шул сөйләшү җитә.



Наиләсе булганга...

Алар йорты янында басып торган балаларны фаҗига булган ул көнне кем җыеп алып керер иде, кем кайгыртыр иде, әти-әниләре кайтып җиткәнче, тынычлыкларын саклар иде? Киң күңелле, мәрхәмәтле шәфкать туташы Наилә Мирзагаләмова шул ул. Ачкычлары рюкзакларында калган күрше балаларын барысын да үзләренә сыендыра...

Өчесенә бер генә бит ул Наилә! «Әтинең эше янгын чыкканда гына куркыныч, әнинеке көн саен җаваплы», – ди уллары. Ярын читтән эзләмәгән Дилүс. Насыйбы – күрше Явлаштау авылы кызы булып чыга. Курсант егет авылларына ялга кайткач таныша Наилә белән. «Озак очрашмадык, җиде ел ярым гына», – дип шаярта Дилүс. Әнә шулай еллар белән сыналган пар алар.

Дилүс Чаллыдан Казанга күченә дә, «Оргсинтез» заводы янындагы янгын сүндерү частена эшкә керә. Яшь гаиләгә тулай торактан бер бүлмә бирәләр.

– Ислам белән урамда йөрергә чыгам. Һава сулыйбыз, имеш. Бүлмәгә кергәч, өстендәге корымны кагып төшерәм... «Яшь гаилә» программасы буенча үз фатирыбыз ачкычларын алгач карарга бардык та, кире кайтмадык инде без. Миңа матрас белән бер мендәр җитә, беркая бармыйм, дидем Дилүскә, – дип искә төшерә Наилә.

«Наиләнең иң яхшы сыйфаты нинди?» – дип сорыйм Дилүстән.

– Мине аңлап яшәве. Хәлемә керә белүе. Бизмән йолдызлыгында туган кеше буларак, әле бу, әле теге якка тартылып, икеләнеп торсам, ул үз фикерен кистереп

әйтеп куя да, шулай хәл итәбез. Миңа гел аның белән киңәшләшергә кирәк.

«Ашыгыч ярдәм» килеп җиткәнче кемгәдер ярдәм күрсәтергә туры килсә, Наиләгә шалтырата Дилүс. Киңәшләрен бирә хатыны, йә табиблар белән элемтә булдыра. Һөнәргә тугрылык дигән төшенчә Наиләгә дә ят түгел. Ул үзе дә Казанның 8 нче хастаханәсендә дистәдән артык ел эшли. Эпилепсия, ДЦП диагнозлы балалар белән көн саен очраша. Бар җылысын шул балаларга бирергә тырыша.

Гаиләнең төп сере – бер-береңне аңлаудадыр. Юкса Сабантуй кадәр халыкны фатирларына чәйгә алып кайта алыр идеме икән Дилүс? Наиләсе каршы булмасын белгәнгә шулай эшли бит ул.

– Сменалары алдагы көнне алышынган Казандагы бөтен янгын сүндерүче егетләрне, гаиләләре белән җыеп, табигатькә алып чыгам. Хезмәттәшләр белән башкача аралашу бит ул. Гаиләләр, балалар дуслаша башлый. Бәрәңгеләр, коймаклар пешереп, самавырлар кайнатып чәй эчүләр... Матур итеп ял итәбез. Кыш көннәрендә чана шуып арыгач, барысын да үзебезгә чәйгә чакырам. Шушы фатирыбызга зур өстәл сузабыз... Сыймыйлар. Подъезд тулы кеше! Ул бала-чаганы күрсәгез! Чиратлап чәй эчәбез. Мондый күмәк оешкан ялларны гел көтәләр, кайчан чыгабыз дип торалар. Наиләгә рәхмәт: бездә гел кунак, гел кеше.

Алар күз карашы белән аңлашып гадәтләнгән. Дилүс уллары белән артык кырыс сөйләшә башласа да, Наиләнең күз карашы барысын да көйли. Тормыш кадерен, сәламәтлекнең кыйммәтен белүче гаилә шул. Шуңа күрә тынычлыкның, саулыкның, исәнлекнең нинди зур бүләк булуын да яхшы белә Мирзегалләмовлар.

– Эштәге проблемаларны өйгә алып кайтырга ярамый, диләр. Кайта шул... Бүген инстаграмны ачкан идем, бер малай югалган дигән хәбәр белән яңалыклар тулган. Ә ул малай әле күптән түгел генә бездә дәваланып чыккан иде. Кайда икән дип борчылып утырам менә. Укол ясатырга кергәч, бигрәк сөйкемле дип карый идем аңа, – ди Наилә.

– Менә шул халәттән чыгуы җиңел түгел, – дип дәвам итә Дилүс. – Кайтасың да эшне уйлыйсың. Атналарга да сузыла кайчак. Үлем-хәтәр булган очраклар тиз генә җибәрми. Без атна ахырында каядыр чыгарга тырышабыз, велосипедта, чаңгыда йөрергә барабыз. Өй салып чыктык, ялларда шунда ашыгабыз, эшләп бушанабыз.

Дилүс малайлары

Алмаш буын дигәннән, хезмәт дәверендә 23 квалификацияле белгеч тәрбияләгән Дилүс Мирзегалләмовның үзендә дә икәү андый төпле егетләр. Ислам белән Дамир кечкенәдән чын ир булып үсәләр. Тәртип, дисциплина аларның һәр хәрәкәтендә сизелеп тора. Барасы җиргә алдан ук барып басарга, беркайчан да соңга калмаска, төгәл булырга өйрәнеп үсә уллары.

Исламда үзенең дәвамчысын, янгын сүндерүче Мирзегалләмовлар гаиләсенең киләчәген күрә әтисе. Ләкин алай да басым ясамый. Улының күңелен үстереп, эшенә алып бара, бөтен сыйныфларына экскурсия оештырып, үзе эшләгән янгын сүндерү отрядына чакыра. Балалар, илһамланып, канатланып китәләр. Ә Ислам горурлана. Аның әтисе герой бит! Аның өчен чын герой! Холкы белән дә әтисенә охшаган Ислам. Җаваплы, җитди, ышанычлы егет үсеп килә. Өйдә кер үтүкләү – фәкать Ислам эше. Энесе Дамирны биш яшеннән үз җаваплылыгына алып, җәйге лагерьга алып йөри, кирәк булса ингаляциясенә кадәр ясый ул.

«Гадел, ышанычлы, төгәл!» – бу сүзләрне Ислам белән Дамир әтиләре хакында әйтә. Дамир да әнисенең ярдәмчесе, аның турында кайгыртучы егет булып үсеп килә. Шуңа күрә мәктәпкә барганчы бер ел алдан балалар бакчасына костюм-чалбар киеп, рюкзак асып йөргән ул. Укуы да – гел «бишле»гә. Дуслары да – абыйсының дуслары. Бөтен фикере дә абыйсыныкы кебек: «Абый ничек әйтә, мин дә шулай», – дип тора. Иң хөрмәт иткән кешесе дә – Ислам абыйсы. Гаиләдә күреп үскәнне үзләренә шулай таманлый егетләр.

Дилүснең дә, Наиләнең дә эшендә хаталар җибәрү мөмкин түгел. Һәр хәрәкәтләре – кеше гомере өчен җаваплылык тотуга тиң. Тормышларыбыз имин булсын инде. Мирзегалләмовларның тыныч, имин тормышлары шуңа бәйле бит. Гадәттән тыш хәлләр сирәгрәк булсын...

Яхшылык җирдә ятмый бит ул. Көн саен кылганы – бигрәк тә... Дилүс Мирзегалләмов һәм аның гаиләсе өчен сез дә сөенегез әле! Язма әзерләнгән көннәрдә Дилүс Дәүләт улына «Татарстан Республикасының атказанган коткаручысы» дигән мактаулы исем бирелде. Бәрәкәтле һәм дәвамлы булсын!



Килен һәм кайнана… Ике арадагы мөнәсәбәтләрнең матурлыгы, ныклыгы, якынлыгы күбрәк кемнең зирәклегенә, акылына, тырышлыгына бәйләнгән? Иреңнең әнисе үзеңнекеннән тары ярмасы кадәр генә ким булырга тиеш, диелгән динебездә. Ә менә сез моңа ничек ирештегез? Нинди сынаулар, нинди юллар аша уздыгыз? Сөйләгез әле! Башкаларга – бигрәк тә яшьләргә гыйбрәт, сабак, үрнәк итеп сөйләгез.
«Сөембикә» журналы «Килен һәм кайнана» дигән хатлар конкурсы игълан итә. Ул ел дәвамында барачак һәм аларның иң эчтәлеклеләре журнал битләрендә урын алачак. Сездән хатлар көтеп калабыз!

ШӘЛЕНЕҢ АК ӘБИСЕ УЛ



Гөлшат ӘЮПОВА



Әниебезне иртә югалттык без. Әтием Рафаэль, апаларым Римма, Лена, Ләйлә һәм мин ятим калдык. Әни бу дөньядан киткәндә миңа бары 23 яшь кенә иде. Ул чакта әнинең иң кирәк чагы иде миңа… Гаиләдә дүртенчесе, иң төпчеге булгангамы – бик авыр кичердем ул югалтуны… Дөньяда иң сабыр, иң әйбәт әни иде ул безнең өчен. Шул чактан ук күңелдә бер теләк бөреләнде: булачак кайнанам әниебез кебек әйбәт булсын иде, кадерле әниемә биреп бетерә алмаган хөрмәтне кайнанама күрсәтер идем дип Аллаһтан сорадым.

2003 елның июль ае иде. Ренат белән өйләнешергә дигән ныклы карарга килгәч, ул мине әниләре белән таныштырырга дип Шәле авылына – туган йортына алып кайтты. Кайнанам белән күрешү мизгелләре әле дә күз алдымда. Оялып, кыенсынып кына бусагадан атлап кердем. Ишек төбендә кечерәк кенә буйлы, башына ак яулык япкан олырак яшьтәге бер ягымлы апа минем белән «Исәнме, кызым!» дип күреште. Әйтерсең, үз әнием «кызым» дип эндәшә! Менә шунда инде күптән күңелдә йөргән теләгемнең кабул була баруын аңладым. Киленне күрергә дип күрше-күлән, җиңгиләр, апалар, әбиләр керә башлады. Каты итеп, кызу-кызу сөйләшәләр. Күз алдымда яшел, зәңгәр, кызыл, шәмәхә төсләр биешә. Барысы да чәчәкле, борчаклы, эре бизәкле күлмәк-яулыклардан. Аларның «Чө?» дип куюлары да кызык... Безнең якта көйләп сөйләшкәч соң... Үземне бөтенләй башка дөньяда хис итәм. Шунда олы җиңгәләре (мөфти Равил Гайнетдиннең әнисе дә әле ул!), Ренат һәрчак бик яратып телгә ала торган Миңниса апа: «Киленең үзеңә охшаган бит! Елмаеп торулары гел синеке», – дип әйтеп куймасынмы! Тавышыннан ук үз итүен тоеп алдым. Тагын эчкә җылы йөгерде. Никахлашкач, абыйларының кулга кәгазь акча биреп күрешүләренә шаккаттым. Шундый йолалары да бар икән.

Булачак кайнанам бик җитез булып чыкты, шул арада Ренатны икенче бүлмәгә алып кереп тә китте: «Безнең кеше бу кыз! Өйлән, улым, без риза!» – дияргә җаен да тапты. Чөнки Ренатның ни уйлаганы шундук йөзенә чыга. «Йә, ничек? Ошыймы сезгә?» дигән карашын әни кеше тоймыйммы соң инде! Казаннан 360 чакрым ераклыктагы Актаныш кызы Шәлегә килен булып төште менә шулай.

Кайнанамның исеме бик матур – Зәйтүнә. Мәңге яшел зәйтүн агачы дигән мәгънәне аңлата ул. Кайнатам Мирзахәсән ул вакытта мәрхүм иде инде. Ул аны яратып, кыскартып, Зәйтүн дип йөртә торган булган. Тукайның сөйгән туташы Зәйтүнә дә Шәледә укытучы булып эшләгән диләр. Соңрак исә минем хәләл җефетем Ренат (Г. Кариев театрының баш режиссеры) әнисенә һәм әлеге туташка багышлап «Зәйтүнәкәй» музыкаль спектаклен сәхнәгә куйды. Беренче күрүдә үк кайнанам Зәйтүнәгә әни дип дәштем, һәм менә егерме еллап инде ул миңа үз әнием кебек якын кеше. Бергә тормасак та, ул безгә ике-өч айга бер килеп, хәлләрне белеп, атна-ун көн кунак булып китә. Элегрәк, Яңа бистә ягында, Тинчурин урамындагы фатирыбызда яшәгәндә, әни белән Елга портына, Мәрҗани мәчетенә хәтле җәяүләп йөрергә чыга идек. Театрга да бергә барган чаклар күп булды. Берсендә театрга киеп барыр өчен әнигә туфли эзләп, әллә кайларга барып чыктык. Матур да, уңайлы да булсын дип, сайлап йөргәндә кылт итеп үз әнием искә төште. Алабугада укыганда, күлмәк, кофталар алып кайтканым булды аңа. И аның сөенүләре!.. Күр инде, Зәйтүнә әни дә нәкъ шулай сөенә икән бит! «Тап-таман! Бик җайлы!» – дип, аркамнан сөя-сөя рәхмәтләр укый. Күлмәк алгач та, «Гөлшат ала белә ул!» – дип, мине Ренатка мактаган иде. Ә мин үз әниемне күз алдымда тотып сайладым ул чакта. Кайнанам да әнием кебек җыйнак гәүдәле: икесенең дә үлчәмнәре бер... Ниндидер охшашлык бар кебек аларда. Икесе дә йомшак, сабыр, беркайчан тавыш күтәрми торган... Минем әнием Флүрә гомер буе мәктәптә биология укытты. Укучылар бик ярата иде үзен. Кайнанам Зәйтүнә дә мәктәптә, интернатта эшләгән...

Улыбыз Нурлан тугач, әни бала белән кала башлады. Безне премьераларга җибәрә иде шулай. Өйләнешкән генә чакларда Ренат гастрольләргә чыгып киткәндә, берүзенә генә кыендыр дип, әни Шәледән үк килеп җитә яныма. Аның белән икәү санаторийларга да бергә бара идек әле без. Гадәттә, Шәле хатын-кызларын бик чая, усал, диләр. Ә Зәйтүнә әни бер дә аларга охшамаган, ул кешенең җаена гына торып сөйләшә. Юмор белән, туры гына итеп үз сүзен дә әйтеп куя белә. Гаеп таба торган, юкка-барга үпкәләп утыра торган гадәте юк аның. Бервакыт 4 яшьлек улыбыз, әбисе кунакка килгәч, аның сумкасын китереп тоттырган да: «Синең өең Шәледә бит! Кайчан кайтып китәсең?» – дип сорый икән. Берәү булса, килен котырткан, дип үпкәләр иде, ә әни көлде генә. «И улым, сине сагынып килдем бит мин!» – дип, баланы сөя башлады. Аның белән киңәшләшүе дә рәхәт шул. Һәрчак мәгънәле гыйбарәләр белән сөйли, безгә җайлап кына киңәшләрен бирә. «Балаларны берүк каты сүзләр әйтеп ачуланмагыз! Рәхмәт төшкерләре, дип кенә шелтәләгез», – дигән сүзләре күңелгә уелып калды. «Үз балаларымны да, кеше әйберенә кызыкмагыз, хәрамнан сак булыгыз, алдашмагыз, сугышмагыз дип үстердем. Өч әйбер: саулык, тынычлык, тигезлек булса, калганы барысы да табыла...» – ди ул. Әнинең шул сүзләре кагыйдә кебек минем өчен. Ул Нурланга да пәйгамбәрләр тормышыннан гыйбрәтле хикәятләр, тәрбияви әкиятләр сөйләп, аңа динебезнең, туган телебезнең кадерен төшендерә. Өйдә әни барында без икенче планга күчәбез. Нурлан өчен әбисе иң якын кешегә әйләнә. «Без гаиләдә дүртәү яшибез: дәү әнием, әти белән әни һәм мин. Дәү әнием бик күп әкиятләр белә. Аның әкиятләр сөйләвен көтеп алам», – дип язган иншасында.

Авылда гомер итсә дә, әни бөтен ил-көн яңалыкларыннан хәбәрдар. Затлы мулла нәселеннән булгангадырмы, ниндидер эчке культура, зыялылык бар аңарда. Ул әле Мәскәүдә яшәүче мөхтәрәм хәзрәтебез Равил Гайнетдиннең әтисе Исмәгыйль абыйның бертуган сеңлесе дә. Үзем дә китапханәче булгач, Зәйтүнә әни белән әдәбият, сәнгать, театр, спектакльләр турында рәхәтләнеп сөйләшәбез. Теге артист ничек уйнаган? Бу спектакльдә кемнәр катнаша? Тагын нинди премьераларга барабыз? Җитмәсә әле Ренат куясы һәр спектакльне башта миңа, аннан әнигә сөйли, киңәшеп тә ала. «Сөннәтче бабай»ны сәхнәгә әзерләгәндә дә шулай булды. «Әни, ничек уйлыйсың, олы кеше чарасызлыктан нишләргә белмәгән юлчыларга киңәш бирә аламы?» – дип сорады. «Аксакал кеше киңәш бирә инде ул, улым. Һәр авылда булган андый кешеләр», – дигән иде әни. Премьераларга да килә, артисткаларга да, директорга да киңәшләрен бирә: бердәм, тату эшләгез, шул чакта гына уңышка ирешерсез, ди. Бик заманча әби ул безнең: ак яулык, калфактан артисткалар уртасында инстаграмга фотога да төште бер көнне.

Аның бездән башка тагын өч улы, өч килене бар. Улларына әни бик яхшы тәрбия биргән. Кыз балалар да әни

Театрга барса, артистлар сырып ала үзен, алар белән дә уртак тел таба әни.



■ Өебездә әнидән изге теләкләрен ишетү, аны кунак итеп, олы хөрмәт күрсәтүдән дә зуррак бәхет юктыр.

Фото: гаилә архивыннан

дип алай ук өзелеп тормас. Килендәшләрем дә бик уңганбулган. Зәйтүнә әни үзе дә кайнана белән 30 ел тату яшәгән, шуңадырмы, безне – килennәрен кеше алдында һәрчак мактап, үсендереп тора – яхшы психолог ул. Биш вакыт намазын калдырмаган әниебез кайгы-хәсрәтләрне, югалтуларны күтәрергә дә көч тапты: сынмады-сыгылмады. Безгә – балаларына көн саен хәер-догада. Кодагые белән кодасын күргәне булмаса да, көн саен аларны догасыннан калдырмый. Теләкләре бик тиз кабул була аның. Ул килгәч өйләргә нур иңә. Намаздан соң һәм өстәл артында дога кыла: «Ризыкларыгыз мул булсын, тигезлектә яшәгез», – ди. Кичләрен, барыбыз да җыелгач, Зәйтүнә әни үзенең еракта калган яшьлек хатирәләрен сөйли.

Авылның озын толымлы, бик чибәр, үзе тыйнак кызларыннан берсе була ул. Олы абыйсы Исламгалинең дусты Мирзахәсән армиядә чакта Зәйтүнәнең фотосурәтен күреп, шундук гашыйк була, бу кызны ятларга бирмим дип күңеленә салып куя. Армиядән кайтканда аңа – 21, ә Зәйтүнәгә 16 яшь кенә була әле. Мирзахәсән, Исламгали янына килгән булып, өч еллап булачак кәләшенә күз атып йөри. Кайнанама 20 яшь булганны көчкә көтеп җиткерә. 1955 елның 7 ноябрь киче яңгырлы, караңгы була, аяк асты да пычрак. Исламгали абый бик ыспайланып, аягына хром итек өстеннән яңа галошын киеп, клубка чыгып китә дә, бераздан караңгыда сыңар галош белән генә кайтып керә. Әнисе белән сеңлесе Зәйтүнәне галошын эзләргә чыгарып җибәрә. Әниле-кызлы галош эзләргә клуб тирәсенә барып яткан җирдән, яннарына җигүле ат килеп тә туктый. Эшнең нидә икәнен чамалаган Зәйтүнә, куркып, ярдәм сорап кычкырып, әнисенә чытырдап ябыша. Өч әзмәвердәй егет (берсе Мирзахәсән, әлбәттә!) аларны аера алмагач, сиам игезәкләре кебек ябышкан бу икәүне ат арбасына салып, толыпка төреп, Мирзахәсәннәргә таба чаптыралар. Юл уртасында көч-хәл белән әнисен төшереп калдыралар. Менә шулай галош эзләү операциясе кыз урлау белән тәмамлана. Сүзем кайнатам рухына дога булып барсын. Монда да Зәйтүнә әни зирәк акыллылыгын күрсәтә, ничек итсә итә – кайнатамны, әнисеннән рөхсәт сорап, яучы җибәрергә күндерә. Шуннан инде кайнана һәм ир туганнары белән матур гына яшәп китәләр.

Олы килендәшләрем дә Шәледәге элек-электән үк килгән кыз урлау йоласын кызык итеп искә алалар. Иң олы килендәшем Гөлсинә җиңгине клубтан кайтканда иң зур абыйлары Мәгъсүм, иптәшләре белән машинага урлап утыртып, туганнары Камилләргә алып кайта. Иртән әни белән йорт хуҗабикәсе Миңниса җиңги булачак кодагыйларына: «Кызыгыз бездә!» – дип хәбәр салалар. Гөлсинә җиңги армиядән кайткан Мәгъсүм абыйны ике-өч тапкыр гына күреп, ошатып калган булган икән. Ул еллардан соң инде 40 ел узды. Мәгъсүм абыйның киткәненә дә бер ел булды, сүзем дога булып ирешсен. Икенче килендәш Айсылу җиңги белән Җәүдәт абый мәктәптә укыганда ук бер-берсен ошатып йөргәннәр. «Бергә яшьләр туенда утырганда Җәүдәт, әйдә клубка танцыга гына барып килик, диде. Аңа ышанып киттем, – дип сөйли Айсылу апа. – Бераз баргач, Җәүдәтнең иптәш егетләре килеп тә чыктылар, мине култыклап диярлек өйләренә алып та киттеләр. Өйгә кереп кенә чыгабыз, дип әйткән була бит әле үзе. Барып керсәк... әниләр белән алдан сөйләшеп куйган инде болар! Мине күргәч, әни белән әти култык астына мендәр кыстырып, күршеләренә кунарга кереп китте...» Икенче көнне иртән яшь киленгә ит белән бәрәңге кыздырырга кушып, үзләре Айсылу апаның әниләренә җыеналар икән. Чишмәгә суга да барырга кирәк ди. «Яшь булганмын инде, бармыйм дип әйттем», – дип көлә Айсылу апа. Ул чакта Зәйтүнә әни елмаеп кына карап торган да: «Ярар, Җәүдәт барыр бүген, икенче юлы син төшәрсең», – дип куйган. «Мин табада ит белән бәрәңге кыздыра белмим, дим, юри киреләнеп. Җәүдәт тиз генә, мин беләм, бергә әзерләрбез, дип тора... Шул чакта кайнаның биш бала үстереп тә сабыр, акыллы булып калуына сокландым», – дип искә ала Айсылу җиңги ул кызык вакытларны. Бик җор сүзле ул, бөтен кеше белән дә турысын әйтеп сөйләшә. Килен – кайнана туфрагыннан шул.

Мин төп йорттагы килендәшем, Ямаширмә кызы Фәридә белән башка районнардан булгач, урлау йоласы безгә кагылмады. Коръән укытканда, әнинең туган көнендә барлык туганнар төп йортка җыелабыз. Мәҗлесләрдә аш-су әзерләргә Фәридә килендәшкә Гөлсинә һәм Айсылу җиңгиләр булыша. Зәйтүнә әни: «И балалар, бер дә ярдәм итә алмадым шул сезгә», – дип куя. Айсылу җиңги: «Әни, син бурычыңны күптән үтәдең инде, биш бала үстергәнсең, шул җиткән», – дип кочаклап ала.

Хәзер исә Зәйтүнә әнигә 86 яшь, күз тимәсен, сөбханалла. Төп йортта өч буын – төпчек улы Илнур, кече килене Фәридә белән әле егермесе яңа тулган яшь киленнәре Энҗе, оныгы Айнур, аның әле биш айлык улы – әнинең оныкчыгы белән яшәп яталар. Көн саен кәрәзле телефоны тынып тормый әнинең: уллары, күршеләре, авылдашлары, оныклары хәлләрен белешә. Менә шундый мировой кайнана, Шәле авылының ак әбисе Зәйтүнә әни белән без – балалары горурланабыз. Озак яшә, сәламәт бул, әни!

ИРГӘ КЕМ ЯКЫНРАК: ӘНИСЕМЕ, ХАТЫНЫМЫ?



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

Әни кешенең улы сайлаган кызны кабул итмәскә хакы бармы?

– Кешегә кагылган һәр мәсьәлә кебек үк, килен-кайнана мөнәсәбәтләре дә бик четерекле. Өстәвенә, ике хатын-кыз мөнәсәбәте бит әле ул, шуңа күрә аеруча авыр булырга мөмкин. Иң беренче чиратта, килен белән кайнана арасында проблема килеп чыкмасын өчен, үзеңә хатын сайлаганда әти-әниең белән киңәшләшергә һәм әниеңә ошаган кызны сайларга тырышырга кирәк. Иң беренче кагыйдә – шул. Әгәр дә әни кеше кызны кабул итми, «Ул безгә туры килми, ризалык бирә алмыйбыз, аңа өйләнмә», – ди икән, бу очракта ул кыздан баш тартуың хәерлерәк. Без, яшьләр, кайчакта: «Хатыным белән әнигә түгел, миңа торасы бит», – дип уйлыйбыз. Әмма ләкин яши башлагач, тормышка әни дә килеп керә, һәм проблемалар туа башлый.

Әйе, әни кеше син сайлаган кызны кабул итмәскә мөмкин – аның моңа хакы бар. Син яшьлегең белән кемнең кем икәнен аңлап бетермәвең дә ихтимал. Ә әти-әниләр бу яктан тәҗрибәлерәк: алар кызның нәсел-нәсәбен дә карыйлар, һәм дөресрәк фикергә дә киләләр. Һәрхәлдә, килен әниеңә ошаса, тормыш итү күпкә җайлырак булачак.

Ислам динендә килен белән кайнана арасын җайларлык ниндидер кагыйдәләр бармы?

– Иң беренче чиратта, әлбәттә, килен тәрбияле булырга тиеш – олы кешене ихтирам итсен. Монда бит егетнең әнисе – олы кеше, шуңа күрә ул ихтирамга лаек. Пәйгамбәребез: «Әти-әниегезне сүкмәгез!» – ди. Сәхабәләр: «Без әти-әнине ничек сүгик инде?» – дип аптырап калалар. Пәйгамбәребез: «Башкаларның әти-әниләрен ихтирам итмисез, сүгәсез икән, үзегезнең әти-әниегезне мыскыл иткән кебек килеп чыга», – ди. Шуңа күрә ireңнең әти-әнисен ихтирам итү – ул үз әти-әниеңне ихтирам итүгә тиң санала.

Шул ук вакытта сабыр булырга кирәк. Ике якка да. Бер түбә астында хәзер ике хуҗабикә барлыкка килә бит: алар бер кухняны бүлә башлыйлар. Һәм олы кешегә мондый очракта юл куя белергә кирәк. Кайвакыт кайнаналарның: «Мин аны тәртипкә утыртам, өйрәтәм әле», – дип, артык кырысланып киткән чаклары да була. Шуңа күрә кайнана азрак телен тешләсен һәм, әйткәнемчә, яшьләргә юл куя белсен. Әгәр дә килен ниндидер хата җибәрсә, аны матур гына, җай гына төзәтеп җибәрергә мөмкин. Ә киңәшне ул үзе сорап килгәндә генә бирсәң яхшы – болай эшләгәндә яшь килен үзен чын мәгънәсендә хуҗабикә итеп тоячак.

Яшь гаиләдә туган барлык бәхәсләргә, аңлашылмаучылыкларга да катнашуның кирәге юк: сезнең аларга файдага караганда, күбрәк зыян салуыгыз бар. Кыенлыкларны үзләре җиңәргә өйрәнүләре дә мөһим бит.

Кайбер кайнаналар яшьләрне: «Акча тота белмисез», – дип ачулана – авыш күп вакыт шуның аркасында чыга. Әгәр бу чынлап та шулай икән, әни кеше гаепне иң элек үзеннән эзләргә тиештер – улын акча тотарга, сакчыл булырга ул өйрәтмәгән.

Сүзгә килгән чакларда, беренче булып кайнана сөйләшә башларга тиештер: ул – өлкәнрәк, акыллырак, ә акыллы кеше юл куя. Хәтта үзеңнең хаклы икәнеңне белгән очракта да, гаиләдәге тынычлык хакына бу адымга барырга буладыр.

Киленне мактаудан да курыкмаска кирәк: ул берәр эшне сездән яхшырак эшли икән, нигә аңардан өйрәнмәскә? Бер нәрсәне онытмаска кирәк: берәүне дә усаллык белән җиңеп булмый, ә менә яхшылыкка яхшылык белән җавап бирми калучылар сирәктер.

Әгәр тормышта шундый очрак килеп чыга икән, ир кем ягына басарга тиеш: хатыны ягынамы, әллә әнисеме?

– Әгәр инде тавыш чыккан икән, ир, әлбәттә, әнисен сайлый. Һәрхәлдә, дин буенча ир кеше үзенең әти-әнисен сайларга тиеш. Ә кыз бала – ире ягына басарга тиешле. Шуңа күрә кызларны ирен ихтирам итә торган итеп тәрбияләргә кирәк. Ул ирен ихтирам итсә, аны тыңласа, кайнана да бу киленне яратачак. Менә ни өчен егет хатын итеп үзен ихтирам итә белә торган итагатьле кызны сайларга тиеш. Сине ихтирам итсә, ул әти-әниеңне дә зурлаячак – алар арасында берниндi аңлашылмаучылык чыкмаячак. Шул ук вакытта, ир кеше хатыны алдында әнисенә тавыш күтәрергә тиеш түгел. Ул, гомумән, аңа тавыш күтәрергә тиеш түгел. Һәм шулай ук үз әнисе янында аңа хатынын кимсетергә, аны җәберләргә ярамый. Андый ихтыяҗ бар икән – аерым әйтергә кирәк.

Мондый низаг чыккан чакта, ир кешегә иң авыры – ул ике ут арасында кала. Аңа әнисе дә якын, шул ук вакытта хатынын да үпкәләтәсе килми. Хатын кеше ирен: «Йә мин, йә әниең!» – дип сайларга мәҗбүр итәргә тиеш түгел. Әйе, ул сезнең икегезне дә ярата, ләкин бу мәхәббәтләр бертөрле түгел, алар – икесе ике үлчәүдә. Ирегез әнисен сайлый икән – гаилә таркалачак. Сезнең якка баса икән – әнисенең рәнҗүе бар. Ә ул рәнҗүнең кайчанда да булса кире әйләнеп кайту ихтималы да юк түгел – барыбыз да картаячак.

Хәзер бу проблемалар, минемчә, бетеп бара, чөнки яшьләр өйләнешүгә өйдән чыгып китә. Әмма бергә торсалар, ир кеше хатыны өчен өйдә аерым бүлмә булдырырга тырышырга тиеш, бу – проблемаларны күпкә киметер.

АЛМА АБЫЙ





Гөлнур САФИУЛЛИНА

Аның исемен ишетүгә, бик күпләрнең күңелендә иң элек «Әрем исе, әрем тәме...» дигән көй яңгырый башлыйдыр, мөгаен. Бу җырда аның җанына тупланган бар моңы, күңеленең йомшаклыгы, ихласлыгы, чисталыгы чагыла кебек. Аннан күңелдә бер-бер артлы ул уйнаган рольләр калка: Булат («Зәңгәр шәл», К. Тинчурин), Ильяс («Казан сөлгесе», К. Тинчурин), Марат («Туй алдыннан», Х. Вахит)... Әйе, ул безгә – татар тамашачысына бик якын. Туганнарына Алма абый кебек якын... Ул – үзебезнеке!
Сүзнең Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Әсхәт ХИСМӘТ турында барганлыгын күптән аңладыгыз инде. Татарстанның халык артисты, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орден медале иясе. 1951 елның 28 декабрендә Әлки районы Түбән Әлки авылында туган. «Шул әремнәр исе тула, / Сагыш дигән яраларга», дип җырлый ул. Гомер озын – анда сагышы да, шатлыгы да, уңышы да, югалтулары да җитәрлек. Шулар хакында сөйләшәбез – истә калган мизгелләрне барлыйбыз.



ТАМЫРЛАР Мин бик бәхетле – әби-бабай белән үстем. Әнинең әнисенә әбзәни дия идек. Дөньяда ике яхшы әби булса, шуларның берсе безнең әбзәни иде. Ураза вакытында сәхәргә уятканнары истә. Ул вакытта да каяндыр җимешләр тапканнар: шуны урталай бүлеп булса да бирә иде. Әбзәни намазын укыганда, кыска гына догаларны син дә өйрәнеп каласың. Кечкенә чакта күңелгә кергәннәр бер дә онытылмый икән...

Дәү әти дә, әбзәни дә җырларга яраталар иде. Әбзәни мөнәҗәтләр әйтә, «Йосыф-Зөләйха кыйссасы»н яттан сөйли. Аны тыңлаганда күзләргә яшь килә... Дәү әти сельпода атлы эштә. Үсә төшкәч, мине гел үзе белән атка утыртып йөрде ул. Сельподан товар төйибез дә, күрше авылга конфет-печеньелар илтәбез. Сөйләшә-сөйләшә барабыз, кайтабыз. Мин мәктәпкә кергәч, дәү әти сумка белән бишмәт алып кайтып бирде. Кайдан алган булгандыр. Беренче оныклары булгач, бик яраталар иде мине. Әнине дә яраталар иде алар. Тырыш булгангадыр. Әни бөтен эшне эшли: ат җигә, сыер сава, утын кисә, утын яра, ирләр белән беррәттән печән чаба... Үзе сулагай әле. Дәү әти гел: «И-и кызым, сиңа ир-егет булып туасы калган», – дия торган булган.

Без башта әтинең әниләрендә тордык. Өйдә низаг чыкмыйча тормый бит инде, әни белән дәү әни нигәдер сүзгә килделәр дә, әтиләр башка чыгарга хәл иттеләр. Өебез инде

салынган, тик эшләнеп кенә бетмәгән иде. 1958 ел бу. Кайдан хәтерлимме? Әтинең өй кыегына менеп, «1958 ел» дип язып куйганы бүгенгедәй күз алдымда... Дәү әни миңа улым димәде, «наным», дип дәшә иде. Чит кешегә әйткән кебек... Әнине нигәдер ошатып бетермәгән шул. Әмма аның ахыргы сулышлары әни кулында булды. Язмышыңнан беркая да китә алмыйсың, чөнки шулай язылган. Үзенең сигез баласы бар иде югыйсә.

Әти белән әни икесе дә җырлыйлар иде. Мәҗлес күтәрә торган җор кешеләр, әти үзешчән сәнгатьтә дә катнашты, укытучылар белән спектакльләрдә уйнады. Әни колхоз эшендә булды, бозау карады, сыер сауды. Әти механизатор иде. Кыш көне фермада эшләде, җәен – комбайнда. 4 нче класстан алып 9 нчы класска кадәр, иң кечкенә сеңелкәштән кала, һәркайсыбыз әти янында комбайнер ярдәмчесе булып эшләде. Безнең әти колхоз эшеннән кайтып кермәде. Ә әни бик булдыклы иде шул!.. Бер очрак истә. Өйгә кунаклар килергә тиеш. «Абый, табын корырга зур өстәл кирәк!» – ди әни. Аралары дүрт ел гына булса да, әтигә ул кайвакыт шулай «абый» дип дәшә иде... Әти нәрсәдер эшләп йөргән арада, әни такталарын да тапкан, өстәлне ясап та куйган... Әле дә баз өстендә тора ул ясаган өстәлэскәмияләр. Авылда кемгә кирәк, шул алып тора. Узган җәй «урам көне» уздырганда да әни өстәлләрен куйганнар.



БАЛАЧАК Зарланмыйм, ипигә туеп яшәдек, әмма конфет-шикәр алда тормады. Мин урлап булса да ашый идем анысы. Әни шкафны бикләп тә карый, аннары ачкычын югалтып тилмерә. Иртән мәктәпкә киткәнче кабартма белән чәй эчәбез. Повидло булмаган көнне әни песок бүлеп бирә. Башкаларга бер кашык, миңа икене. «Алма абыйга икене!» – диләр кечерәкләр. «Тавышланмагыз, Алма абыегыз зур инде ул», – ди әни. Бездә Алма абый дип әйтү бар, хатыныма менә Алма апа диләр.

Гаиләдә олы бала булгач, уйнап йөрү бик эләкмәде миңа – бөтен эшне эшләп үстем. Газ плитәсе юк, керогаз гына. Ул озак кайный, корымлый. Керогазда пешермәсәң, казан астын үрләтәсең. 20 литрлы зур казанга ике тустаган су салып аш пешерергә кирәк. Бәрәңге турыйсың, йомырка туглап саласың. Иң тиз пешә торган аш! Ашны сосып алгач, казанын чистартырга, су салып куярга кирәк... Кер үтүкләү дә минем өстә. Күмер үтүге белән балитәкле күлмәкнең һәр итәген үтүкләп кара әле син! Бөтен эштә тәртип булырга тиеш иде. Су алып кайткансың икән, өстен ябарга, көянтәңне урынына эләргә кирәк. Урынына куймасаң, шалт Мөхәммәтҗан, көянтә белән башыңа...

Кыш көне атна саен әни алты ипи сала, ә миңа он иләргә кирәк. Җәй көне булса – бер хәл, ә кышын он бик салкын, туңдыра. Башта җиренә җиткереп или идем, үсә төшкәч исә хәйләгә керештем: нечкә иләк белән башлыйм да, бик тиз эре тишеклесенә күчәм – аннан он тиз төшә. Әнинең ипие бер тапкыр уңмады, ике... Әни шуннан сизеп алды, «малай актыгы» дип ачуланды.

Балачак дигәндә искә төшә торган тагын бер мизгел бар. Авылга кино килә. Бик барасы килә, тик акча юк! Күкәй тапшырсаң була да, тик урлаганыңны әни шунда ук сизәчәк – тавыклар көнгә ничә йомырка салганны белә ул. Әбзәнигә керәм. Кереп исәнләшәм дә, бусагага утырам – әбзәни намаз укый. Бераз көтеп торгач: «Ярар, китәм», – дим. Ул идәнгә суга – «көт» диюе. Догаларын кылып бетерә дә: «Нәрсә, балам, нишләп йөрисең?» – ди. «Кинога барасы иде...» – дим. «Акчаң юкмы?» – дип, ул кесәсеннән биш тиен акча чыгара...



УКУ Безне мәктәптә озын тәнәфестә чаптырмыйлар иде: түгәрәккә басабыз да, җырлап әйләнәбез. Мин дә җырлыйм. Ә берсендә, ата-аналар җыелышында чыгыш ясаганнан соң: «Бала-чага башың белән мәхәббәт җыры сайлагансың», – дип ачуландылар. «Әрәмәдә карама, карамада йолдыз бар, / Караңгы дип килми калма, / Ай булмаса, йолдыз бар», дигән көй иде ул. Еладым да шуннан җырлауны ташладым.

6 нчы класста укыганда «Кошлар көне» үткәрәбез. Асия Мингалимовна: «Җырларга кирәк, югыйсә чирегеңә «икеле» чыгарам», – ди. Җырлый белгән килеш, «икеле» алып булмый бит инде... Әтинең ботинкасын кидем, чалбар үземнеке бар иде. Әни сеңелләренә ак күлмәк сорарга китте. Җизни – шофер, акчалы. Күлмәкне биргәннәр, тик җизни: «Буй җиткән малаегызга бер күлмәк ала алмыйсызмы?» – дигән. Әни елап кайтты... *(Елый.)*

Без гел җыр тыңлап үстек: Усман Әлмиев, Сөләйман Йосыпов, Фәридә Кудашева, Таһир Якупов, Гөлсем Сөләйманова, Әлфия апа, Илһам Шакировны... Патефоныбыз, пластинкалар бар иде. Әтиләр сигез туган: бөтенесе таралган, авылда ул гына калган. Орскидагылары Әлкигә бер күчеп кайттылар, бер киттеләр. Кире киткәндә әйберләрен калдырып киттеләр: патефон калды, өч ишекле шкаф... 9 нчы класста «Кем булырга телим?» дигән темага сочинение язарга бирделәр. Хәзер аны инша диләр. 42 бала арасыннан бер мин «артист булам» дип яздым. Мәктәптә татар телен һәм әдәбиятын яраттым, укытучы Наилә апаны үз иткәнгәдер. Кайбыч районы Кошман авылыннан иде ул. «Яланаяклы кыз»ны без аның туган авылында төшердек.

Элек укучыларга клубка чыгарга ярамый иде. Спектакльгә барырга да рөхсәт итмиләр. Безнең әнинең концертка исе китми, үзем дә җырлыйм ди, ә спектакль карарга ярата. Күчмә театр еш килә иде ул елларда. Әни завклубка: «Артистларны безгә керт», – дип әйтеп куя. Наил абый Шәйхетдиновның кызы Миләүшә бездә бәрәңге чүпләшкәннәрен әле дә искә төшерә... Спектакльдән соң кайткач, артистлар чәй эчәләр, сөйләшеп утыралар.

Мәктәпне 1969 елны тәмамладым. Мине фермага учетчик итеп чакырып килделәр. Ферма мөдире, бригадир, председатель үзе... Әни аларга: «Беркая да бармый! Тешем чыкканнан бирле колхозда чиләндем, бер рәхмәт ишетмәдем, рәхәт күрмәдем», – диде. Миңа исә: «Улым, бар, җыен да Казанга кит!» – дип әйтте.

Мәктәп елларын уйласам, бер хатирә исә төшә. 9 нчы класста укыганда безнекеләр Волгоградка барды. 42 бала арасыннан бер мин калдым. Акча юк... 27 сум акча кирәк иде. Елыйм, ә әни ачулана: «Күрмәгән җиренң калмас әле», – ди... Театрда сәхнә хезмәткәре булып эшли башлагач, 1977 елда Әстерхан–Баку ягыннан гастрольдән кайтканда

Фото: Анна Арахамия

Волгоградта туктадык. «Ватан-ана» скульптурасын өч тапкыр барып карадык! Театр белән ике тапкыр Финляндиягә, хәтта Пекинга кадәр бардык. Әнинең сүзе рас килде!



УҢЫШ Минем бит хыял – артист булу! Казанда әнинең апасына килеп урнаштым да, киттем консерваториягә. Барып таптым. Бер бүлмәдә ике апа сөйләшеп утыралар. Соңыннан белдем, аның берсе җырчы, педагог Зөһрә Бәйрәшева булган. «Җырчы буласым килә», – дим. «Хуш, авылым»ны, Мансур Мозаффаровның «Туган як» җырын җырлап күрсәттем. «Синең соң музыкаль белемең бармы?» – диләр. «Юк, апа», – дим. «Энем, 1 сентябрьдә кил, әзерлек группасына алабыз», – дип озаттылар. И-и, миндәге сөенечне күрсәгез! Артист булам бит! Ышанасызмы, консерваториядән Зорге урамына – әтинең апаларына кадәр җәяү кайттым. Утыз күкәй күтәреп! Минем арттан ук җизни дә кайтып керде, табын янына утырдык. Апа мактана: «Әсхәт консерваториягә укырга керә менә», – ди. Җизни кашыгын ук күтәреп бәрде: «Авыз күтәреп җырлап йөрү мужик эшемени?!» – ди. Иртәгәсен ул мине РТИ заводына ияртеп китте, корым цехына урнаштырды. Кирза итек, комбинезон, респиратор, бияләй бирделәр. Көне буе зур капчыкларга корым төядем... Ә өченче көнне әнинең энесе: «Син ул корым цехында ярты елда харап булсың», – дип, төзелешкә алып китте. Монтажник булып эшли башладым. Казаннан чыгып китә торган җирдә Нефтьчеләр бистәсе бар иде: конторабыз да шунда, тулай торагыбыз да. Бер көнне карыйм: «Укытучылар йорты» егетләр-кызлар кабул итә», дигән игълан тора. Эзләп барып таптым. Түгәрәкнең җитәкчесе Хәбип абый Хәбипов икән, ул Камал театрында эшләгән булган. Җыр түгәрәге дә бар – анда да йөрим. Бер ел шулай узды. Армиягә алар яныннан киттем, 1972 елның җәендә, Казан Сабан туе көнне аларга әйләнеп кайттым.

Тагын ике-өч ел узды. Берсендә тулай торакка мәдәният институты кызлары килеп керде. Диплом спектакле чыгарырга егетләр җитми икән. Биш кызның берсе миңа: «Үзең төзүче, ә үзең «Дом Учителя»га йөрисең», – дип куйды. Шул сүзгә карап, Төзүчеләр мәдәният йортына күчендем. «Сәрвиназ» вокаль ансамблендә җырлый башладым. Кирам Сатиевнең яшь чагы: ул, Рәфкать Гомәровка охшатып, басып баянда уйный, мин Илһам Шакировка охшатып җырларга тырышам. Илһам абыйның бер концертын калдырмыйм. Телевизорымны сатып, батарейлы «Весна» магнитофоны алдым. Илһам абыйның һәр концертына барам, яздырам, җырларын өйрәнәм... Баянчысы белән танышкач, концертларга бушлай йөри башладым. Иң алгы рәткә утырам, чәчәк менгезәм.

Бер репетиция вакытында Мәсгут абый Имашев килеп керде. Ул элек монда эшләгән, киткәндә үз урынына Фатыйманы калдырган икән. Хәл белергә килгән. «Әсхәт һәр көнне яңа җыр алып килә, өйрәнеп өлгермибез», – ди аңа Фатыйма. «Сәфәр» җырының чыккан вакыты – шуны җырлап күрсәттем. Дәрес беткәч, яныма килде дә: «Театрда эшлисең килмиме?» – диде. «Мине анда кем алсын?» – дим. Мәсгут абыйның Камал театрында эшләгәнен дә, Булатны уйнаганын, спектакльләргә көй язганын да белмим бит... Марсель Хәкимович белән мине ул таныштырды. «Җырлый беләсеңме?» – ди. «Туган як»ны суздым: «Кешене иленнән, йортыннан аерып, / Йөреткән илләр бар, җирләр бар...» Аннан – «Күн авылы» көен. «Төзелештә күпме акча аласың?» – дип сорады Марсель абый. «110 сум», – дим. «Бездә бит андый акчалар юк, 60 тәңкә генә түлибез», – ди. «Минем артист буласым килә», – дидем... Театр училищесының икенче курсына алдылар мине. Укыганда Марсель абый мине «Зәңгәр шәл»дә шәкерт җырын җырларга да чыгарды. Ул рольне Барый абый Әшрәпов уйный иде. Заманында, Кәрим Тинчурин аклангач, Шириаздан абый Сарымсаков «Зәңгәр шәл»не кабат куя һәм әле беркем белмәгән Илһам Шакировны шушы шәкерт җырын җырларга чакыра. Спектакль тоташ бер ай буе бара. Шәкерт җырын һәр кичне халык кабат сорап җырлата...

Миңа Әлмәттән, Минзәләдән, Күчмә театрдан һәм Камалдан заявка бар иде. Әлбәттә, Камалны сайладым. Ризван Хәкимнең «Синең урынга кайттым» спектаклендә Көтүче ролен бирделәр. Аннан Хәй Вахитның «Талак, талак» спектаклендә Мирсәет ролен. Җырлы роль! Һәм, күз алдына китерәсезме, шул елны Ринат Таҗетдинов «Диләфрүзгә дүрт кияү»дән миңа Җәмил ролен бирә. Үзе гөрләтеп уйнаган җирдән! Дәфтәргә рольне язып ук килгән иде. Язуы шундый матур аның. Зур сәхнәгә аяк басуга ике җырлы роль! Бу, әлбәттә, уңыш иде. Ә театрның яңа бинасына инде «Зәңгәр шәл»дә Булатны җырлап кердем...

Шулай да халыкка мине күбрәк телевизордан барган сериаллар таныткандыр. Күп булды бит алар: «Яшьнәп үткән яшьлек», «Мыраубатыр», «Габбас хәзрәт», «Китәм димә», «Яланаяклы кыз», «Ерактагы якты йолдызым», «Җылы эзли җаннар», «Авыл эте Акбай»... Өлкәнрәк тамашачылар очратып: «Әсхәт, безнең балалар синең Акбаең, Кыш бабаең белән үсте», – диләр. Кыш бабайны бик яратып уйнадым! Хәзер замана үзгәрде, бүгенге Кыш бабай твист бии, сакалы төшеп китә, егыла... Тик мин ул шамакай булырга тиеш түгел дип саныйм. Әле дә балаларны Кыш бабайга, аның могҗизасына ышандырып буладыр.



МӘХӘББӘТ Беркайчан да: «Мин болай булмыйм», – дип әйтергә ярамый... Авыл егетләре кызлар янына башка авылларга йөриләр, ә мин күрше кызына гашыйк. Дөрес, ул мине якын итмәде... Егетләргә: «Нигә ерактан эзлисез, үзебездә дә кызлар бар бит», – дим. Ә аннан үзем 12 чакрымдагы Карамалыга барып йөрдем! Җәй чилләсендә салкын тидерә-тидерә. Без аның белән бер концертка җырларга баргач таныштык. Бик чибәр иде ул. Бөдрә чәчле! Мин аның янына велосипед белән барам. Барганда әле яктырак була, кайтканда инде караңгы – ай гел булып тормый. Җитмәсә, велосипедның фарасы да ватылды. Юл буе кычкырып җырлап кайтам: бүре-мазар чыкса, куркытам, имеш. Берсендә Чирмешән елгасы аша салынган басмага кергәндә, аяк педальдән ычкынды да, елга кырыена ук салынган мунчага барып бәрелдем. Кәкрәйгән велосипедны җилкәгә салып кайттым. Көтү куалар иде инде. Ә әти иртүк велосипед белән эшкә китәргә тиеш... «Әбзәни, әйдә, чык әле, турайтык», – дим. Рәтләгән кебек булган идек тә,

әти тотынуга велосипед таралды... Ул кыз да: «Мин сезнең авылга беркайчан бармыйм!» – дигән иде. Нинди бармау! Кинофикациядә укыды да, юллама белән аны безгә эшкә җибәрделәр. Шушында кияүгә чыкты, балалар тапты, кабере дә бездә дип беләм.

Аннан «Укытучылар йорты»ндагы бер кызны яратып йөрдем. Армиягә озатып калды, тик ярты ел гына хат язды да, туктады. Солдаттан кайткан көнне үк янына бардым. «Барып сорасаң, кияүгә чыгам», – ди. Ә ул Киров өлкәсеннән иде. Поездга утырып киттем боларга... Алар авылына паром белән елга аша чыгасы икән әле. Бер кич кундым, шартын китереп, әти-әнисеннән кулын сорадым. Уйлашырбыз дип калдылар. Авылга кайтып төшүгә: «Өйләнәм», – дидем. Әни мин исән-имин әйләнеп кайткан хөрмәткә аш уздырды. Ак яулыклы апаларның кайсы: «Хәерле булсын», – ди, кайсы: «Иртәрәк», – ди... Киров өлкәсеннән дә хәбәр килеп җитте. Әнисе: «Яшь куенда камчы бар, камчысы да бал белән, карт куенда калач бар, калачы да кан белән», – дигән. «Юк» дигән сүз иде бу...

Равил хәзрәт Гайнетдин белән Зөһрәнең туенда исә Нурания белән урыннарыбыз кара-каршы туры килде. Хәер, ул чакта Равил хәзрәт түгел иде әле. Нурания белән өйләнештек, ике кызыбыз туды. Туйдан килүгә, мине театрга чакырдылар. Нурания: «Тулай торактан бүлмә бирсәләр дә ризалаш», – дип озатып калды. Мин исә «әби берүзе яши, бергә торырбыз» дип уйлап йөргән идем... Театр көтмәгәндә фатир ачкычы бүләк итте! Ике бүлмәле фатирның зур ягында театрның труппа мөдире Мәрьям апа Чанышева тора иде, кечкенә бүлмәсендә – без. Нинди тәмле әйбер пешерсә дә, иң элек безгә кертә иде Мәрьям апа. Алты елдан соң Ирек абый Баһманнарга яңа фатир бирделәр дә, аларныкына без күчендек. Тик дүрт аяклы ат та абына, диләр – Нурания белән бергә яшәп бетә алмадык... Ә аннары юлымда Рәшидә очрады миңа. Туасы җаннар булган, димәк. Беренче хатыным исә күптән вафат: Дөбьязда җирләнде, туганнары янында... Йөрәк, операцияне күтәрә алмый, диделәр...

Бөтен җирдә язалар, «икенчегә өйләндең икән, тегесен искә төшермәскә тиешсең», диләр. Әмма бит ничә еллар гомер иткән беренчесенә ияләшкән буласың... Тик сине тиң күреп килгән хатын-кызның да бер гаебе юк – шуның өчен җайлашырга кирәк тә. Беребез дә әүлия түгел...
Әле әни белән әти искә төшә. Әни соңгы вакытта урын өстендә ятты. Әтине ачулана: «Бөтен яшьлегемне алдың», – ди. Ә табиб килгәч, белер-белмәс русчасы белән аңа: «Это моя первая любовь!» – дип сөйли.



МАВЫГУ Телевизордан хоккей карарга яратам. Яшь чакта уйный да торган идек. Әти тимераяк сатып алган иде – итеккә бәйли торганны. Утынга баргач, әни исә кәшәкә ясарга кәкре агач кисеп бирде. Ә җыр... Җыр – ул күңел халәте! Күңел тулса да җырлыйм мин... Әмма хәзерге җырларның берсен дә белмим. Алар никтер бер-берсенә охшаганнар – тиз генә отып булмый. Аннан әллә кайдан җырны сатып алу гадәтен уйлап чыгардылар. Рөстәм абый Яхин әнә: «Теләсәләр – җырласыннар, җырым гына яңгырасын», – дия торган булган... Әйе, элеккеге җырлар башка бит алар. Минә Роберт Әхмәтҗанов сүзләренә язылган «Хәтерләү» дигән җыр бар: «Кырга чыксам җылы җилләр, / Чәчтән сыйпап иркәли. / Кырда искән таң җилләре, / Синнән сәлам микәнни?» Мин аны 1968 елны озатканда, багана башындагы радиодан ишеткән идем. Башта Илһам абый язмасында, аннары – Флера апаныкында. Шуннан бирле җырлыйм менә...



АКЧА Лотереяга бер акча отып карыйсым килә. Аллаһы Тәгаләдән дә сорыйм: «Бер бир инде – тикшереп кара мине», – дим. Уйлап ятам, миллионнар отсам, менә бу сеңелгә бирер идем, дим, кызларыма, мәчеткә, мәктәпкә... Аннан театрга күчәм: Алмазга бирер идем, башкасына... Болай бүлгәч тә, үземә күп кала әле. *(Көлә.)* Яңа ел тирәсендә 1 мең сумга ун лотерея алган идем, өчесе отты: 100–50 сумнар тирәсе...



БАЛАЛАР Дүртәү алар минем. Олы кызлар икесе дә гаиләле инде – мине оныклар белән сөендерделәр. Берсендә – өчәү, икенчесендә – бераү! Илсөярнең артист буласы килгән иде менә. Аның каршында гаебем бар – моңа риза булмадым. Әмма дөрес эшләдем дип уйлыйм. Театр кухнясы, артист тормышы яхшы таныш бит миңа. Булатны исә белә торып сәнгать дөньясына керттем. Үзем гармунда уйный алмагач, аны 6 яше тулганчы ук баянга бирдем. Өйдә дәрес әзерләгәндә елашып бетә идек: «алай уйна, болай» дип өйрәтәм – үзем дә белмәгән килеш... Музыка мәктәбен кызыл дипломга тәмамлады. Укытучысы Любовь Семеновна: «Училищега керсен инде», – диде. Аннан да «кызыл диплом» белән чыкты. Консерваторияне дә тәмамлады. «Менә сиңа 10 сум акча, татар көен өйрән», – дия идем. Үзе акча эшли башлаганчы, өйрәнде, аннан ташлады. Берәр мәҗлескә эшләргә бара да, шалтырата хәзер: «Әти, теге көй ничек әле?» – ди. Көйне искә төшерәм, билгеле, әмма: «Мин бит сиңа өйрән дип әйттем!» – дигән сүзне дә кабатламый калмыйм...

Балалар белән аралар якын, шөкер. Алар дүртәү дә үзара аралашалар. Илсөяр белән Булат апаларының балалары белән тәгәри-тәгәри уйныйлар.




КУРКУ Үләсе килми! Әти 94 яшенә җитеп үлде: «Их, дөньялар да матурайды, китәргә генә вакыт җитте. Яшәмәгән дә кебек... – дия иде мәрхүм. – Сугыштан кайткан кешеләр әллә кайчан китеп бетте, хәтта миннән яшьрәкләр дә», – дип уңайсызлана иде. «Син бит алар өчен дә яшәргә тиеш, әти», – дия идем. Юк, үләсе килми бер дә! Якты дөнья кала...



ҮЗЕМ ТУРЫНДА ҮЗЕМ Мин – турысын әйтә торган кеше. Әни дә шундый иде. «Туры йөрсәң, баш тия, улым», – дия иде ул. Туры әйткән туганыңа да ярамый, диләр бит: дөресен сөйләсәң дә, ахырда барыбер үзеңә эләгә... Чын күңелдән әйтәм дә, шунда ук суынам да. Кызу инде мин. «Нигә кычкырасың?» – дигәнне еш ишетәм. Театрда да шулай... Хәзер үзгәреп булмый торгандыр инде. Бөкрене кабер генә турайта, диләр.

КЕШЕНЕҢ ИСЕМЕ – АНЫҢ ЯЗМЫШЫ

Җаннан җан яралу, бала туу! Дөньяга яңа кеше аваз салу! Яшәешнең иң зур могҗизасы, иң зур сере шушы түгелме?! Мөгаен, шулайдыр! Юкка гына һәр әти-әни өчен ул тормышта бөтен нәрсәдән дә истәлеклерәк вакыйгага әйләнми. Гомер-гомергә шулай булган!


Фото «Тартарика. Этнография» атласыннан алынды.

Халык арасында таралган, бала туу белән бәйле гореф-гадәтләрнең, йолаларның берсе дә юктан гына уйлап чыгарылмаган. Ул гамәлләрнең һәркайсы баланың тормышына, аның киләчәгенә нинди дә булса йогынты ясый: сабыйның сәламәтлеген ныгыта, аңа көч бирә. Әлеге йолалар ярдәмендә дәү әни-дәү әтиләр, әби-бабайлар, туган-тумача, тирә-күрше, дус-иш кечкенә бәби алып кайткан әти-әнинең олы шатлыгын уртаклаша, баладан яңа котылган әнине, яңа туган нарасыйны яратуга, кайгыртуга күмә.

Дөрес, заман белән бергә бик күп нәрсә үзгәрде. Әмма йолаларның тормышыбызга кире әйләнеп кайткан очраклары да шактый. Әйтик менә кендек бавын саклау. Бүгенге яшь әниләрнең күбесе бу хакта хәбәрдар хәзер: ана белән баланы тугыз ай буе бер-берсенә бәйләп торган кендек бавын элеккегеләр юкка гына матчага кыстырып сакламавын яхшы белә. Балага исем сайлау, исем кушуга да никадәр зур әһәмият бирергә кирәген яхшы аңлыйлар. Исем кушу турында соңрак сөйләрбез. Әлегә бала туу белән бәйле башка йолалар турында искә төшереп узыйк.

Беләсез инде, элек хатын-кызлар баланы өйдә генә тапкан. Аларга *кендек әбиләре* булышкан: баладан котылырга ярдәм иткән, кендек бавын кискән, сабыйны коендырган... Гомумән, ул берничә көн бала тапкан ана янында бөтенләй китеп тә тормаган. Баланың беренче тапкыр коендыруның үз тәртибе булган. Кайбер якларда кендек әбисе ул суга тоз һәм бәбиләүче хатын алдан ук әзерләп куйган көмеш тәңкәне салган. (Бу көмеш акчаны кендек әбинең үзенә дип әзерләгәннәр.) Коендырганнан соң, сабыйны ул этисенең күлмәгенә төргән. Моның да үз хикмәте бар: ата баланы яратсын, бала аңа да якын булсын дип шулай эшләгән.

Аннан кендек әбисе *авызлыкландыру (авызландыру)* йоласына керешкән. Догалар укып, баланың авызына башта бал, аннары май тидергән, ә үзе теләк теләгән: *Авызың ризыклы булсын, / Гомерең озын булсын, / Юлың тигез булсын, / Саның сан булсын, / Йөзең ак булсын, / Күңелең пакь булсын,* – дигән.

Ә кайбер якта: «Баланы кем авызландыра – ул шуңа охшый», – дип санаганнар. Соңыннан хәтта сынаганнар: «Фәлән апа авызландырган иде, холкы нәкъ аның кебек әйбәт» яисә «Шул хатын авызландырды, шуңа күрә киребеткән», дигәннәр. Бу йола турында каяндыр укыган яки ишеткән яшь әниләр, үзләре белән бала тудыру йортына хәзер дә бал алып киләләр һәм баланы беренче тапкыр имезер алдыннан, аның иреннәренә аз гына бал тидерәләр. «Бал белән авызландырганның теле татлы булыр, май белән авызландырганның теле йомшак булыр», ди халык мәкале.

Бала яткан урынны – соңгылыкны да кендек әби урнаштырган. Гадәттә, ул аны берничә тапкыр юган һәм чиста чүпрәккә төргән. Соңгылыкны берәүләр җиргә күмгән, икенчеләр – чормага менгезеп яки идән астына алып төшеп яшергән. Бүген дә бала тудыру йортларында, әгәр әниләр мондый теләк белдерә икән, соңгылыкны аларга бирәләр.

Бала туган көнне үк яки иртәгәсен иртүк мунча ягып җибәргәннәр. *Бәби мунчасында* юынып чыгу һәркем өчен савап саналган: тирә-күршеләрнең, туган-тумачаның берсе дә бәби мунчасыннан баш тартмаган. Кунакларның мунчадан чыгышларын өйдә самавыр куеп, тәм-томнар белән табын әзерләп көткәннәр.

Чакырылган кешеләрнең барысы да юынып чыккач, кызуы сүрелә төшкәч, кендек әбисе мунчага бәбиләгән хатынны алып кергән. Ул аны

да, бәбине дә мунчада үзе юындырган. Бәби мунчасы әле тагын берничә көн ягылган. Кендек әбисе, әйткәнебезчә, ана белән бала яныннан китмәгән – аларны карап-тәрбияләп тору өчен баланың кендеге төшкәнче еш кына шул йортта калган (яки көн дә килеп йөргән). Кендек алты-җиде көн дигәндә төшкән. Аны да, чиста чүпрәккә төреп, сакларга куйганнар.

Бу көннәрдә бәбидән котылган ананың хәлен белүне һәркем үзенең бурычы санаган. «Бәбили торган хатынның морҗасына карау да савап», – дип саналган халыкта.
Иң элек аның хәлен белергә, әлбәттә, үз әнисе килгән. Кызының тулгак ачыларының яртысын булса да үзенә алырга дип өзгәләнгән әнисенең, сөенче хәбәр ишетүгә, алар бусагасын атлап керүе аңлашыла, әлбәттә. (Саратов губернасында гомер итүче татарлар арасында исә мондый йола да була: килене бәбиләүгә, кайнанасы авыл буйлап сөенче алырга чыгып киткән. Бала – Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һәм бүләге. Шуның өчен дә бала туу турындагы хәбәр мөмкин булган кадәр бүтәннәргә тизрәк хәбәр ителергә тиеш. Аны котлап, һәркем акча биреп калган.) Кыз әнисе, оныгын котлап, бигрәк тә беренче бала булса, аңа урын-җир, бәби мендәре, бәби юрганы, бала чүпрәкләре, тәмтомнар алып килгән. Кайбер якларда бишекне дә ул бүләк иткән. Әмма күп җирдә бәллүне киленнең кайнатасы яки ире үз куллары белән эшләгән.

Кыз әнисе артыннан ук, бәби тапкан хатынның хәлен белергә дип, алар йортына бер-бер артлы күршеләре, туганнары керә башлый – һәрберсе *бәби ашы* китерә (кайбер якларда моны «бала үстерү» дип тә атыйлар). Берсе – бәлеш пешереп кертә, икенчесе – кыстыбый, өченчесе – коймак, дүртенчесе – шулпа... Ә кемдер пешкән мич ризыгы түгел, ә бәби кирәк-ярагы, кием-салым алып килгән. Бәби ашын никадәр күбрәк китерсәләр, бала имезүче әнинең сөте шуның кадәр күбрәк булачак дигән ышану да булган. Хәл белергә килүчеләрнең һәрберсен табын янына чакырганнар: самавыр көнозынына шаулап торган – һәркемне чәй эчертеп, сыйлап чыгарганнар.

Исем – халыкның милли йөзе.

Балаларга милләтебезгә хас булмаган исемнәр кушып, киләчәктә үз йөзебезне югалтмабызмы?

Бу йоланың артында бик зур мәгънә ята: бала тапкан хатынның хәле кырык көн буена – кыл өстендә дип санала. Аш-су тирәсендә йөреп, авыр эш эшләп өзлекмәсен, күбрәк ял итсен, баласын карарга көче, вакыты калсын дип китерәләр аңа бәби ашын.

Түбән өлкәсенең Тубыл шәһәре тирәсендәге татар авылларында, бәби ашы китерүчеләрнең һәрберсенә кендек әбисе төрле төстәге җепләр – *бәби җебе* өләшкән. Ул җепләрне бәби көтүче әни алдан ук әзерләп куя торган була. Бәби җебенә алмашка биреп калдырган акчалар кендек әбисенең үзенә булган.

Бәбигә беренче күлмәкне берәр иске әйберне генә сүтеп теккәннәр. Бу очракта бала үскәч кием-салымын кадерләп киячәк, туздырмаячак дип саналган. Кендеге төшкәнгә кадәр, берничә көн генә киертелгәнгә күрәдер, ул *кендек күлмәге (яки көчек күлмәге)* дип аталган. Шуннан соң да киертсәң, бала елак була, еш авырый дип саналган. Кендеге төшкәннән соң, бу күлмәкне юып, үтүкләп, икенче балалары тугач кидертергә дип җыеп куйганнар: шулай итсәң туганнар бер-берсе белән дус, тату булачак дип ышанганнар.

Игътибар иткәнсездер, бала туу белән бәйле йолаларның һәрберсендә кендек әби дә катнаша. Ул бу көннәрдә бәбиләгән хатынның иң беренче ярдәмчесе, киңәшчесе. Кендек әбинең үзенә карата да бәби туган гаиләдә аерым кадер-хөрмәт күрсәтелгән. Ул өенә кайтып китәсе көнне *«әби озату»* дип атаганнар: тирә-күршене чакырып, чәй мәҗлесе уздырганнар. Әмма кендек әбисен бала туган тирәдә генә дә түгел – гомер буе хөрмәтләгәннәр. Йортта таба ризыгы пешсә, аңа өлеш чыгармый калмаганнар, кендек әбисе ялгыз яшәсә, аңа хуҗалык эшләрендә булышканнар, вафатыннан соң да онытмаганнар – аңа гел догада булганнар. Кендек әбисе үзе дә дөньяга килергә булышкан һәр баланы исемләп белгән, «минекеләр» дип йөрткән – хәер-догасыннан ташламаган.

Инде менә исем кушуга да килеп җиттек.

Бәби туды – гаиләгә яңа ямь, бәхет, куаныч өстәлде. Шуның белән бергә әллә никадәр яңа – куанычлы мәшәкатьләр дә артты. Аның беренчесе, әлбәттә, балага *исем кушу*.

Ислам дине буенча балага исемне җиденче көнне кушалар. Әмма моны беренче көнне үк тә, өченче көнне дә эшләргә мөмкин. Әлбәттә, бу йоланы соңрак үтәүчеләр дә бар – һәммәсе дә ата-ананың теләгенә, аның мөмкинлекләренә бәйләнгән. Тик яңа туган баланы беркайчан да озак вакытлар исемсез тотмаска тырышканнар: югыйсә аның сәламәтлегенә куркыныч яный дип санаганнар. Исем кушу мәҗлесенә мулла һәм олы яшьтәге иң якын ир кардәшләр, тирә-күршеләр генә чакырылган. Сабыйны, мендәргә салып, мулла каршысына китергәннәр. Ул, Коръәннән тиешле догалар укып, өч тапкыр баланың исемен, әтисенең исемен әйтеп: «Синең исемең фәлән улы (кызы) фәлән була», – дип, сабыйның колагына пышылдаган. Шуннан соң метрика кенәгәсенә аның исемен теркәгән. Баланың уң колагына – азанны, сул колагына камәтне аның әтисенә дә укырга рөхсәт ителгән.

Исем кушу – бала туу белән бәйле йолалар арасында иң мөһиме, иң җаваплысы. Нинди исем сайларга, меңләгән исемнәрнең кайсына тукталырга? Бу сорау һәрбер ата-ананы, әбибабайны, бөтен кардәш-ыруны, туган-тумачаны уйландыра, борчый. Чөнки исем кешегә бер тапкыр гына бирелә һәм аның гомерлек юлдашына әйләнә. Кытай халкында: «Начар исем начар язмыштан да яманрак», дигән мәкаль бар икән. Шулкадәр хак әйткәннәр! Күркәм исем белән дәшү балага дога кебек уңай тәэсир итә.

Татар халкында балага исем кушу авыр гамәл саналмаган: барысы да гаиләнең хәленә карап башкарылган.

Ә начар мәгънәле һәм ярамаган исем балага да начар йогынты ясый, аның психикасы бозылуга, ямьсез холыклы булуына, авыруларга ансат бирешүенә сәбәп булып тора ала. Моның шулай икәнлеген бүген инде фән дә раслады. Менә ни өчен балага исем сайлаганда ялгышмаска, бик төптән уйлап эш итәргә кирәк. Әгәр мәгънәсез исем бирелә икән, ата-ананың бурычы үтәлмәгән дип санала. Бу очракта мулланың да ул исемне кушмаска хакы бар. Чөнки дин буенча, балага әлеге исем белән дәшкән саен, аның әтиәнисенә дә, исемне кушкан кешегә дә гөнаһ язылып барыла. Әйе, исем кушу бала каршында гына түгел, Аллаһы Тәгалә каршында да зур җаваплылык. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) бу уңайдан әйткән сүзе бар: «Кыямәт көнендә үзегезнең һәм атагызның исеме белән чакырылырсыз», – ди ул. Исеме күркәм булмаса, кеше җәннәткә дә керә алмый.

Исем кушу буенча әти белән әни арасында каршылык чыкса, монда хөкемдар имам булырга һәм ул мәгънәви яктан яхшырак исемгә өстенлек бирергә тиеш. Исемнәрнең икесенең дә мәгънәсе әйбәт икән, өстенлек әти кеше кушарга теләгән исемгә бирелә.

Шулай да улыңа яки кызыңа нинди исем сайларга соң? Белгечләр мондый вакытта Гомәр-Саттар Мулиллинең «Татар исемнәре ни сөйли?» дигән китабына мөрәҗәгать итәргә куша. Анда кергән исемнәрнең теләсә кайсысын балага кушарга мөмкин, чөнки ул исемнәр Казанда, казыят утырышында тикшерелгән, мәгънәләре шикле дип саналганнары төшереп калдырылган.

Исем – ул тарих та. Шәҗәрәләргә язып-теркәп калдырган исемнәр, борынгы бабаларыбызның, нәселебезнең ерак тамырларын күрергә мөмкинлек бирә. Шуңа күрә бүгенге көндә исем бирү традицияләренең югалуы, төссезләнүе нәсел җепләренең дә өзелүенә китермәсме?

Кабер ташларындагы язуларга, башка тарихи чыганакларга карасаң, халкыбыз XIX гасырга кадәр башлыча төрки-татар исемнәре кушкан. XIX гасырда барысы да үзгәрә. Бохара мәдрәсәләренә барып дини белем алучылар балаларына Аллаһы Тәгаләне һәм Мөхәммәд пәйгамбәрне зурлаучы исемнәр куша башлый. Бик зур тиражлар белән бу исемнәрнең шәригать кануннарына нигезләнеп, ничек дөрес язылышын күрсәткән китапчыклар басылып чыга. Әлеге китапчыкларга кергән исемнәр арасында иң беренче урында Габдулла, Гобәйдулла, Әхмәдулла, Рәхмәтулла, Мөхәммәткәрим һәм башка исемнәр тора.

Ә аннан заманалар үзгәрә, илдә революция була, коллективлаштыру, индустрияләштерү еллары башлана. Бу шулай ук исемнәрдә яңгыраш таба. Әти-әниләр балаларына географик атамалар белән бәйле исемнәр куша башлый (Казбек, Урал, Эльбрус), башка планета исемнәрен (Венера, Марс), минералларны (Бриллиант) искә төшерәләр, исем итеп төрле чәчәк исемнәрен сайлыйлар (Резедә, Роза, Лилия, Ландыш, Сирень)... Вил (Владимир Ильич Ленин), Лениза (ленинские заветы), Ленар (ленинская армия), Рунар (революция уничтожает национальную рознь), Дамир һәм Дамира (Да здравствует мир) кебек исемнәр дә шул елларда барлыкка килә.

Нәкъ шул елларда исем кушу йоласын тамырыннан үзгәртү омтылышлары була. Яңа йоланы «октябрина» дип атыйлар. Ул митинг, җыелыш, котлау форматында үткәрелә. Хәтта докладлар ясала. Аның ничек үткәнен күз алдына китерү өчен бер мисал. 1924 елның 22 июнендә «Кызыл Татарстан» газетасы менә нинди хәбәр урнаштырган: «Казан трамвай паркы клубында, бер татар эшчесенең баласы туу уңаеннан октябрина узды. Яңа туган кыз балага, Кызыл Армия җитәкчесе хөрмәтенә Троцкина дигән исем кушылды. Шул уңайдан иптәш Троцкийга телеграмма җибәрелде».

Бу яңа йола халык арасында зур таралу тапмаса да, исем кушу өлкәсендә шактый зур үзгәрешләр кертергә өлгерә. 1930 елда безнең «Азат хатын» журналы «Ата-аналарга киңәш» рубрикасында менә нинди исемнәрне кушарга тәкъдим итә: Рафил, Марат, Фред, Ирек, Рев, Ренад, Корыч, Эдвард, Альфред, Ким, Баян, Карл, Марсель, Марлен, Тимер, Ук, Лерон, Илгиз, Роберт, Сталь, Рева, Марта, Аида, Лера, Рема, Майа, Ландыш, Клара, Денам, Ялкын, Роза, Баян, Ариа, Радик...

Болары инде йөз елга якын элек булган хәлләр. Ә хәзер тирә-юнегездә бүген иң еш очраган исемнәрне искә төшерегез: Эмиль, Милана, Арина, Регина, Ильвина, Амелия, Сабина, Сабрина, Ралина, Карина, Диана, Эллина, Милена, Мира, Стэлла, Радмир, Лина, Софья, Даниэль... Ә исем бит милли һәм аһәңле булырга тиеш! Йорт түренә бишек элгән – бәби алып кайткан һәркем бу хакта исеннән чыгармасын иде...

Бәби туен исә бала азрак исәйгәч зур мәҗлес итеп уздырганнар. Ул мәҗлес татар халык яшәгән төбәкләрдә төрлечә аталган. Казан артында, Пенза өлкәсендә – бәби мае; Тау ягында – бәби туе, бәби боткасы; Касыйм, Сергач татарларында – бәби чәе... Бала котлап алып килгән бүләкләр Нократ татарларында «бишек бирнәсе» дип аталган. Алар балага күлмәк, юрган, чыбылдык, көрпә, мендәр китергәннәр. Ә Сергачта бәби чәенә мендәр китерсәләр, аның читенә көмеш тәңкә бәйләгәннәр. «Көмеш кебек ялтырап торсын», – дигәннәр. Себер татарларында бала котлап биргән бүләкләрне «савын» дип әйткәннәр.

Бәби туйларын зурлап уздыру соңгы елларда янә күзәтелә. Тик кунакларны хәзер өйгә түгел, күбрәк кафе-рестораннарда җыялар. Бәби туе – дини йола гына түгел, ул – милли гореф-гадәт тә, гаилә тантанасы да, гомергә истә калырлык зур бәйрәм дә.

...Өегезгә бәби кайттымы? Йортыгызның һәр бүлмәсе бәби исе белән тулдымы? Безнең әбиләр аны «фәрештә исе» дигән... Бу исне һәркемгә дә татырга язсын!



« Текстны тулысынча уку һәм бәбигә исем кушу йоласы бүген ничек узуын видеодан карау өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз. Видео: Фәгыйлә Шакирова.

ЭКСКЛЮЗИВ БҮЛӘК



Борынгы заманнарда ук кыйммәтле металларның магик көчкә ия булуын белгәннәр. Алтын һәм көмеш үзенең иясен явыз көчләрдән саклый дип ышанганнар. Татар халкы арасында элек-электән зәркән бизәнү әйберләрен бүләк итү, аларны буыннан-буынга тапшыру гадәте булган. Зәркән бизәнү әйберләре үз хуҗасының һәм аның нәселен дәвам итүчеләрнең генетик хәтерен саклый дип саналган.

Татар гаиләсендә кыз бала туугач ук аңа бирнә җыя башлаганнар. Әниләр бизәнү әйберләрен кызларына яки киленнәренә тапшырган. Кызчыкка колакларын тишкән беренче көндә үк алтын алка такканнар. Һәм ул алкаларны аңа нәкъ менә әбисе белән бабасы бүләк иткән. Бу – гаилә кыйммәтләрен тапшыруның да күркәм бер йоласы саналган.

Айлы алкалар – хатын-кызны күз тиюдән саклый торган борынгы символ. Ул ана образын гәүдәләндергән, һәм шуңа күрә ай формасындагы алка һәм муенсалар нәсел дәвам итү кебек изге теләкне аңлаткан.

Улын башлы-күзле итәргә ниятләгән ата-ана аның кәләшенә дә бүләк әзерләгән. Булачак кайнана килененә Коръән сүрәләре белән бизәлгән пар беләзекләр бүләк иткән. Ул яшьләрне олы тормыш юлына озатканда озак һәм бәхетле яшәү теләген җиткергән, өстәвенә, беләзекнең эчке ягына кәләшнең исеме дә уеп язылган әле.

Пар беләзекләр уңыш символы саналган, яман күзләрдән саклаган.

Кәләшнең әнисе һәм туганнары бирнә әзерләгәндә кызларына бизәнү әйберләре белән бергә бөти дә бүләк иткәннәр. Аның эченә Коръән сүрәләре урнаштырганнар. Аннары инде бөтине, күз тиюдән саклый торган миләш, артыш агач ботагы белән бергә, яңа туган баланың бишегенә элгәннәр.

Бүгенге көндә борынгы татар традицияләрен дәвам итү мөмкинлеген безгә «Эксклюзив» зәркән кибетләре бирә: татар һәм мөселман стилендәге бүләкләрне алардан алырга була.

Кадерле кешебезгә нәрсә бүләк итик, дип, еш кына күпләр баш вата. Әниегезне туган көнендә, юбилеенда яки болай гына да айлы татар алкалары белән сөендерә аласыз.

Кызыгызга чылбырлы мөселман асма бизәген бүләк итегез: нинди металлдан булуы мөһим түгел, «Эксклюзив»та күңелегезгә хуш килгәнен табарсыз.

Егетләргә дә мөселман йоласы буенча көмеш ирләр бизәнү әйберләрен – йөзек, асма бизәкләр бүләк итәләр.

Хәтерлисезме, элегрәк әбиләребез эре гәрәбә тезелгән муенсалар тагып йөри иде? «Эксклюзив» кибетләр челтәрендә гәрәбә дисбеләр һәм әбиләребезнеке сыман муенсалар да бар. Җомга намазына йөрүче әтиләргә шулай ук затлы дисбеләр сайлап була. Олыгайган саен, буыннарның сыгылмалылыгы, хәрәкәтчәнлеге кими. Шуңа күрә әти-әниләрегезгә дисбеләрнең эре мәрҗәнлеләрен алырга тырышыгыз: аларга куллану җайлырак булсын. Йолаларыбызны саклап, шатлык бүләк итү шундый рәхәт бит ул...



СЕТЬ ЮВЕЛИРНЫХ САЛОНОВ
ЭКСКЛЮЗИВ

Казан, Р. Зорге ур., 67; Бутлеров ур., 29; Чистай ур., 15/16; Восстание ур., 62.

exclusive.kazan www.exclusive-jewelry.ru РЕКЛАМА.

PRESSA


Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ

Язучы, шагыйрь, күпсанлы җырлар авторы, драматург, әдәбият галиме... А. Алиш, Ф. Хөсни, С. Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе... Сүзебез – Галимҗан Гыйльманов турында. Дүртөйленең Әсәнендә – Шәехзадә Бабич туган авылда, Наҗар Нәҗмине биргән якларда тууы белән генә дә үзенә җәлеп итә ул. Мәктәп елларында ук шигырьләре матбугатта басылып килә. Казан университетында уку елларында атаклы «Әллүки» берләшмәсенә йөри, әдәбият фәне һәм текстология белән шөгыльләнеп, гыйльми дәрәҗәгә диссертация яклый. «Тозлы яңгыр», «Албастылар», «Оча торган кешеләр», «Табылдык хатлар», «Язмышның туган көне» кебек әсәрләре белән укучылар күңелен яулый. Шулай да ул иң элек мәхәббәт шагыйредер...

КҮККӘ ЕГЫЛАСЫ КИЛӘ!

Сөю – җыр ул

Сөю үзе – тыңлап туймас җыр ул,
Бәхетледер аны ишеткән.
Ләкин бәхет бик оялчан әйбер –
Һич керәм дип тормый ишектән.

Сабыр гына көтеп ала бел син,
Аера бел сөю җырларын.
Иң сагышлы минутларыңда да
Онытма син шундый җыр барын!

Сөю җыры гел яңгырап тормый,
Бер мәртәбә килә язлар да.
Бәхетенә ирешкәнче, йөрәк
Борчылырга тиеш, сызларга!

Ә аннары куанырга тиеш,
Сабый көлгән кебек бишектән.
...Сөю сүзе – тыңлап туймас җыр ул,
Бәхетледер аны ишеткән!..

Сөю һәм иман

Күзләремә дөнья сыйган,
Күңелемдә – иман.
Тик шулай да синең күзгә
Карарга кыймам!

Көндез якты Кояшым син,
Төннәрен – Аем.
Сиңа багып, таңда торам,
Кичләрен байыйм!..

Кояшка карап булмавын
Беләм, бик беләм.
Иман тәкъдирне чакыра, –
Тын гына үләм...

Мең үлеп һәм мең терелеп
Яши йөрәгем.
Иманым белән сөюем –
Яшәү терәгем!..

Кайда күрдем?

Мин сине кайда күрдем соң?
Һаман шул хакта уйлыйм.
Өндәме, төштә күрдемме, –
Очын югалттым уйның.

Син миңа шундый таныш бит,
Йөзләрең, карашларың.
Бәгыремә үтеп кереп,
Елмаеп торышларың.

Минем өчен бик тә газиз
Хисләр бар синең җанда.
Шул хисләрең кинәт кенә
Әйләнсен иде чынга!

Синең кем икәнлегеңне
Белер идем шул чакта.
Без яралганбыз, ахыры,
Бер уттан, бер балчыктан...

Мин сине кайда күрдем соң? –
Син шуны уйлап табыш.
...Белдем-белдем! Син бит миңа
Хыялымнан ук таныш.

* * *

«Килермен, көт», – дисең,
Котылу өчен генә.
Өзәсең серле әкиятнең
Иң кызык төшен генә.

Күптән беләм, сүзләреңдә
Әрнеп яткан ялган бар.
Алар иң татлы хыялны
Өзеп, тартып алганнар...

Үпкәм юк, изге җаннарга
Үпкәләп булмый икән.
Күңелдә – сөю дәрьясы,
Ул мәңге тулмый икән!

Хыялларыма юл авыр,
Бары үр генә алда.
Менә – язмышымны сузам, –
Тагын бер генә алда!

Алдану газапларына
Тагын бер генә төшим.
Алдарак кебек
иң матур,
Татлы-газаплы төшем...

Әйдә!

Әйдә сөяргә өйрәтәм,
Назларга, назланырга...
Күзләрендә – моңланырга,
Күләргә – язларында.

Юллар табарга өйрәтәм
Юллар аерылган чатта.
Сагышланырга өйрәтәм,
Мине югалткан чакта.

Әйдә яшәргә өйрәтәм
Ярлы, парлы тормышта.
Туктап калырга өйрәтәм
Һәлакәтле борылышта...

...Өйрәнмәдең.
Буй җитмәслек
Чәчәккә үрелгәнмен.
Сине өйрәтәм дип, үзем
Яшәргә өйрәнгәнмен!

Күңелем җырдан тора

Хисләрең, һай, кайнар, дисең, –
Җаным гел уттан тора.
Янып-көеп яшәвемне
Таңдагы чыктан сора.

Карашларың яшьле, дисең, –
Җаным гел судан тора.
Яшенле яңгыр шикелле,
Бер явар сыман тора...

Күңелең сагышлы, дисең, –
Җаным гел моңнан тора.
Минем хәлемне кояшлы,
Яңгырлы таңнан сора!

Минем хәлемне күлләрдән,
Урманнан, кырдан сора:
Йөрәгем тоташ сөюдән,
Күңелем җырдан тора!..

Синең хатың...

Мине кире кагуыңмы, –
Ничек аңлыйм хатыңны?
Ышандыра алмадым мин
Сөюеңә хакымны.

Тик... ничекләр котылыйм соң
Бу өметле уемнан? –
«Сөймим» дигән сүзләрдән соң
Күп нокталар куелган...

* * *

Сине сагынганда үрелеп бер
Таңга кагыласы килә.
Ялгыш кына таеп киткән булып,
Күккә егыласы килә!
Күк алкадай, үлән арасына
Төшеп югаласы килә,
Тик шунда да, сине сөендереп,
Кабат табыласы килә!..

...Сине сагынганда, җан җылатып,
Ныграк сагынасы килә!

* * *

Бәхетемә моңнар кушып,
Язмышыма язган.
Әле кояш, әле болыт,
Көз дә түгел, яз да...

Сине әле аңлый алмыйм,
Янымда, түгел дә син.
Күз алдыннан югаласың,
Ә үзең күңелдә син...

Яктырак, ди, дөрес икән
Ерактагы йолдыз.
Мин, синсез, – гел синең белән,
Синең белән – ялгыз..

* * *

Ак карларга күпме табындым мин,
Сөюдәй саф ак карга.
Карлар килеп яуды.
Карлы буран
Тели җанны акларга...

Җаным-тәнем белән күтеп алдым
Кар китергән хәбәрне.
Сөю китә, өмет кенә кала,
Карлар күмә хәтерне...

...Бәхет булып явар сыман иде
Быелгы кышның кары.
...Мин сине һаман яратам,
Онытмым гына бары.

Аерылышыйк

«Аны сөймим, сине сөям», – дисең,
Ымсындырып яңа хисләргә.
Өмет тулы ярсу йөрәгемне
Учка салдым, – хәзер нишләргә?

«Сине генә сөям» дигән сүзең
Колагымнан мәңге китмәсен.
Тик... шунысы: миңа гына түгел,
Башкага да хыянәт итмә син!..

Оныттым – онытмадым

Мин сине оныттым инде,
Күктәй серле күзеңне,
Маңгай кыйгач чәчләреңне,
«Сөям» дигән сүзеңне...

Мин сине оныттым инде,
Иркәләү-назларыңны,
Сине миңа бүләк иткән
Кояшлы язларымны...

Мин сине оныттым инде,
Көйләгән көйләреңне,
Мине дивана иттергән
Ягымлы юләремне...

Төшемә килеп керсәң дә,
Күрсәм дә... танытмадым.
Мин сине инде оныттым...
Мин сине онытмадым!

Аерылышу гаме

Аерылганга үкенмәгез,
Изаланмагыз, зинһар! –
Күңелемдә шул иманны
Кабат яңартты гыйнвар.

Әле кайчан гына икәү
Киң кырлар гизгән идек.
Көзге яфраклардан юлга
Шигырьләр тезгән идек.

Аерылуга түзәлмичә
Үләләр язган идек.
Күпме яшьнәп һәм тетрәнеп
Бер гомер узган идек.

Менә тагын очраштык та
Хәйран калып торабыз.
Күңелләрне бәйләр өчен
Берәр хәйлә корабыз.

«Бәхетлеме-бәхетсезме?» –
Күзләрдә бер үк сорау.
Чәчләрдә генә үзгәреш –
Әллә бәс, әллә кырау...

Гүя көзен юлга тезгән
Яфраклар да тузмаган.
Бер-беребездән аерылуга
Кырык ел да узмаган!..





Сәйдә ЗЫЯЛЫ

АНА-КАЗНА

(Хикәя)

Поезд тәгәрмәчләренең бер ритмга салынып, өзлексез кабатланып барган тавышы Элинага «ВИЧ-инфекция», «ВИЧ-инфекция» дигән сыман тоела. Ул, ике терсәге белән өстәлгә таянып, учлары белән колакларын томалый. Әмма бу тавыштан барыбер котыла алмый. Юк-юк, поезд тәгәрмәчләре чыгарган тавыш кына түгел бу. Аның баш миендәге һәр күзәнәк шушы коточкыч сүзләрне кабатлый. Инде әллә никадәр дару эчте. Корвалол да, сукыр кычыткан төнәтмәсе дә, валериан дигәне дә калмады... Ә йөрәк һаман калтырана. Поезд, үзенең тизлеген әле арттырып, әле киметә төшеп, чаба да чаба. Юл кырые буйлап сузылган урман полосаларындагы агачлар, әйтерсең лә аның хәлен аңлап, кул болгап кала. Җәй буе хуш ис таратып утырган юкәләр, гайрәтләре ташып торган горур, нык имәннәр, ябь-яшь каеннар каралып, мескен кыяфәт белән башларын игән. Алар да моңсулыкка, тирән сагышка уралган сыман. Яз җитеп, кояш җылы нурларын сибә башлауга, бу агачлар кабат үзләренең яшьлегенә кайтыр, дөнья кошлар җырына күмелер... Ә Элинаны ни көтә? Ул упкынга тәгәрәде. Ә аннан ничек чыгасы, ничек котыласы?..

Әле кайчан гына ул бик бәхетле иде. Аның сөекле әтисе бар иде. Тәмле ризыклар пешереп, мәктәптән каршы алучы мөлаем дәү әниләре бар иде. Хәзер алар икесе дә фани дөньяда юк инде...

Вагонга милиция киемендәге ир-ат килеп керсә, аның коты чыга. «Мине алырга түгел микән, Ходаем?» – дип, йөрәге «жу» итә. Аннары үзен тынычландырырга теләгәндәй, кылган гамәлләрен күңеленнән барлый башлый: «Дамирны безнең йортта белүче булмаска тиеш. Мин аны беркайчан да үзебезгә чакырмадым. Кесәсендә документлары юк иде бугай. Телефонын ватып, Яшел Үзәндәге чүплеккә үк ташладым. Хәер, аны кем эзләсен?..»

Поезд тәгәрмәчләре, көйгә салынган авазларны берөзлексез кабатлый- кабатлый, чаба да чаба. Калын кар катламы тигез төшеп өлгермәгән иркен басулар, юл читенәрәк урнашкан авыллар, урман, әрәмәлекләр – һәммәсе артта кала. Элинаның уйлары гына һич тә үзеннән калмый. «Әй Дамир, Дамир, – ди ул эченнән генә. – Никләр дип кенә миңа очрадың син? Никләр дип мин сиңа иярдем?.. Нәкъ җырдагыча: Ходай миңа насыйп итте, яп-ялангач башлыны...»

Башлангыч сыйныфта чакта Элина белән Дамир бер мәктәптә укыганнар иде. Чандыр гына юаш бер малай иде ул. Кызлар чәчен тартмас, малайлар белән бәрелешкә кермәс... Укуы әллә ни мактанырлык булмаса да, укытучылары коңгырт күзле, пөхтә Дамирны ярата иде.

Аннары Дамир каядыр юкка чыкты. Баксаң, алар элекке фатирларыннан киткән икән. Ире вафатыннан соң, малайның әнисе Гөлгенә Үзбәкстаннан килгән бер ирне йортка керткән. Җимеш сатучы шул ир тәкъдиме белән фатирны да базарга якынрак урамга алыштырганнар.

Яңа ир белән яши башлагач, Гөлгенә ханым улы барлыгын онытып җибәрә, күрәсең. Аның ничек укуы, ничек көн үткәрүе белән берәү дә кызыксынмый. Кыю, чая, «эш майтара белгән»

үсмерләр малайны тиз күреп ала. Ул шул рәвешле «Тарташныкылар» дип даны чыккан үсмерләр төркеменә килеп керүен сизми дә кала. Бу төркем шактый гына кибет, рестораннарны үз кулларында тота. Төркемдәгеләр телендә әйтсәк «крышовать» итәләр. Әлеге «хезмәт» өчен кибет, ресторан хуҗалары табышларының бер өлешен шушы егетләргә бирә. Әгәр бирмәсәң?.. Бирмәсәң – бандитларның кануны катгый....

Ә Элинаның балачагы шундый якты, шундый бәхетле башланган иде дә бит...

Алар гаиләсенә «бәхетсезлек» дигән афәт кайчан керде соң әле? Мөгаен, дәү әниләре Маһруй җиңги киткәчтер. Өлкән кешене үз бусагасыннан чыгып китәр дәрәҗәгә җиткерүнең кемгә бәхет китергәне бар соң? Әйе, дәү әнисеннән аерылган чакта Элинаның башына мондый сорау килми иде әле... Ул бүгенгечә уйлый белми иде.

Аларның дәү әтисе сугыштан кайтмаган. Тула өлкәсендәге каты бәрелешләрнең берсендә 1942 елда һәлак булган. Дәү әниләре берсеннән-берсе өч нарасые белән «коммуналка» дип йөртелгән кечкенә бер бүлмәдә яшәгән. Кырык биш ел буе заводта эшләп, балаларын үстергән, аякка бастырган. Аның өч баласы да химия-технология институтын тәмамлаган. Институттан соң кызларның өлкәнен Мәскәү өлкәсенә җибәргәннәр. Кечесе Ленинградка урнашкан. Элинаның әтисе Расих көндез эшләгән, кичләрен укыган. Шуңа күрә ул Казанда әнисе янында калган.

Еллар үткән. Илгә тынычлык килгән. Завод җитәкчеләре, Маһруй апаның хезмәтен зурлап, өч бүлмәле яңа фатир биргән. Расих өйләнгән. Авылдан килеп, чәчтараш һөнәрен үзләштергән Хәния Маһруй җиңгиләр фатирына килен булып төшкән. Киленне матур итеп каршылап, зурлап туй иткәннәр...

Киленне бик ошата Маһруй җиңги, тик аны бер нәрсә, улыннан күпкә яшь булуы гына борчый. Егерме яшь бит... Бигрәк күп... торып китә алырлар микән? – дип борчыла.

Килен бер-бер артлы ике кыз бала тапкач, Маһруй җиңги сөенеп туя алмый: «Аллага шөкер! Торам дип, килгән. Исән-имин генә яшәсеннәр, бәхетле булсыннар», – дип куана. Декрет ялы тәмамланып, эшли башлагач кына Хәниягә әллә ни була. Югыйсә кайнанасы ул эштән кайтуга балаларны карап тора, аш-су әзерли. Кибет ризыкларын да Расих ял көннәрендә атнага җитәрлек итеп ала. Өй җыештыру, кер юу ише эшләр генә Хәниягә кала.

Кызларга 3 яшь тулып узгач, Маһруй җиңги балалар бакчасы турында сүз кузгата.

– Мин ике баланы көн саен бакчага сөйрәп йөри алмыйм, – дип кырт кисә Хәния.

– Мин йөртергә тиеш тә инде аларны, – ди Расих, чарасыз калып. – Миңа эшкә барып җитәргә генә дә бер сәгать вакыт кирәк. Үзегез беләсез: хәрби завод. Соңга калырга ярамый.

Күз төпләренә тирән буразналар сызылган, бармакларының буыннары бер якка бөгелгән ана сүзгә кушылмый гына тыңлый. Бу сөйләшүдән тынычлыгын югалткан Хәния төнлә ире куенында тагын сүз кузгата. Назлап, кайнар иреннәрен иренең битендә йөртә-йөртә, ул болай ди:

– Җаным, садик дигәннәрендә балалар гел авырый икән бит. Анда тәрәзә ачып йоклаталар, шуңа балаларга салкын тия, ди. Безнең эштә бер хатын интегә мескен, кан елый. Әнкәй белән сөйләш әле, зинһар.

Маһруй җиңги улына каршы килмәде. Кызлар бер-бер артлы мәктәпкә киткәнче өйдә булдылар. Мәктәпкә дә дәү әниләре чәчләрен тарап, ашатып-эчертеп озатты, каршы алды. Башыннан узган гыйбрәтле хәлләрне әкият итеп сөйли-сөйли, иркәләп йоклатты...

Өйдәге кеше күп күрер дип юкка гына әйтмәгәннәрдер шул. Беркөнне кичләтеп кенә Маһруй җиңги балконга эленгән керләрне алырга чыкты. Сөлгене алыйм дип бауга үрелгәндә, күзе урамга төште. «Әнекәйгенәм! – дип аптырап эндәште ул үз-үзенә. – Хәния түгелме соң бу! Әйе, әйе, Хәния... Һай, Аллам, һай, Аллам», – дип кабатлыйкабатлый стенага килеп сөялде.

Шактый ук чайкалып, алпан-тилпәнрәк атлаучы киленне яшьрәк кенә бер ир биленнән кочып озата килә иде.

Аңлады Маһруй җиңги. Киленнең вакытында эштән кайтмавы да, эштән соң ни кылып йөрүе дә ачыкланды. Элек тә шикләнә иде шикләнүен. «Тотылмаган карак – карак түгел» дигәндәй, ялгышырмын, араларын бозсам, гөнаһысы булыр», – дип эндәшмәде, түзде.

Килен, аяк киемен генә салды да, тып-тын бүлмәләренә кереп китте. Хәния, чишенеп, караватка сузылып кына яткан иде, баш очында кайнанасы пәйда булды.

– Килен, ничекләр оялмыйсың син? – диде Маһруй җиңги, әрнүеннән калтырана-калтырана. – Алма кебек ике кыз балаң үсә, аларга нинди үрнәк күрсәтәсең?!

– Мин нишләгән соң әле? – дип мыгырдана-мыгырдана торып утырды Хәния.

– Нишләгән? Нишләгән, имеш! Кешнәгән! Инде ирең генә җитми башладымы? Хатын-кызның азынуы юньлегә алып бармый. Иреңне санламыйсың, мине санга сукмыйсың. Балалар турында уйла хет!

– Алар бит минеке генә түгел, сезнеке дә, – дип җавап бирде килен, кайнанасының әйткәннәренә һич кенә дә исе китмичә. – Алар бит синең оныкларың! Мин эштән кайттым. Аптыратма! Арыдым!

Киленнең үз-үзен тотышына тәмам сабыры төкәнгән Маһруй җиңги түзмәде, тавышын күтәрә төшеп:

– Һай, Аллам! Харап булган! Берәүләр таш кисеп кайткан! Кем эшләмәгән! Беләсең килсә, мин кырык биш ел станокта эшләдем! Синең шикелле эчеп йөрмәдем! Ирсез килеш өч баланы үстердем! Ә син өйдә аркылыны буйга да алып салмыйсың!

Сиңа әйттең дә әйтмәдең ни дигәндәй, Маһруй җиңги кулын селтәп, чыгарга борылды. Авырткан аягын сөйрәп бер адым атларга өлгермәде... киленнең сүзләре аны туктарга мәҗбүр итте.

– Ха! Син генә эшләгән инде! Бүтәннәр эшләми! Минем хезмәтне син эшкә дә санамыйсың! Беләсең килсә, бел: мин сигез сәгать буе аяк өстендә! Өйдә дә тынгы юк! Әле төне буе малаеңның күңелен дә күрәсем бар!

Маһруй җиңгинең башына таш белән ордылармыни – ул чайкалып китте дә, ишек яңагына таянды. Бераз хәл алгач, килен ягына башын борып, әкрен генә әйтте:



– Битеңә сыер тизәге каплаган нәрсә икәнсең… Борынгылар, ананы казна дигән. Син менә… син казна түгел. Син – безнең башка төшкән каза!

Ул кичне ир белән хатын арасындагы тавыш төн уртасына кадәр сузылды. Мәһруй җиңгинең керфегенә дә йокы кунмады. Улы белән киленнең күңелсез сүзләре, төн карасын тагын да каралта-каралта, ананың колагына килеп бәрелә торды.

– Сиңа ни җитми?! – дип сорады Расих, эчендә кайнаган ачуын йодрыгына кысып. – Эчүеңне ташламасаң, үзеңә үпкәләрсең!

– Нишләрсең? – дип, үчекләгәндәй сорады хатын. – Әллә үзең әулияме?

– Әулияме, түгелме – суд карар! Мин – ир кеше! Гаилә башлыгы…

– Һе, – диде Хәния һич тә исе китмичә. – Безнең илдә ирләр белән хатын-кыз тигез хокуклы.

– Тигез генәме соң! – дип, тешләрен шыгырдатты ир, – тыштан – матур, эчләре – пычрак! Тигез хокук дип, бөтенләй тугарылдылар! Ятимнәр белән ил тулган! Ә бит һәммәсенең әниләре исән!

– Ну и что?

– Күрсәтермен мин сиңа «ну и что»ңны! Менә хәзер үк милиция белән психбригада чакыртам!

Расих тиз генә телефонын алды. Бу хәл хатынга бик тиз тәэсир итте.

– Расих, тукта әле, – диде ул ирнең кулына ябышып, мескенләнгән тавыш белән. – Мин гаепле… Больше не буду…

– Син миңа ничә тапкыр «больше не буду» дидең инде?

Суга төшеп күшеккән чебештәй мескен, көчсез кыяфәт чыгарып, Хәния сүзен дәвам итте:

– Беләм, беләм… әни котырта инде сине… Син мине дә аңла, җанашым… Эштән кайтуыма – миңа замечание. Әнкәйгә ярап булмый. Аргансың дигән кеше юк, хәлең ничек дигән сүз юк. Ирексездән шушы юлга бастым…

Бу сүзләрне ишетеп яткан Мәһруй җиңги ике учы белән башын кысып, берөзлексез үз-үзенә тәкрарларга керешә. «Һай, Аллам! Һай, Аллам! Карт юләр, үзем гаепле икән ләбаса! Нишлим икән соң? Нишлим? – Шушы рәвешле уйлана торгач, ул катгый бер фикергә килде. – Китәргә кирәк! Ленинградка, кызым янына. Минем аркада бозылышып яшәмәсеннәр. Балалар ятим үсә күрмәсен…»

Эчендәге кичерешләрен йөзенә чыгармаска тырышып, ул атна-ун көн җыенды. Аннары гына ниятен улына чиште.

– Улым, мин апаңнарны күреп кайтсам дип уйлап йөрим әле. Сагындым да… – дигән булды. Әлбәттә, Расих каршы килмәде. Китәр алдыннан күршеләре белән күрешеп чыкты. Ана күңеле сизенде, анда аны билгесез хәвеф көтүен аермачык тойды. Күршеләре белән саубуллашуы да – аның бәхилләшүе иде… Ә инде иртәгә китәргә дигән төнне ул тагын йокламады. Үз бүлмәсенең стеналарын сыйпый-сыйпый йорты белән сөйләште, догалар укыды. Бу йортка иминлек теләде. Киткән чакта ике оныгын алып, күз яшьләрен түгә-түгә иркәләп, назлап сөйде.

Ул киткәнгә карап гаиләдә тынычлык урнашмады. Хәния генә иркенәеп, киң сулыш алып калды. Өй эчен ниндидер күңелсез салкын бушлык биләде. Кызларны тәмле ризык пешереп берәү дә каршы алмый хәзер. Күп вакыт алар үз иркендә. Әтиләре эштә. Цех начальнигы урынбасары булгач, план үтәлешен аннан сорыйлар.

Тормышының рәтсезләгән, әнисенең китүен авыр кичергән Расихның кан басымы күтәрелә башлады. Ә беркөнне… Хәния соңга калды. Сәгать төнге унберенче киткән. Кызлар да йокларга ятты. Хатын юк та юк. Аптырады Расих. Автобус тукталышына да чыгып керде. Эш урынына да шалтыратып карады, җавап бирүче булмады. Инде ничәмә-ничә тапкыр балконга чыгып ишегалдына күз салды. Ә соңгы чыгуында… подъезд ишеге өстенә куелган лампочканың сүрән уты яктысында ул ике гәүдәне күрде. Хатын-кыз белән ир кочаклашып, үбешеп тора иде. Хатын-кызы аның хәләле Хәния иде. Расихның җанында чиксез дәрьяларның дулкыны кузгалгандай булды. Бу дулкында, юлына очраган һәрнәрсәне юып алырдай куәт бар иде. Бу мизгелдә аңа каршы торырдай көч-куәт юк иде.

Хәниянең ишектән килеп керүе булды, нык йодрык аның яңагына килеп кунды. Бу гамәленнән соң Расих инде берни дә хәтерләмәде. Нервларының соңгы чиккә җитеп тартылуы нәтиҗәсендәдер – кан басымы ике йөздән артыкка күтәрелде. Ул аңын югалтты. Һәм бүтән аңына килмәде…

Табиблар инсульт диделәр. Бу югалту Мәһруй җиңгине дә аяктан екты. Улыннан соң озак та тормыйча ул да мәңгелеккә күчте…

…Ә поезд чаба да чаба. Киң кырлар, урман, әрәмәлекләр һәммәсе юлдагыларны озатып кала сыман. Ул арада каршы килгән паровоз тирә-юньне яңгыратып сәлам биреп уза. Һәммәсе уза, артта кала. Элинаның уйлары гына һаман аның миендә. Алар беркая да китми, берөзлексез җанын кимерә. «Әй, Дамир, Дамир, – ди ул эченнән генә. – Никләр дип очрадың син миңа?»

Әтисез, дәү әнисез калган кызлар, тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, мөстәкыйль тормышка аяк басты. Суфия педагогика көллиятенә укырга керде. Берничә елдан соң Элина да документларын медицина көллиятенә тапшырды. Әмма кызның юлы уңмады – конкурстан узмады. Балачактан ук табиб булам дип йөргән хыяллары чәлпәрәмә килде. Әтисе исән булса, болай төшенкелеккә бирелмәс тә иде. Иң элек урта белем алыр иде. Ул хәзер бөтенләй дә ялгыз калды. Әниләре үз юлында, Суфия – укуда. Апасының үз дуслары, үз дөньясы. Элина өчен берәү дә борчылмый. Кыз урамнар буйлап аптырап йөри. Белдерүләр эленгән урыннарда тукталып, үзенә кулай булган хезмәт урыны эзли. Ә беркөнне… «Үзәк парк» тукталышындагы белдерүләрне укып торганда аңа бер егет сүз кушты.

– Чибәркәй эш эзли, ахрысы, – диде янәшәсендә басып торган кара күзлекле егет.

– Эзли… – дип авыр сулады кыз игътибарсыз гына.

– Ә мин сезне беләм, – диде кара күзлекле, сагызын чәйни-чәйни. Ул бу сүзләрне әллә чынлап, әллә Элинаның


Рәсем: Наталья Васильева

игътибарын үзенә юнәлтер өчен генә әйттеме, әмма теләгенә иреште. Кыз борылып егеткә күз салды. Чәче кырылган, калын кара кашлы, какча яңаклы, йөзе кояшта каралган егет аңа һич кенә дә таныш түгел кебек иде. Әмма... тавышындагы бер төсмерне колагы кайчандыр ишеткән дә сыман...

– Сез кызлар белән гел шулай танышасызмы? – диде Элина.

– Төрлечә.

– Сезгә дә эш кирәкме? – диде кыз.

– Юк. Минем эшем бар. Бүген ял көнем.

– Сез бәхетле, – диде Элина. – Хәзерге заманда эш урының булу – зур бәхет.

– Дөрес. Әйдә, бүген үзебезне үзебез бәхетле итик әле. Мин сезне кафега чакырам. Чакыруын чакырам, ә исемегезне белмим.

– Элина.

– Ә мин – Дамир.

Алар әнә шулай таныштылар. Соңыннан бер мәктәптә укып йөргән бала чаклары да искә төште.

Берничә көннән соң Дамир аны үзенең «биләмәсенә» алып кайтты.

– Бу фатирны миңа бер дустым калдырды, – дип аңлатты ул.

Шәһәр уртасындагы ике катлы агач йортның кечкенә генә бер бүлмәсе иде ул. Шушы көннән соң Элина монда еш була башлады. Дамирның өстәлендә колбаса, яшелчә, җиләк-җимеш ише ризыклар һич өзелми. Бер кичне алар шәраб эчте. Элинаның башы әйләнеп киткәндәй булды. Ул кеткелдәп көлде, йөремсәк мәзәкләр сөйләде. Бераздан аны нигәдер сагыш басты. Дамирның иңнәренә кулын куйды да, әкрен генә җыр башлады.

Мин Ходайдан сорадым
Чем-чем кара кашлыны;
Ходай миңа насыйп итте
Яп-алангач башлыны.

Дамир үзенең чәче кырылган башын сыйпап алды:

– Син нәрсә? Мин ошамыйммыни?

– Юу-ук! Бу җыр сиңа түгел. Гафу ит. Дәү әни җыры бу. Ул шулай җырлый иде. Безнең стенада дәү әти белән дәү әнинең яшь чактагы фотолары тора. Дәү әти чем-кара чәчле, килешле мыеклы. Ә дәү әни аны «яп-ялангач башлы» дип җырлый. Бу – язмыш. Язмыш турындагы җыр...

Элина әкрен генә сөйли. Ул икесенең дә әниле хәлдә – әнисез, гаиләле җылысыз яшәүләрен күз алдында тотып сөйли...

– Ә син күп уйлама. Күп уйлау нервларны какшата, – дип киңәш итте егет.

Шулай кышлар үтте, яз җитте. Җәйне алар Кырымда үткәрде. Ул чакта Дамир күп акча тапты.

– Безгә китәргә кирәк, – диде егет беркөнне.

Алар икенче көнне үк Мәскәүгә очтылар. Аннан соң поезд белән бардылар...

Шулай Дамир тапкан акчага яшәп, шактый гомер үтте, яше унҗидегә җитте. Яши-яши Элина Дамирның ничек акча табуын да, наркотиклар сатуын да, наркоман булуын да күрде, белде. Моннан китәргә, араны өзәргә кирәклегенә дә төшенде. Үз аягы белән килеп кергән бу җәтмәдән ансат кына котылып булмаслыкны да күңеле белән тоя иде. Ташлап китүне Дамир гафу итмәячәгенә иманы камил иде.



Иң элек эшкә урнашуны максат итеп куйды кыз. Эш тә тапты. Октябрь ахырларында балалар бакчасына җыештыручы булып урнашты. Хезмәт хакы кечкенә булса да, тамагы шушында туя иде. Бала-чагадан калган ипи, ботка, котлет ише ризыкларны өйгә дә алып була.

Җыештыручы бик кирәк булгандыр күрәсең, эшкә урнашканда анализлар да сорамадылар. «Иртәгә эшкә чык», – диде мөдир. Элина кан анализларын ноябрь кергәч кенә тапшырды. Эш табуына сөенеп, тырышып эшләп йөргән бер көнне мөдир аны үзенә дәшеп алды. Ак халатлы, түгәрәк йөзле, 50 яшьләрдәге мөлаем ханым каршысына утыртты да аңа озак текәлеп карап торды. Аннан соң аналарча кайгыртулы тавыш белән:

– И бала... бала... – дип, авыр сулады. Элина, берни аңламыйча, мөдир апасына сораулы карашын текәде. – И бала... – дип кабатлады мөдир. – Синдә ВИЧ-инфекция таптылар...

Бер сүз... Бер мизгел... Элинаның башы әйләнеп китте, күз аллары караңгыланды. Җанын, һәр күзәнәген чарасызлык, курку биләде. Гүя ул сазлыкка баткан. Аның чәбәләнергә дә, бу коточкыч упкыннан чыгар өчен кыймылдарга да хәле юк. Ул тоташ караңгы сазлык эчендә өнсез халәттә утыра сыман. Аның колагына тагын: «И бала, нишләдең син?» – дигән сүзләр ишетелде. Элина кинәт аңына килгәндәй булды. Ике учы белән йөзен томалады. Аннары, бер кәлимә сүз әйтмичә, ишеккә томырылды. «Дамир! – дип кабатлады ул эченнән генә. – Дамир!.. Нишләргә? Кая барып бәрелергә?» Башында бөтерелгән шушы сорауларга җавап таба алмыйча, шәһәр урамнарын урады. Шулай йөри торгач, Суфия янына барырга уйлады. Бу афәтле кайгыны кыз апасына гына сөйли алачак. Туган туган инде... Элинаны апасы тынычландырды, юатты. «Дәваланырсың. Борчылма», – дип киңәш итте.

– Ә Дамир? – дип сорады Элина. – Ул кабахәт тагын күпме кешегә йоктырыр бу чирне! Аннан барыбер үч алырга кирәк!

– Сеңелкәем! Бандит бит ул! Бу хәлне аңа әйтә күрмә! Һичшиксез башыңа җитәчәк!

– Мин аңа әйтмәдем.

– Алайса, уйлашыйк.

Кышның караңгы бер кичендә Элина Дамирны үз өйләренә кунакка дәште. Егет килешкә, кызлар табын әзерләде.

– Әни кайда соң? Ул кайтып эшне бозмасын тагын, – дип куйды Суфия.

– Юк. Бүген кайтмый ул. Икенче көн инде дусларында...

Кызлар Дамирны мактый-мактый сыйладылар. Сәгатъ уклары икенче тәүлекне саный башлаганда егет үз-үзен белештермәс дәрәҗәдә исергән иде. Дамир алып килгән бер ампула «доза»ны Элина шприцка суыртып алды. Бервакыт егет аңа үзе укол ясарга өйрәткән иде. «Син табиб булырга хыялланган кеше. Өйрән. Үзеңне табиб итеп хис ит!» – дигән иде. Юк, ул бүген табиб түгел. Ул бүген – кеше үтерүче. Башкача мөмкин түгел. «Әгәрдә мин йоктырган булсам бу чирне... ул мине һичшиксез юк итәр иде бит...» – дип акланды Элина үз-үзенә. Һәм... шприцтагы наркотикны әкрен генә исерек Дамирның кан тамырына җибәрде....

Шприцны, ампула пыялаларын, төреп, Суфия үзенең сумкасына салды. Кызлар сөйләшми генә табынны җыештырдылар. Өстәлдәге бар савытны әйбәтләп юып, сөртеп урнаштырдылар. Аннары Элина Дамирның салып куйган киемнәрен, ботинкасын үзенә кидерде. Шул арада Суфия әкрен генә балконга чыкты. Ишегалды тып-тын. Тәрәзәләрдәге утлар күптән сүнгән. Подъезд ишеге өстенә куелган тоник лампа яктысы гына түгәрәк ясап аяк астында чайкала.

Төннең кырыс, салкын җиле шәһәр өстенә кара болытлар куып китергән.

Берни белештерми яткан Дамирны кызлар, икесе ике ягыннан күтәреп, балконга алып чыктылар. Үз-үзен тота алмаган гәүдәне урамга каратып, балкон стенасына сөяделәр дә, икесе ике аягыннан тотып өскә күтәрделәр. Егет баштүбән аска очты...

Суфия белән Элина, балкон ишеген ябып, шым гына өйгә керделәр.

Таң атып, тәмам яктырып беткәнче, бер кәлимә сүз әйтмичә, тып-тын утырдылар.

– Миңа бик соңга калмыйча китәргә кирәк, – дип пышылдады Суфия. Җизнәң төнге сменадан кайтып җиткәнче өлгерәсе иде.

– Беләм. Кешеләр йөри башласын инде.

– Син нишлисең?

– Мин бүген үк Ленинградка китәм.

– Билетың бармы соң?

– Башта мин Яшел Үзәнгә барам. Шуннан берәр поездга утырып Мәскәүгә китәрмен.

...Поезд чаба да чаба. Тукталышларда кемнәрдер төшә. Димәк, алар ниятләгән урыннарына яки үз өйләренә кайтып җиткән. Кемнәрдер чемоданнарын, төргәкләрен күтәреп, поездга яңа кереп кенә утыра әле. Һәркемнең үз уйлары, үз мәшәкате, үз юлы. Тик, алар берсе дә Элина хәлендә түгелдер. Һәрхәлдә Элинага шулай тоела. Әле әтисенең апасы янына баргач та үзенең хәле турында сөйли алмаячак. Ничек сөйләсен? Әни эчә. Аның кыланмышларыннан туеп, бер бандит белән аралаштым. Аннан чир йоктыргач.... үч алдым, дисенме? Ярар, эчендә кайнаган бу куркыныч вакыйгалар турында ул гомере буе сөйләмәс. Милиция эзләп таба күрмәсен... Хәер, төркемдә йөргән малайлар һаман бер-берсен үтереп тора...

Паровозның кинәт әче итеп сызгыруы кызны сискәндереп җибәрде. Ул тәрәзәдән күккә күз салды. Кышкы бу кыска көн ниндидер авыр сагышка төренгән сыман иде. Салкын җил иркендәге кара болытлар, зәңгәр күк бездән тизрәк арынсын инде дигәндәй, бер-берләрен этә-төртә агалар да агалар.

* * *

Элина ике ай буе Ленинградта «кунак» булганнан соң гына Казанга кайтты. Шушы вакытка кадәр аны берәү дә эзләп килмәгән, берәү дә аның кайда йөрүе белән кызыксынмаган.

Дамирны моргтан исемсезләр каберлегенә җирләгәннәр. Аның язмышы турында берәү дә кызыксынмаган...



Марат
КӘБИРОВ,
язучы

МЕНӘ ШУЛАЙ...

Эшкә әле иртәрәк. Һава торышы ничек икән дип балконга чыгам. Җылы. Рәхәт. Якты. Матур. Каршыда гына әллә ничә катлы йорт. Санарга ирендерә. Биек нәрсә матур күренә. Бу – пыяла белән таштан гына тора кебек. Аның янында кечкенәрәк йорт. Ул да пыяла белән таштан гына тора. Алай түгелдер инде, кайсыдыр җире пластик, кайсыдыр җире калайдыр. Карале, без шуның эчендә яшибез икән бит. Таш, калай, пыяла, пластик эчендә. Асфальт урам буйлап машиналар җилдерә. Матур машиналар. И-и-и, нәрсәләр генә ясамый инде бу адәм кулы. Карале, урам тулы адәм кулы белән ясалган нәрсә икән. Электр баганалары, рельслар, тимер коймалар... Ямь-яшел булып балкып торучы бер генә табигый нәрсә бар. Юк инде, яшел чирәм түгел. Чирәм дә пластик. Ниндидер түрә килү хөрмәтенә китереп җәйгәннәр иде – шул килеш калды. Бердәнбер табигый нәрсә – биек булып үсә торган агачлар. Нинди икәнен белмим. Күршем бер әйткән иде инде, онытканмын. Кабат сорарга кыен. Әллә ничә агачның орлыгын бергә кушып бутаганнар-бутаганнар да, шундый матур затлы агач ясаганнар... Кар-ра-ле! Башыма да килгәне юк иде. Алайса, монысы да табигый булып чыкмый бит инде. Ясалма була. Әйтәм, аның яфраклары кар яуганда гына коела башлый иде.

Кабат фатирга керәм. Бүлмәгә күз йөгертеп чыгам. Стеналарга... Түшәмгә... Идәнгә... «Флизелин, пластик, керамика...» – дип уйлап алам. Мебельләр дә... Барысының исемен белеп бетермим. Ясалма икәнен генә беләм. Нәрсәнедер нидер эшләтеп, ничектер ясаган кемнәрдер.


Суыткычны ачам. Күз шундук колбасага төшә. Кытай борчагы аксымыннан ясалганы кәгазенә үк язылган. Шул аксымны суда болгатып ботка ясыйлар да тәмләткечләр һәм буяулар кушып иткә әйләндерәләр. Монысын инде бала-чага да белә. Алтынсыман ялтырап торган кыздырылган бәрәңгегә карыйм. Үткән атнада бер кафедан алып кергән идем. Монысы да крахмалдан, тагын әллә нәрсәләрдән ясалган инде. Ашап та булмый, бозылмагач түгеп тә булмый. Кунаклар килсә дип алып куелган кызыл уылдык. Су үсемлекләреннән ясалган, диләр. Кәтлит... Ит... Химия фәне бик алга китмәгән чорда да кәтлиткә ит кушып тормыйлар иде бит инде. Хәзер бигрәк тә. Яшелчә яхшырак булырдыр. Кыяр-помидорга карау белән аларның минераль мамыкта төрле химик матдәләр ярдәмендә үстерелүе искә төшә. Җимеш суты турында уйлап та тормыйм инде. Боларның тәмләткеч һәм буяу икәнлеге әйтмәсәң дә билгеле. Суыткычны өйрәнеп чыккач, аппетит ябыгып кала. Мөгаен, сөтле чәй белән генә чикләнергә туры килер... Ләкин сөт дигәне кичә үк өстәлдә калган, суыткычка алып куярга онытканмын. Ачыгандыр инде. Юк, ачымаган! Тагын бер атна торса да ачымаячак икән. Чәй кайнар суга элэгү белән куе булып чыга башлый. Буяу бит инде. Шайтан алгыры! Табигый ризык ашау теләге югала. Мөмкин булмаган нәрсәне хыялга да кертергә ярамый ич инде. Һәм мин суыткычта булган хәзинәне өстәлгә куям... Минең кайсыдыр өлешендә киләчәктән ишетелгән таныш әкият чагылып кала: «Борын-борын заманда, бәрәңге – җирдә, ит сыер аягында үскән чорларда...»

Урамга чыгам. Күрше тәмәке сорап сәламли.

– Кибет ачылмаган икән әле, – дип акланган була. Мин аның кичә – кибет ачык чакта да сорагганын искә төшерәм. Дәшмим. Бирәм. Жалко түгел. Кәгазь генә ич ул, кирәкле матдәләр сеңдерелгән кәгазь. Күршегә жәл түгел – агулансын рәхәтләнеп. Өстәвенә, ял итеп, саулыгын ныгытып Дубайда йөреп кайтты. Үзе дә мактанды. Интернеттан да бөтен адымнарын күреп сөенеп тордык. Минем ялга барган юк алай. Барасы килә килүен, тик соңыннан тәмәке сорап йөрисе килми.

Эшкә керәм. Кичә генә бер-беребезне күрәлмәс дәрәҗәдә аерылышкан хезмәттәшләр белән дә ай буе күрешми торгандай исәнләшәбез. Күзләрдә – кыска вакытлы ясалма яктылык, иреннәрдә – елмаю. Хәл-әхвәл сорашабыз да җавапны тыңлап та тормый, китәргә ашыгабыз. Югыйсә елмаю мускуллары калтырана башлап, бөтен матурлыкны бозарга мөмкин...

Менә шулай гомер ясап ятабыз. Мин кайчагында, үзем дә ясалма түгел микән дип шикләнеп, берәр җирне чеметеп карыйм. Авырта, шайтан алгыры. Белмим, бәлки, бу – ясалма авыртудыр...



Була шундый мизгелләр: күңелләр әллә кайларга ашкына, инде онытылган вакыйгалар яңадан искә төшеп, сине кабат уйланырга этәрә.

Тормыш дилбегәсен тартып чаба-чаба, вакытның ничек тиз узып китүен сизмисең дә. Балачак еллары, яшүсмер чаклар инде күптән еракта. Әмма һаман да күңелнең иң түрендә...

Казан шәһәренең 150 нче мәктәбендә укып йөрим. Алдагы тормыш инде билгеләнгән дә кебек. Балалар табибы булырга хыялланып, химия, биология фәннәрен тирәнтен өйрәнәм, дәресләрдән соң КФУда (элекке КГУ) түләүле курсларда укыйм.

Июнь җитә. Чыгарылыш кичәсе. Барыбыз да рухланган. Яңа тормыш баскычына күтәрелергә торабыз! Алда нинди кыенлыклар көтәсен күз алдына да китермибез. Кичә беткәндәрәк сыйныф җитәкчем Альберт Әминович мине үз янына чакырып алды да болай ди: «Илсөя, мәктәп директоры синең исемеңә Казан пединститутына татар теле белгечлегенә юллама җибәрде». Аптырашта калуымны сизептер, татар теле олимпиадаларындагы уңышларымны искә төшерде. Нәрсә әйтергә дә белмәдем. Бу хәбәр тормыш юлымны бөтенләй икенче якка әйләндерде дә куйды. Табибә булырмын дип уйлап йөрдем бит югыйсә! Нинди укытучы миннән? 11 нче сыйныфны бетерсәм дә, аның ике елы гына саф татар телендә булды. Сөйләшү ул – бер нәрсә, ә инде телне белү – бөтенләй башка!

Яңалыкны ишетүгә, әни барысын да үз кулына алды. Медицина институтына керү бик авыр булуын белә идек. Шуңа икенче көнне педагогика университетын эзләп таптык та гариза язып калдырдык. Шул көннән мин тел, әдәбият дөньясына чумдым. Татар телендә очраган һәрбер китап, газета-журнал минем игътибар үзәгендә булды. Китап кибетендә татар теле һәм әдәбият дәреслекләре сатып алдым. Имтиханга бик аз вакыт калган иде. Укыдым да укыдым. Ул елны җәйнең нинди булуын хәтерләмим дә хәтта... Күңел ярсый, уйлар тик уку турында. Мәрхүм дәү әнинең: «Бу бала җүләрләнмәсен», – дип борчылулары бер сәбәпсез булмаган икәнен хәзер генә аңлыйм. Ләкин кая ул чакта кемне дә булса тыңлау?!

Имтихан көннәре килеп җитте. Комиссия әгъзалары Чулпан Харисова белән Фоат Галимуллин иде. Әле дә хәтерлим, Чулпан Харисова минем рус мәктәбен бетереп, монда укырга килгәнемә шатланып: «Молодец!» – дип куйган иде. Галимәнең бу сүзе мине канатландырып җибәрде. Аның урынында икенче берәү булса, тормышым да башкача булыр иде, бәлки.

Татар теленнән «яхшы», әдәбияттан «канәгатьлелек» билгеләре булды. Фатих Кәрим иҗаты эләккән иде билетта. Мин аның шигырьләрен яттан сөйләдем, тик Фоат Галимуллинның бер соравына җавап бирә алмадым. Нәтиҗәдә, абитуриентлар исемлегенә эләкмәдем. Директор юлламасы турында да беркем белми иде, кызганыч... Шул кәгазьгә ышанып, хыялларыбызны үзгәрттек бит без!!! Нишләргә? Кире кайту юк! Әти-әни бергә киңәшкәннән соң, мине түләүле укытырга булдылар. Бердәнбер кызлары бит! Абый армиядән соң үз белгечлеге буенча эшләп йөри. Эше авыр булды. Салкында җир астын казып, электр үткәргечләре суза. Акчасы да күп түгел. Мине рухландырып: «Укы, тырыш», – дип торды. Абыем бик акыллы кеше иде. Гел елмаеп торыр, уен-көлке яратыр иде. Гомере генә бик кыска булды шул! 26 яшендә безне калдырып мәңгелеккә китте. Бу хәл әле дә миңа тынгылык бирми. Сау-сәламәт килеш эшкә дип китсен дә, бүтән кайтмасын инде...

Мин 1 нче курс студенты булдым. Сөенгәннәрем! Студент булу – бик җаваплы. Яңа тормыш яңа кыенлыклар тудырды. Белем азлыгы үзен бик нык сиздерде. Яшьтәшләрем ял турында уйласа-

лар, мин гел укуда булдым. Үземне аямадым, дәресләр бетүгә, китапханәгә чаба идем, ашау да онытыла иде. Минем башкалар белән тигез буласым килде шул! Шуңа омтылдым. Үземнең чын татар баласы икәнен исбатларга тырыштым.

Шулай биш ел гомер узды да китте. Ниһаять мин, татар теле һәм әдәбияты белгечлеге алып, шәһәр мәктәбенә эшкә урнаштым. Дистәдән артык елымны балаларны татар теле серләренә өйрәтүгә багышладым. Укытучы булып киткәнемә мин бик шат. Язмыш мине юкка гына мәктәпкә китермәгәндер дип уйлыйм.

Илсөя ЯРУЛЛИНА.

Әлеге фотода – Тын океанда ике дистә елдан артык хезмәт иткән 1 нче статья старшинасы, «чын морячка» Римма Хатыйм кызы Нигъмәтуллина (сулда) һәм әчке гаскәр өлкән сержанты Алла Александровна Месхи.



Алар икесе дә хәрби-диңгез флоты ветераннарының «Экипаж – бер гаилә» ансамбле җырчылары. Ансамбльнең оештыручысы – Төньяк флот юнгасы, 1 нче статья старшинасы, Балтыйк диңгезе ветераны Альберт Серебряков булган. Хәзерге вакытта коллектив белән Мөхәммәт Ниязов җитәкчелек итә. Ансамбль коллективы Казан кадет мәктәпләрендә, уку йортларында һәм хәрби-патриотик лагерьларда чыгышлар ясый, җырлары һәм чыгышлары белән тыңлаучыларны югары рухлы ватанпәрвәрләр итеп тәрбияли. Римма Нигъмәтуллина һәм Алла Месхи икесе дә фидакарь хезмәтләре һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүләре өчен бик күп медальләр белән бүләкләнгәннәр.

– Үземә тапшырылган эшне һәрвакыт намус белән җиренә җиткереп башкардым, – ди тырыш һәм сабыр Мамадыш кызы Римма.

Мәктәптә бергә укып, Хәрби югары уку йортын тәмамлаган сөйгән яры Фәрит белән Владивостокта, Тын океан хәрби флотында иңгә-иң куеп хезмәт итә татар кызы. «Русский остров» дип йөртелгән җиргә 1978 елның августында барып төшә алар. Парис бухтасында, ОВРА дигән шәһәрчектә (охрана водного района) бер-берсенә терәк булып яши башлыйлар. Уллары Артур, кызлары Эльвира туа. Римма Хатыйм кызы шәһәрчектәге элемтә мәктәбендә – диңгезче, тегү остаханәсендә өлкән тегүче булып хезмәт итә. Ире Фәрит Гыйззәт улын яңа частька күчергәч, тормышлары икенче ярдагы Подножье шәһәрчегендә дәвам итә. Римма Хатыймовна электр эшләре буенча механиклар мәктәбендә хезмәт итә башлый. Ире 1 нче ранг капитаны булгач, Нигъмәтуллиннар Казанга әйләнеп кайта.

Уллары Артур – хезмәтен Тын океанда башлаган югары квалификацияле диңгезче. Медальле диңгезче Артур Нигъмәтуллинның балачакта мәңгелек ут янында моряк формасыннан хәрби газетада чыккан собкор фотосы һәм язмасын, истәлекле моряк күлмәген Казандагы ДОСААФ бинасындагы музейда күреп була бүген. Фидакарь, шагыйрь җанлы, җыр күңелле ханымнар – Римма Нигъмәтуллина һәм Алла Месхи – икесе дә әниләр. Үз балаларына гына түгел, төрле милләт балаларында ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләгән алар.

Равилә МӨБАРӘКШИНА.
Казан шәһәре.

Сүзем – эстрадабызның сүнмәс йолдызы, халкыбызның сөекле һәм яраткан җырчысы Хәния Фәрхи турында.

Озак еллар «Бәйрәм» ансамбле белән бергә чыгыш ясаган Хәния Фәрхи беркем белән дә бутамый торган моңлы тавыш иясе иде. Сәхнәдә үз-үзен тотышы, килешкилбәте, тышкы кыяфәте, искиткеч матур күлмәк-костюмнары белән дә аерылып торды. Әдәпле, бик гади, эчкерсез, чиста күңелле, мәрхәмәтле җырчы иде ул. Аны алыштырырлык җырчы юк инде, бәлки, булмас та...

Әй Хәния, Хәния,
Матур иде җырларың.
Үлгән хәбәрең килгәч,
Күпме халык елады.

Оныттырмас сине
«Әлдермешең»,
«Үпкәләсәң, әйдә, үпкәлә»,
«Утыр әле, әни, яннарыма» диеп,
Өзелеп җырлый кызың Алия.

Күпме җырлар калды
җырланасы,
Үрләрне бар иде яулыйсы.
Иңне-иңгә куеп Габделхаең белән
Тормыш сукмагыннан атлыйсы...


Шул яраткан җырчыбызны бик тиз оныттык түгелме? Башка җырчыларга һәйкәлләр, истәлек такталары куйдылар. Ә Хәния Фәрхигә әле дә бернәрсә юк. Халкыбыз яраткан җырчының исемен мәңгеләштерергә иде. Киткәненә биш ел була бит инде...

Гөлиһам МИНГАЛИЕВА.
Яшел Үзән.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адр ес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA

ЯЛГЫЗ КАНАТ





Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

Тормыш арбасын ялгыз тартулары җиңел түгел. Авырлыгы иң элек балаларга төшә. Миләүшә дә улын тайгага җибәрергә рөхсәт бирер идеме соң?! Ире чит хатынга чыгып китсә дә, йөрәк болай әрнемәс иде. Хыянәтен кичерә алмый, мендәр кочаклап елар да, мәхәббәтне нәфрәткә әйләндереп яшәр иде. Ә ул хатынына гына түгел, балаларына, әти-әниләренә, диненә, үзенә хыянәт итте. Миләүшә яшь көе ирсез калды. Тормышта терәк тә, ир-ат назы да бик кирәк икән ул…

Армиядән үк йога күнегүләре өйрәнеп кайта Рәкыйп. Кем нәрсә белән шөгыльләнмәс?! Миләүшә егетнең бу гадәтенә артык игътибар итми. Ике яраткан йөрәк кушыла. Балалары Айрат белән Алия туа. Заманына күрә бик яхшы яшиләр. Фатирлары, машиналары, дачалары бар. Икесе дә абруйлы эштә: Миләүшә – сырхауханәдә балалар бүлеге җитәкчесе, Рәкыйп – инженер. Эчми, тартмый, балаларны ярата. Менә шундый бәхетле гаилә булып унөч ел яшиләр. Ә аннан соң... Рәкыйп кришнаитлар сектасына эләгә. Тыныч тормыш шул вакытта чәлпәрәмә килә. Ире аерым ашый башлый, ә табиб Миләүшә өчен иң җирәнгече – ашаган савытын сыер тизәге белән юа. Берәр ел көндезләрен «бәхетле ир белән хатын» булып яшәргә тырышалар, ә төннәрен әрләшеп чыгалар. Өйләнешкәндә үк балалар янында беркайчан да талашмаячакбыз дип сүз биргән булалар. Тик аларның сере төнгә генә сыймый башлый. Рәкыйп балаларын да үз артыннан ияртергә тели. Өйгә әллә нинди сәер китаплар алып кайта. Балаларга белем бирү хакында ишетергә дә теләми. Ә беркөнне Миләүшә эштән кайтып керсә, улы һәм кызы әтиләре белән телевизордан кришнаитларның куркыныч йолаларын карап утыра. Балалары белән утырып сөйләшә ана. «Сез югары белем алырга тиеш, ә тизәк белән табак юып йөрергә тиеш түгел», – ди ул аларга. Өйдә ике лагерь барлыкка килә: Миләүшә белән балалары һәм Рәкыйп. Көннәрдән бер көнне ир хатынына ультиматум куя: йә сез – минем белән, йә мин китәм. Яраткан кешеңнән шундый сүзләр ишет әле син?! Бу хәлләр белән бетерешкән Миләүшәгә инсульт була. Башын да бора алмыйча хастаханәдә яткан хатыны янына ире килеп тә карамый. Миләүшә өйгә кайткан көнне үк Рәкыйп гаиләдән китәргә җыенуын әйтә. Балалары хакына ул иренә ялына: «Җәйгә кадәр генә кал. Айратның мәктәп тәмамлап укырга керәсе елы. Күңеленә яра салмый торыйк. Түз, зинһар!» Рәкыйп тешен кысып кына ризалыгын бирә. Башка чаралары юк: бер караватка ятып йоклыйлар. Тик алар инде ир белән хатын түгел. Хатын-кыз өчен моннан да зур мыскыл ителү бар микән?! Бик авыр була Миләүшәгә. Ябыгып бетә. Интегеп яшәгән көннәрдә аңа санаторийга юллама бирәләр. Ике дә уйламый җыенып китә. Миләүшә өчен ул «коткару тәгәрмәче» була. Санаторийда ирләр күзе төшәрлек хатын-кыз булуын аңлый.

Килеп урнашу белән табиб бүлмәсен эзләп таба Миләүшә. Чират көтеп утырганда бер сабырсыз ханым тузына башлый. Икенчесе аны тынычландырырга керешә. Боларны карап тора да: «Кешене үзгәртеп булмый, энергиягезне әрәм итмәгез», – ди тынычландыручы хатынга. Һәм шундый ук җөмләне үзеннән берничә кеше алда утырган ирдән дә ишетә. Алар, бер-берсенә карашып, елмаеп куя. Икенче көнне урамда һава сулап йөргәндә очраклы рәвештә генә шул ир белән очраша. Танышып, сөйләшеп китәләр. Өч көн шулай аралашалар. Үзеннән ун яшькә өлкән

Ире ультиматум куя: йә сез – минем белән, йә мин китәм.

Ирек белән ярты сүздән аңлаша. «Хатыным белән күпме яшәп мондый аңлашу юк иде», – дип аптырый ир дә. Ирекнең китәр көне килеп җиткәч: «Сезнең белән элемтәне югалтасым килми», – дип, визиткасын суза. Миләүшә шунда гына аның доцент икәнен белә. «Мин кияүдә. Телефон номерымны бирә алмыйм», – ди хатын. Киләчәктә очрашачакларын белмичә, саубуллашалар...

Миләүшә санаторийдан бөтенләй башка хатын булып кайта. Гаиләдәге авырлыкларның да алай ук фаҗигале булмавын аңлый. Балаларның тамагы тук, өсте бөтен булсын дип өч эштә эшли башлый. Уллары Казандагы югары уку йортына укырга кергәч, ире өйдән чыгып китә. Һәм алар тормышыннан мәңгегә югала. Юк, Миләүшә аның белән очрашачак әле...

Җәй чыккан саен, санавиациягә утырып Казанга оча. Студент улына азык-төлек алып бара. Монысы сәбәп кенәдер. Өйдән чыгып киткән улын бик сагына ана. Ул бит аның терәге! Башкаладан үз шәһәрләренә автобус белән кайта. Әнә шундый кайтуларның берсендә Ирек белән очраша. Аның Миләүшәләр шәһәрендәге институтка лекция укырга баруы икән. Юл буе сөйләшәләр. Миләүшә аңа бу юлы өй телефонын бирә. «Өйдәгез, очрашыйк», – ди аңа Ирек. «Балаларга ишетелсә, күзләренә ничек карармын», – дип, хатын очрашуларны кире кага. Аның хәлен аңлый Ирек. Бәхетләр теләп, югала. Ике елдан соң тагын шалтырата. «Җаннар туры килмәсә, гаиләне ничек теләсәң дә саклап булмый икән ул. Балалар белән утырып сөйләштек тә, хатыным белән тыныч кына аерылыштык. Сине онута алмыйм. Санаторийдагы берничә көн эчендә минем кеше булуыңны аңладым бит. Әйдә, бергә булыйк, күчен Казанга», – ди ул. Ирекка карата җылы хисләре булса да, ир дип бер шәһәрдән икенчесенә кубарылып күченеп йөрергә балаларыннан кыенсына. Ничек инде 45 не узгач, мин кияүгә чыгам дия алсын ул балаларына?! Җитмәсә, алар әле башлы-күзле дә түгел. Чит ир барыбер әти булмаячак. Ирекнең тәкъдимен шулай кире кага ул. Башка шалтыратмавын үтенә.

Өченче курста Айрат укуын ташлый. Ул бу хакта әнисенә Яңа елның беренче көнендә әйтә. «Алия Казанда укырга тиеш. Бюджет урыннар аз. Ә түләп укытырга акчабыз юк. Себергә барып акча эшләп кайтам. Соңыннан укуымны дәвам итәрмен», – ди ул. Сеңлесен аталарча кайгырткан улын кочаклап озак елый Миләүшә. Аның белән әле горурлана, әле аны сүгеп ата. Янында әтисе булса, бу кадәр үк җаваплылыкны үз өстенә алмас иде, гаиләдә ир-ат терәк шул, хәзер бу улыма төшәмени инде дип уйлана. Ялгыш

Фото: www.pixabay.com

Бәхетең булмагач, юк икән инде ул...

адым булып, бөтен язмышын үзгәртеп куймас микән дип икеләнә. Ләкин белә: уеннан кире кайтмаячак улы. Айрат укыган институтка барып сөйләшер өчен Яңа ел бәйрәмнәре беткәнен көтә. Ут эчендә янган ана өчен, ай-һай, озак үтә ул көннәр. Бәйрәмнән соң туп-туры деканга барып, хәлне аңлата. Улының бу адымга бару сәбәбен сөйли. «Сезнең улыгыз хөрмәткә лаек. Исән-сау булсам, мин аны берсүзсез кире кабул итәчәкмен», – дип тынычландыра декан. Үз шәһәрләренә кайтуга ук Айрат Себергә баручы вахтаны эзли башлый. Ананың җибәрәсе килми. Уе барып чыкмаса гына ярар иде дип тә тели. Тик беркөнне Айрат аның эшенә шалтырата: «Мин иртәгә вахта белән китәм. Себер шартларында эшли ала дигән белешмә генә ясап алып кайтчы». Себер бит ул! Андагы үзәккә үтә торган салкыннар хакында ишетеп белә Миләүшә. Туганнардан җылы кием-салым җыялар. Миләүшә, төне буе елый-елый, өчпочмаклар пешерә. Сеңлесенең туган көнендә юлга кузгала Айрат. «Алияне уятмыйк», – ди ул. Мендәр астына куярсың дип, сеңлесенә язган хатын әнисенә суза. Үзе Себернең кайсы почмагына алып китәселәрен дә белми. Озатырга килгәч, борчылып сораштыра башлаган ананың күңеленә ут салып: «Сезгә барыбер түгелмени? Вертолеттан тайгага ташлаячаклар аларны. Ә анда элемтә юк. Цивилизациягә барып җиткәч шалтыратыр. Ә аңынчы без алар белән рация аша сөйләшеп торачакбыз. Бер-бер хәл булса, шалтыратырбыз», – дип «тынычландыралар». Улы утырган автобус китә, ә ана, агач төбенә чүгәләп, еларга тотына. «Улымны озаттым, тик кая җибәргәнемне белмим», – ди ул үкси-үкси, янына килеп юаткан бер хатынга. Ул да ирен озаткан икән. «Ирем инде тәҗрибәле. Килеп төшүгә үк хәбәр бирү җаен таба. Мин сезгә шалтыратырмын. Цивилизациягә ике атна барачак алар. Сезнең улыгызга күз-колак булырга кушармын», – ди хатын. Баксаң, яңа танышкан ханым баласы белән Миләүшә эшләгән бүлектә дәваланып чыккан булган икән. Бүлек башлыгын шуннан таныган.

Улы бер айдан соң шалтырата. Үзенә «студент» дип кушамат тагуларын әйтә. Киткәндә кат-кат әйтә шул Миләүшә: «Бер тапкыр авызыңа хәмер кабасың икән, юлдан язачаксың. Анда ирләр кыстар, ризалаша күрмә. Бер бирешмәсәң, башка бәйләнмәсләр». Ирләр аракы эчкәндә, Айрат шоколад ашый икән. Кушамат та шуннан тагылган. Улы борчылмаска кушса да, Миләүшә, кайгырып, ябыга, суырыла. Ана улының кайтыр көннәрен саный. Нәкъ ике ай ярымнан соң кайта ул. Бар эшләгән акчасын әнисенә тоттыра. Ябык, куллары мазутта, ә үзе шундый бәхетле...

Декан сүзендә тора. Айратны институтка кире алалар. Алия дә Казанга укырга керә. Гаилә башлыгы булып калган улы әнисенә фатирларын сатып, Казанга күченеп килергә киңәш итә. «Без монда, ә син анда ялгызың», – ди ул. Ике бүлмәле фатирларын саткан акчага Казан читендә бары тик бер бүлмәле фатир алалар. Кысанлыгына шаккатмыйлар. Бергә булудан тәм табалар. Акча җиткерә алмаганлыктан барысы да эшли башлый. Миләүшә балалар сырхауханәсенә урнаша, Айрат укудан соң грузчик булып мебель ташый, Алия идән юа.

Бер яңгырлы көнне метродан чыгып барганда Миләүшәгә берәү китап суза. (Кришнаитлар сектасында булучыларның кешеләргә китап тәкъдим итеп йөрүләрен күргәнегез бардыр?) Зонтигын күтәреп карагач, таныш күзләр белән очраша хатын. «Бу бит Рәкыйп!» – дигән уй уза. Миләүшә елмая, ә ир борыла да тиз-тиз китеп бара. Яңгырда чыланып беткән, иңсәләре төшкән, бөкрәеп атлап китеп барган ирен бик жәлләп карап кала ул. Әмма артыннан барырга батырчылык итми. Икесе ике яр кырыенда икәнен аңлый Миләүшә. Ә ярлар кушылмый... Бу очрашудан соң ике ел узгач, Рәкыйпнең апасы аның фаҗигале төстә вафат булуын хәбәр итә. Рәкыйп Миләүшәне очратуы хакында аңа сөйләгән булган. Соңгы елларда һәрвакыт: «Хатыным бигрәк яхшы иде», – дип, аны гел мактаган.

Авыр еллар инде күптән артта калды. Улы нефть тармагы өлкәсенә эшкә урнаша. Компанияләре аны чит илгә эшләргә җибәрә. Гаиләсе белән улы шунда китә. Әнисен, бар чыгымнарын күтәреп, үзләренә кунакка чакыра. Миләүшәнең чит илләр күрәсе килү хыялын улы шулай тормышка ашыра. Кызы да, шөкер, башлы-күзле. Оныклар белән мәш килә Миләүшә. Ана буларак, бик бәхетле. Әмма хатын-кыз бәхетен татый алмады. Бәхетең бер булмаса, юк икән инде ул. Казанга килгәч, Ирек исенә төшсә дә, аны эзләми. Шулай язгандыр, балаларыма шулай яхшырак булгандыр дип юата үзен. Бәлки, иң элек хатын-кыз булуы турында уйлап, сөю ләззәтен татып каласы булгандыр. Балалары белән утырып сөйләшәсе калгандыр. Бәлки, алар хуплаган да булыр иде.
Юк, улы алар гаиләсендә чит ирне күрергә теләмәс иде, мөгаен. Ул үзен бик тиз гаилә терәге итеп куйды шул: Миләүшәне, сеңлесен кайгыртты. Әнисенең башка ир белән кушылуын хыянәт итеп кабул итәр иде. Еш уйлый ана шулар хакында. Ә хәзер инде гомер узган. Балалар дип узган ул гомер. Бар наз да, мәхәббәт тә аларга бирелгән. Шунысы сөендерә: заяга узмаган. Алар – Миләүшәнең терәге, Миләүшәнең горурлыгы. Әмма тормышта хатын-кыз ялгыз булырга тиеш түгел икән... Һич тә...

ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ КОТЛЫЙБЫЗ!

Электр грилеме, җиләк-җимеш киптерү җайланмасымы, әллә иттарткычмы?

Һәр хуҗабикә өчен боларның арадан берсен сайлап алу да читен... Һәркайсы үз урынына кирәк! Ә бит хатын-кызның эшен күпкә җиңеләйтү өчен уйлап чыгарылган бу техникаларның берсе сезнеке була ала иде!

«Сөембикә» редакциясе 2022 елның беренче яртыеллыгына һәм тулы бер елга журналга язылучылар арасында бүләкләр уйната дип күптән игълан иткән идек. (Сүз уңаеннан: ә сез журналга бер елга да язылып куярга мөмкин икәнен беләсезме? Индексын хәтерләп калыгыз: П8299)

Бүләк оту шартлары бик гади иде: «Сөембикә»гә язылырга һәм квитанциянең күчермәсен редакциягә җибәрергә кирәк иде.

Квитанция күчермәләрен 211 укучыбыз юллады. 25 гыйнвар көнне без аларның соңгыларын кабул иттек һәм 28 гыйнвар көнне, «Сөембикә» журналының инстаграм битендә барган туры эфирда алдан вәгъдә иткән әлеге бүләкләрне уйнаттык.

«Сөембикә»не гаиләдә иң элек әти кеше укый, аннары гына чират башкаларга җитә», – диләр. Дөрес ул! Югыйсә җиңүчеләр арасында ир-ат та булыр идеме?!

«Сөембикә» – бөтен дөньяга таралып яшәгән татар хатын-кызларын берләштерүче журнал», – диләр. Хак әйтәләр! Бүләкләрнең берсе юкка гына Башкортстанга китми!

«Сөембикә» – күңел өчен, җан өчен», – диләр. Шулайдыр... Җиңүчеләр арасында журналның тугры дуслары булуы да очраклы түгел бит!

БҮЛӘКНЕ МЕНӘ КЕМНӘР ОТТЫ:

Электр гриле:
Римма Авзалова (Мөслим),
Рөстәм Сәлахов (Казан).

Җиләк-җимеш киптерү җайланмасы:
Инзилә Тимергалиева,
Эльза Ярмөхәммәтова (Казан).

Иттарткыч:
М. Вәлиуллина,
Лилия Исхакова (Башкортстан, Бәләбәй).

Җиңүчеләрне чын күңелдән котлыйбыз! Игелекле бүләкләр булуын, сезгә күп еллар хезмәт итүләрен телибез! Һәм кабат исегезгә төшерәбез: «Сөембикә»дән иң зур бүләк – ул үзе! Көтегез – һәр ай саен балкып өегезгә килеп керәчәк! Сагындырып, сөендереп, рәхәт кичләр вәгъдә итеп...

Җиңүчеләрнең редакция белән элемтәгә керүләрен көтәбез.
Безнең телефон: 8 (843) 222-09-77.



ГОМЕРЛӘР ЮРАСЫН, БӘХЕТЛӘР СОРАСЫН


Фото: авторның шәхси архивыннан

Кайларда йөрисең, сөйгән яр?

Кәккүкләр моңая,
Кәккүкләр еракта.
Кешеләр шикелле алар да.
Гомерләр юрасын,
Бәхетләр сорасын
Кәккүкләр без сөйгән ярларга.

Кайларда йөрисең,
Син хәзер кем белән,
Яшьлектә өзелеп сөйгән яр?
Кәккүкләр юраган
Бу озын юллардан
Гел бергә барырбыз дигән яр.

Кәккүкләр ник моңлы?
Кәккүкләр исәпли
Без бергә үткән ул елларны.
Онытмас микәнни
Кәккүкләр без бергә
Откан ул җырларны, моңнарны?

Рафис КОРБАН

1980 нче елларда миңа Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакциясендә эшләргә насыйп булды. Ул елларда радиодан яңгыраган концертларны төзүче буларак кына түгел, музыкаль редакция фонотекасын яңа язмалар белән тулыландыру буенча да зур һәм җаваплы вазыйфа башкарырга туры килде. Республикада гына түгел, бөтен татар дөньясының җыр-музыкага булган ихтыяҗларын канәгатьләндереп торган бердәнбер радио иде ул вакытта Татарстан радиосы. Кайлардан гына хатлар алмый идек без! Җыр, музыка сөюче радиотыңлаучыларыбыз теге яки бу җырны ишетергә теләүләрен белдереп язалар. Нинди генә кызыклы, мавыктыргыч, халык яратып тыңлый торган тапшырулар әзерләмибез... Көненә ике сәгатьтән дә артмаган музыкаль тапшырулар өчен бирелгән вакытта нинди генә эчтәлекле, төрледән-төрле музыкаль программалар яңгырамый да, нинди генә яңа җырлар эфирга чыкмый!..

Радиокомитетның заман таләпләренә җавап биргән тавыш язу студиясе бар иде. Композиторларыбызның әсәрләрен югары сыйфат белән магнитофон тасмасына яздыралар иде анда. Шул елларда миңа берара хәтта ул студиянең өлкән редакторы булып эшләп алырга да туры килде. Республикабызның күренекле сәнгать осталарыннан, музыкантлардан, шагыйрьләрдән торган сәнгать советы студиядә яздырыла торган әсәрләрнең профессиональ яктан югары сыйфатлы, камил булуын тикшереп кабул итә. Язмаларны энә күзеннән үткәрә торган ул сәнгать советы бүген күпләгән радиоларда тапшырыла торган җырларның берсен генә дә эфирга үткәрмәгән булыр иде. Ярар, ул җырларның сыйфаты турында сөйләүне бер читкә куеп торыйк. Сәнгать советы кабул итмәгәч, яңа текст иҗат иткән чаклар да була иде. Студиядә яңадан язылып, халык арасында популяр булып киткән шундый җырларның берсе белән таныштырасым килә.

Сиксәненче еллар башы. Җырчылар Газинур Фарукшин, Азат Хөсәенов-Тимершәех, Айдар Фәйзрахманов, Искәндәр Биктаһиров, Зөһрә Шәрифуллиналарның эстрадада әле яңа күренә башлаган еллары. Бүгенге шикелле көтү-көтү булып түгел, берәнсәрән генә дөньяга чыга башлаган яңа тавышлар, яңа талантлар. Татарстан радиосы яшь иҗатчыларга тормышка путёвка, үзенә күрә фатиха бирә торган оешма иде ул вакытларда. Беренче җырларын алар радионың тавыш яздыру студиясенә алып киләләр. Сәнгать советы язмаларны тыңлап, бәя бирә. Уңышлы башкарылганнарын кабул итеп, фонотекага саклауга тапшыра. Сират күперен кичкән ул язмалар радио концертларында программага кертелеп, дөньяга тарала, халыкка барып ирешә. Җырчы шулай итеп популярлык казана.

Шул елларда сәнгать советы төрле җырчылар башкаруында яшь композитор Илгиз Закировның берничә җырын тыңлады. Илгизнең беренче кабул ителгән җыры «Бар ул син эзләгән кеше» иде бугай, ялгышмасам. Җырларының берсен, «Яныңа ашыгам» дигәнен яшь җырчы Зөһрә Шәрифуллина башкарды. Шагыйрь Фәннур Сафин шигыренә язылган җыр иде. Зөһрәнең дә әле радиога яздырган тәүге җырларының берсе бу. Фәннур инде – җырчы шагыйрь, җитмешенче елларда ук таныла башлады. Аның «Хушлашырга ашыкма», «Берни сорама», «Ялгыз көймә» дигән җырларын халык аеруча яратты. Фәннур сиксәненче елларда җырчы шагыйрь булып киң танылып, хәтта радиокомитетның сәнгать советы әгъзасы да иде. Ә менә бу җырны, сүзләрендәге җитешсезлекләр аркасында, совет ул вакытта кабул итмәде. Җыр текстлары иҗат итү өлкәсендә азу тешле чыгарган шагыйрьләр Сибгат Хәким белән Гөлшат Зәйнашева бик таләпчән иделәр. Җырның сүзләрен үзгәртергә кирәк дигән фикер әйтелде.

Мин дә бу елларда – танылып килүче яшь шагыйрь, радиога яздырылырга тиешле җыр текстларының камиллеге өчен җавап бирергә тиешле редактор. Автор белән башкаручы – Илгиз һәм Зөһрә шул көнне үк әлеге җыр сүзләрен алыштырырдай яңа текст язып бирүемне сорап мөрәҗәгать иттеләр. Уйлап карармын дип калдым да, җырның магнитофон тасмасындагы язмасын берничә мәртәбә тыңладым. Шуннан соң Фәннурны бөтенләй кабатламый торган шигырь иҗат иттем. «Кайларда йөрисең, сөйгән яр?» дип атала иде ул. Беркадәр салмаграк һәм моңсу, сагышлы җыр тексты килеп чыкты. Ул үзе шикелле үк сагышлы көй дә сорап тора иде. Шигырьне Илгиз дә, Зөһрә дә ошатты. Берникадәр вакыттан соң Зөһрә радиога килеп, Илгизнең салмак темпта җырлана торган итеп үзгәрткән көен яңа сүзләр белән җырлап, магнитофон тасмасына яздырды. Яңа җыр менә шулай туды.

Заманалар үзгәреп, туксанынчы елларда «Барс-Медиа» студиясе чыгарган дискларны әйләндерә торган «Казан радиосы», «Дулкын» дигән каналлар килеп чыгып, шуларның берсендә Салават Фәтхетдинов башкаруында «Яныңа ашыгам» дигән җырны ишетергә туры килде. Бу Илгиз Закировның Фәннур Сафин шигыренә язган әлеге шул сәнгать советы кабул итмәгән җыры иде. Бу вакытта инде дөньялар үзгәргән, Татарстан радиокомитеты да ГТРК һәм Болгар радиосы дигән студияләргә таркалган, сәнгать советы дигән нәрсәләр дә юкка чыгып беткән иде. Салават башкарган ул җыр «Кайларда йөрисең...»нән көе белән дә, сүзләре белән дә бөтенләй аерылып торган, нигезендә яткан кайбер ноталар яңгырашындагы охшашлыгы белән генә ике бертуган икәнен сөйләп торган язма иде.

Зөһрә Шәрифуллина башкаруында «Кайларда йөрисең, сөйгән яр?» дигән бу җыр һәр кешегә яшьли яратышып та, кавышалмый калган беренче мәхәббәтен искә төшереп, йөрәк түрендә сакланган тирән сөю хисләрен яңартып торган сагышлы, моңлы бер җырга әверелде. Җыр эфирда яңгырый башлаган елларда радиотыңлаучылардан, җыр сөючеләрдән күпләгән хатлар ала идем. Әлбәттә, сүзе белән көе тәңгәл килгәндә генә җыр уңышка ирешә, күңел кылларын тибрәтергә сәләтле була. Җырчы моңлы тавышы, тыңлаучыны хисләндерерлек итеп башкаруы белән җырга озын гомер алып килә. «Кайларда йөрисең, сөйгән яр?» әнә шундый бәхетле язмышка ия. Моннан өч дистә елдан артык элек язылган булса да, ул әледән-әле радиолардан яңгырый.

Кайларда йөрисең,
Син хәзер кем белән,
Яшьлектә өзелеп сөйгән яр?..

Әлбәттә, Илгизнең җырын саклап калу өчен язылган сүзләр генә түгел иде бу. Шигырьне мин чынлап та яшь чакта яратып йөргән кызларны күз алдында тотып яздым. Мин үзем егет чакта бик тиз гашыйк булучан, һәм гыйшык утында күп тапкырлар дөрләгән кеше. Студент елларымда үлеп гашыйк булган бер кызның кулыма язу карасына манып энә белән дә язып куйган исеме хәзер дә аны искә төшереп тора. «Бу җырыңны хатының ничек кабул итте?» – дип тә сорашучылар булды. Әйтә алмыйм. Бәлки, ошатмагандыр да... Тик ул хакта миңа сиздергәне булмады. Хәер, кемнең генә беренче мәхәббәте булмаган да, кемнәр генә аны сагынмаган икән! Аның да яшьлегендә беренче сөйгән яры булгандыр. Шуңа күрә бу җыр турында берни дә сөйләшми идек. Әлеге җыр эфирда яңгыраганда, үзе кушылып җырламаса да, сагышка бирелеп тыңлый торган иде...

ХАТЛАР ЯЗАМ, ӘНИ, СИҢА ХАТЛАР...

Фото: Анна Арахамия

Хатлар язмыйбыз шул хәзер әниләргә. Телефоннан гына шалтыратабыз. Бер-ике сүз алышабыз да күңелебез була. Тормыш бит инде, сәбәп табып, әниләр янына да сирәк кайтыла. Алар менә шулай мәңге безне көтәр сыман. Кайчан кайтсак та капкасын ачар, кайчан шалтыратсак та, телефоннан эндәшер кебек. Ә эндәшмәсә?! Юк, моны күз алдына китерү түгел, бу хакта уебызга да китермибез. «Әнисез тормышның нинди икәнлеген белмисез дә, аңламыйсыз да, – ди «Интертат» интернет-газета журналисты Алинә Айдарова. – Әниегез искә төшкән саен телефоныгызга үреләсездер. Ә мин әниемә хатлар язам. Тик мин аларны җибәрә генә алмыйм...» Тормышының иң ачы хәсрәтен Алинә үзе сөйләсен әле.

Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Әтием Айдар – Урал ягыннан ук. Актаныш районы Усы авылына армиядә бергә хезмәт иткән иптәш егетенә кунакка кайткач, әни белән танышкан. Алар гаилә корып, Чаллыда яши башлый. Әтием бик чибәр минем, әнием дә чибәр булган. Алар, мөгаен, бик матур пар булганнардыр. Аларга сокланганнардыр... Абыем туган, җиде елдан соң мин дөньяга килгәнмен. Төпчек кыз итеп бик иркәләп кенә үстергәндер мине әнием. Әнинең назы, әнинең куллары нинди булганын белмим мин... Хәтерләмим... Миңа 3 яшь тулганда, үпкәсендә яман шеш авыруы булып әни үлеп китә. Әни табиб булган. Үләсен, мөгаен, белгәндер ул. Туган авылымда, туган нигеземдә соңгы сулышымны алыйм дип теләгәндер әни. Якты дөнья белән хушлашуына ике-өч көн кала, әтидән авылга алып кайтуын сораган. Бик кечкенә чагын кеше хәтерләми, диләр. Ә минем ул көндәге бер мизгел хәтеремдә уелып калган. Өй уртасында яткан әнинең өстенә ак простыня ябылган... Аның тирәсендә кешеләр утыра. Кайсы апаның кайда утырганын бик ачык хәтерлим... Аннан соң безне күрше Луиза апаларга керткәннәр дип беләм. Кечкенә иңнәренә нинди зур кайгы килгәнен сизенгәндер бала күңеле. Шуңа да истә калгандыр... Минем абый бәхетле. Ул әнине хәтерли. Әни үлгәндә аңа 10 яшь булган. Ул аны минем кебек фотолардан түгел, ә тормышта күреп белә, әнинең тавышын ишеткән, аның җылысын тойган... Ун ел әниле булып яшәгән бит ул!

Әнине җирләгәч әти безне алып Чаллыга кайткан. Хәзер уйлыйм да шаккатам. Әти үзе ничек түзде икән ул?! Аның йөрәге ничек шартламады да, ничек сыгылып төшмәде икән? Яраткан кешесен югалту өстенә, кулында ике бала. Ул бит ир-ат! Бу хакта әти белән сөйләшмибез. Әни турында сораштырасым килсә дә, сорамыйм. Аңа әни турында сөйләү бик авыр икәнен аңлыйм. Яраларын кузгатмыйм дип уйлыйм. Ул әнине һаман яратып яшидер кебек...

Кечкенә чакта әтидән әнине сораганымны хәтерләмим. Сораганмындыр инде. 3 яшьлек балага: «Әниең үлде», – димәгәндер әти. Балалар бакчасына йөрдем. Ә анда, гадәттә, балаларын әниләр алып килә. Бөтенесенең дә әнисе бар! Беренче класска укырга кергәндә әнинең үлгәнен аңлый идем инде. Әни турында сорагач: «Ул үлде», – дигәнем хәтердә. Әни дигәч, кайчак күз алдыма Гөлназ апа килеп баса. Ул безнең белән озак яшәмәгән. Мин аңа әни дип әйткәнмен. Ул миңа якын. Нигә якынмы? Һәр баланың күңелендә әнисенә карата наз, мәхәббәт бардыр. Ул аны әнисенә бүләк итәдер. Мин, күрәсең, булган бар назымны аңа ачканмындыр. «Әни» дип әйткәч, димәк, мин аны әни дип кабул иткәнмен бит! Иң кадерле ул сүзне башка беркемгә дә әйтә алмадым, әмма бик әйтәсем килә... Бәлки, Гөлназ апа да безне яраткандыр. Ул киткәч: «Сезне яратмаган», – диючеләр булды. Безне ярата алмаудан киткәндер дип уйламыйм, әтинең салгалый торган гадәте бар иде. Шуңа түзә алмагандыр... Ә бәлки алар арасында әни торгандыр... Ә яратуга килгәндә... Кеше баласын яратып булмый ул! Моны улым Данияр тугач аңладым. Юк, ни генә әйтмәсеннәр, кеше баласын яратып булмый. Аны тәрбияләп-карап була, ботка пешереп ашатып була, җаваплылык сизеп була, әмма яратып булмый. Ана назы ул башка... Шуңа да Гөлназ апа яратмаган булса да, үпкәләмим. Быел Чаллыга кайткач, улым белән урамда йөргәндә, очраклы рәвештә генә Гөлназ апа белән очраштык. Кочаклашып алдык. Сиздем: безнең арада нindidер импульс булды. Кулымда бала, үзем елыйм... Хәзер Гөлназ апа белән телефоннан сөйләшеп торабыз. Аның белән сөйләшеп алганнан соң шундый рәхәт булып китә, җиңеләеп калам кебек...

Мин бишенче сыйныфка барганда үги әни белән яши башладык. Исемдә әле, әти: «Без башка фатирга күчәбез», – диде. Шатлануларымны күрсәгез. Хыялым чынга аша бит. Әниле булам! Җитмәсә, аның ике кызы бар икән. Минем үз апа-сеңелләрем булачак! Бу көнне төнлә йоклый алмадым. Сөенүдән шулай дулкынланганмындыр, мөгаен.

Әти белән аларга күчендек. Очып барганда килеп бәрелсәң, бик авыртадыр ул. Монда да шулай булды. Бик авыртты! Күңел авыртты! Үги әнигә «әни» дип эндәшә алмадым. Бер тапкыр да! Бик теләсәм дә, эндәшә алмадым. Бәлки, зур булганмындыр инде. Начар яшәдек дип әйтә алмыйм. Бәйрәмнәр дә үткәрә идек, көлешә дә идек. Әмма ул мизгелләр генә. Үзем

Әни кем ул?.. Рәхәт кешедер ул. Тикмәгә генә, хат язгач, миңа рәхәт булып китмидер.

дә гаепле булганмындыр дип уйлыйм хәзер... Мине үз кызларыннан аеруын сизмәдем сизүен. Ул вакытта мәктәпкә формадан йөри идек. Икебезнең дә формаларыбызга ак яка тегә иде. Караганы өчен рәхмәтле мин аңа. Әмма җылылык, хисләр булмады. Аннан да сизмәдем, үзем дә бирә алмадым. Мөнәсәбәтләр вак детальләрдән корыла бит ул. Алар белән яши башлагач, беркөнне чәй эчкәннән соң, кечкенә кызы килеп: «Апамның чәшкесеннән башка чәй эчмә!» – диде. Гаиләдә һәр кешенең үз чәшкесе булу гадәти хәл бит югыйсә, әмма минем күңелне сызып алды. Аннан соң шикәр комы сала торган махсус кашык белән белмичә чәй болгатканмын. Моны да төртеп күрсәттеләр. Бәлки, минем болай да китек күңелем менә шушы вак әйберләрне авыр кабул иткәндер. Белмим... Әмма без бер өйдә ике гаилә яшәдек: ул кызлары белән һәм мин әти белән. Алты ел бер юрган астында йоклаган кызлар белән без хәзер аралашмыйбыз. Югыйсә бер-ике ай фатир «снимать» итеп торган кызлар белән дә дусларга әйләнәсең... Үги сеңлем белән хәзер дә бик аралашасым килә. Кунакка да чакырып карыйм. Даниярны күрсәтәсем килә. Әмма ул килми...

Ул вакытта кычкырышулар, шапылдатып ишек ябып чыгып китүләр булмады булуын. Мин мәктәптән кайтып кермәдем. Гали Акыш исемендәге лицей-интернатында укыдым, лицей газетасының баш мөхәррире идем, музыка мәктәбенә, биюгә, театр түгәрәгенә йөрдем. Гаиләдә булмаган җылылыкны онытырга тырышуым да булгандыр шулай. Аннан мин үсмерлек чорына кердем. Ятимә кыз өчен генә түгел, әниле балалар өчен дә авыр чор ул. Күңелгә шушы вакытта әни бигрәк тә кирәк. Әнигә хатлар яза башладым. Музыка мәктәбендә укытучым «Хатлар язам, әнкәй, хатлар язам. Беләм инде барып җитмәсен...» дигән юллары булган җыр бирде. Шуны җырлаганда әнигә хат язу уе тугандыр... 13 яшь иде миңа. Аяктагы йонны беренче тапкыр кырганнан соң әнигә утырып хат яздым. Сирәк кенә булса да, әнигә хатлар язарга гадәтләндем шулай. Күңелемә шул рәвешле рәхәтлек тапканмындыр, күрәсең.

Үги әни белән алты ел яшәгәннән соң, көннәрдән бер көнне әти: «Үзебезгә кайтабыз!» – диде. Ул да җылылык тапмагандыр инде. Безнең халыкта, өйләнешкәч, яшәргә кирәк дигән кысалар бар бит. Әтинең дә шуңа аерылышасы килмәгәндер, түзеп яшәгәндер. Әмма озак түзеп яшәп булмыйдыр ул... Якынлык булмагач, гаилә булмый инде ул. Югыйсә үги әни начар кеше дә түгел иде. Ул бит безне ашатты, карады! Әмма без аралашмыйбыз. Бергә торганда аралашмаганны инде...

Ә ул вакытта җыендык та кайтып киттек. Мин 10 нчы сыйныфта укый идем. Алардан кайтып китү авыр булмады. Гомумән, тормышның ул чоры булмаган да кебек иде. Ә миңа бик рәхәт иде өйдә. Ул фатирга һаман да кайтырга яратам. Анда әнинең фотографияләре бар... Үз өебезгә кайткач, әти дә үзгәрде. Үз өендә яши башлаганга микән, өстеннән тау төшкәнгә микән?!. Әнигә дә хат язуларым ешайды... Ул хатларда тормышка карата үпкәләүләрем дә бар... Әти эчкәләгән вакытларда үземне бик ялгыз итеп тоя идем шул. Юк, башын ташлап эчмәде ул, безне карады, ярдәм итте. Әмма сынган чаклары булды. Бик авыр вакытлар иде ул. Иң шатлыклы мизгелләрне: Яңа елда Чаллының төп чыршысы куелган стадионда җырлау, «Сабантуй гүзәле» бәйгесендә катнашу, чыгарылыш сыйныф кичәсендә шатлыклы минутлар кичерү сөенечен әти белән бүлешә алмадым. Янәшәмдә әнием юклыгының бөтен ачысын тойдым шунда. Менә шул чакларда әнигә сыенасым килде... Әтине дә аңлыйм. Тикмәгә генә эчмәгәндер... Аңа бик авыр булгандыр. Әни булса, безнең тормыш бөтенләй башкача булыр иде бит. Әти бу хакта уйламый гына яшәмәгәндер. Бик көчле кеше ул, ләкин сыгылмый гына яшәп булмагандыр. Әтигә үпкәләремне белдереп, әнигә хат язганда, «Әтиеңне кичер», дип әйтә төсле иде әни. Хәзер, еллар үткәч, кичергәнемне аңлыйм. Ул бит минем әти. Бүген нинди булуымда әтинең өлеше зур. Бик тырыш кеше ул. Мине университетта түләп укытты, киендерде... Әти мине бик ярата. Ул әле һаман да: «Бәләкәй кызым», – ди миңа. Хәзер ул оныкларым дип яши. Минем улым, абыемның ике баласы бар. Һәрбер оныгын кайгырта. Алар өчен йөгереп йөри. Ә мин аның парлы булып яшәвен телим. Әтиемне өйләндерәсем килә. Берәр яхшы күңелле апа аңа кияүгә чыксын иде. Мин ул апага «әни» дип эндәшер идем. Без бик якын булыр идек. Бәлки, дөньяда әти дә, мин дә бу кадәр ялгыз булмас идек...

Казанга укырга кергәч, студент тормышы башланды. Уку, яңа дуслар, егетләр... Һәм бер көнне аңладым: әнине искә алмый яшим икән бит! Шимбә көн иде ул. Казанга якын районнардан булган дус кызлар өйләренә кайтып китте. Мин тулай торакта ялгызым калдым. Шул көнне үземне ачуланып бик озак еладым. Әнине дә онытканмын, сеңлесе Фиразия апага да шалтыратмаганмын. Шул көннән соң әнине бер көн дә исемнән чыгарганым юк. Фиразия апага да шалтыратып торам. Актаныштa Усы авылында яши ул. Әниләр сигез бала үскәннәр. Фиразия апа белән аеруча якын булганнардыр. Минемчә, әни Фиразия апа кебектер, тавышы да аныкына охшаштыр. Шуңа да бик-бик якын ул миңа. Нишләп Фиразия апа гаиләсендә тумадым икән дип уйлаганым да бар. Балачакта һәр җәйне Актаныштa үткәрдем. Шул вакытларда үземне аларның кызы итеп хис итә идем. Авылда минем арттан йөргән егетләр дә, мине шушы авылда, шушы өйдә яши, Чаллыга укырга барып йөри

дип уйлыйлар иде. Шулай дип уйлаулары рәхәт иде. Мин аларга кунакка кайткан кебек түгел. Хәзер дә! Мин анда бөтенләй башка. Мин анда – үзем. Битлекләрсез! Ирем дә сизә аны. Ул да аларга кайтырга ярата. Илназны Фиразия апа да, ире дә яратты. Алар уртак тел тапты. Әни дә яратыр иде... Әни урынын алып булмыйдыр, әмма Фиразия апага бөтен хөрмәтне күрсәтәсем килә. Берсендә Фиразия апа кунакка килде. Мин аны кайларда гына йөртмәдем! Аңа бөтен нәрсәне бирергә теләдем... Ул да мине әниләр кебек – шартларсыз гына яратадыр дип уйлыйм. Беләм, ул миңа бәхет тели...

Әнигә хатлар язудан туктамыйм. Әниле кешеләр әниләренә шалтыраткан вакытта, мин әнигә язамдыр инде ул. Әнигә бит инде нинди күлмәк киярга икән дип шалтыратмыйсың, ә күңелне борчыган сорауга җавап табу өчен шалтыратасыңдыр. Бәлки, син ул сорауны аңа бирмисең дәдер, әмма әниең белән сөйләшә-сөйләшә аңа җавап табасыңдыр. Мин дә нәкъ шулай. Тормышымда җитди адым ясар алдыннан йә берәр сорау килеп туса, аңа хат язам. Хат язганда җавап табыла, әнинең фатихасын алам кебек. Никах көнне дә иртән үк торып яздым. Яраткан кешемә кияүгә чыгам бит. (Илназ – әнинең каберенә алып барган бердәнбер егет. Ул вакытта җитди итеп йөрми дә идек әле. Шулай туры килде.) Шундый бәхетле көнемдә янәшәмдә әни юк! Визажистка барып утырдым, һаман күзем яшьләнә. Ә мине бизәндерергә кирәк. Кәгазь алдым да, кабат әнигә үземнең кичерешләремне сөйләп, хат яздым. Тынычландым. Мин әнигә һәрвакыт кулдан язам хатны. Шулай рәхәтрәк. Туй көнне дә әнигә хат яздым. Елый-елый... Туебызда да әниемне искә алып, аңа рәхмәтемне әйтеп шигырь укыганда еламый түзә алмадым...

Бала тапканда тулгагым 20 сәгать дәвам итте. 20 сәгать буе әнигә хат яздым дисәм, ялганламам. Ул вакытта күп кеше әнисенә шалтыратыйдыр, мөгаен. Ә мин әнигә хат яздым. Ул исән булса, бу көнне минем өчен бик борчылган булыр иде... Төне буе йокламас иде... Шалтыратыр иде... Ул хатлар чиста пөхтә итеп язылмый, билгеле. Алар барысы да күз яше белән юылган. Хәзер кайбер урыннарын укый да алмыйм, язуын да танымыйм... Күңел халәтем нинди – хатларым да шундый. Аларда минем борчуларым, шик-шөбһәләрем. Егерме сәгать буе минем белән нәрсә булды, барысын да яздым: «Әнием, мин таба алырмын микән? Әнием, мин синең кебек әни була алырмын микән?.. Әнием, минем хәлем бетте... Әнием, минем температурам күтәрелде... Әнием, миңа нindидер укол кададылар, нәрсә икәнен беләсеңдер...» Табиблар, килеп, баланы ярып алырга киңәш итәләр, әмма ризалашмыйм. Ахырда бүлек мөдире иртән керде дә: «Заключение ясап, ризалыгыңнан башка, тугызларда операциягә алып кереп китәбез», – диде. Иртәнге сигезләр иде ул. «Әнием, тусын инде, минем үземнең табасым килә бит», дип кабат әнигә хат язам. Нәкъ ярты сәгатьтән Данияр туа башлады. Әнием ярдәм иттеме, белмим... Тулгак вакытларында әнигә хат язып, үземә җиңеллек эзләдемме, онытыласым килдеме?!. Андый вакытларда әни белән сөйләшсәң, бәлки, чынлап та җиңел булып китә торгандыр. Мин бит белмим... Әни исән булса, мин, тәгаен, әнигә шалтыраткан булыр идем... Югыйсә ирем дә, кайнанам да, абыемның хатыны да гел хәлемне белешеп язып тордылар. Әмма барыбер әни җитмәде...

Әйткәнемчә, гаиләм белән авылга кайтып йөрим. Кәефем юклыгын күрсә, Илназ: «Әйдә, Актанышка», – ди. Анда кайтканда шатланганымны күреп, үзе дә шатлана бугай. Авылдан киткәндә зиратка керергә тырышам. Әни кабере янында сөйләшеп торучылардан түгелмен. Миңа анда бик авыр. Кайтып хат язсам, җиңелрәк. Кайтканда зиратка тукталабыз икән, ул авыр халәттән озак чыга алмыйм. Фиразия апа никадәр генә кәефемне күтәрергә теләсә дә, миңа рәхәт түгел. Соңгы кайтканда Данияарны да зиратка алып бардык. «Менә монда синең әбиең ята. Безгә ул күктән карап тора. Ул – фәрештә. Син үскәч, аны сорашырсың», – дип, Илназның Даниярга сөйләвен ишетеп, дулкынлануымнан егылып китә яздым. Илназда әниемә карата җылылык тоям, һәрвакыт аның турында сораша ул. Авылга кайткач, «Әби янына кереп чыгыйк», – дип әйтми калмый... Әни турында елый-елый сөйли алган бердәнбер кешем ул минем. Һәм хатларым... Алар бары минеке генә. Бәлки, киләчәктә кызыма укытырмын дип уйлый идем. Хәзер Даниярга карыйм да аңлыйм: укытмыйм. Анда сагыну гына түгел, үпкәләүләр дә, ачынулар да, гаепләүләр дә күп... Әнинең бездән китүе гаделсезлек бит. Аның үләргә хакы булмаган... Әмма язмышыңа язылган булса, минем үләргә хакым юк дип кенә яшәп булмаганын хәзер үзем әни булгач кына аңладым. Гомумән, хәзер әни миңа ныграк та җитми. Миңа кирәк ул, Даниярга кирәк ул... Әниләре үлеп киткәннәрне бик жәллим. Әнисез булырга мин ияләшкән инде, ана назын күреп үскәннәргә әниләрен югалту тагын да авырраktыр... Алар әниле булуның рәхәтен белә. Ә мин күз алдына да китерә алмыйм. Әни дигәндә күңелдә – бушлык... Әни кем ул?.. Рәхәт кешедер ул. Тикмәгә генә, хат язгач, миңа рәхәт булып китмидер.

Минем иң яратмаган һәм иң курыккан аем – март ае. Әни 8 Март төнендә үлгән. Гадәттә, ул көннәрдә озын яллар була. Бөтен ил бәйрәм итә. Ә минем өчен ул көннәр бик озак үтә. Күңелсез, ямьсез көннәр. 8 Март бәйрәмен дә яратмыйм. Мине бары Фиразия апа гына аңлыйдыр. Ул шалтыратмый калмый. Аның янына кайтсам, тагын да авыр буласын беләм, шуңа кайтмыйм. Узган ел ирем дә эштә булды. Берүзем өйдә яттым. Быел инде Даниярым бар. Җиңелрәк булыр дип уйлыйм... Бик яратам баламны. Көн саен Ходайдан баламны үзем тәрбияләп үстерергә язсын дип сорыйм. Бала өчен моның иң зур бәхет икәнен мин беләм...





Фото: www.pixabay.com



Сорауларга акушер-гинеколог Фирдәвес ГАЯЗОВА җавап бирә

Ике тапкыр авырым төште. Мин хәзер тагын йөкле. Алдагылары 11–12 нче атнада уза торган УЗИдан соң төшкән иде. Шуңа күрә хәзер хатын-кызлар консультациясенә исәпкә басарга да куркам. Мине тагын УЗИга җибәрәчәкләр. Аннан соң тагын баламны югалтырга куркам. Әлеге УЗИны узу мәҗбүриме?

Сезгә кичекмәстән йөклелекнең 12 нче атнасына кадәр хатын-кызлар консультациясенә исәпкә басарга һәм скрининг узарга кирәк. Скринингның максаты – алдагы срокларда ук карындагы баланың үсешен бәяләү, тайпылышларны билгеләү. Шул исәптән, Даун синдромы, нерв трубкасы үсеше зәгыйфьлеге, «куян ирене», «бүре авызы» һәм башка тайпылышлар. Скрининг баланың норма буенча үсүен, сәламәт булуын, порокларны вакытында билгеләргә ярдәм итә.

11–12 нче атнада УЗИ тикшерүе һәм биохимик скрининг узалар. Йөклелекнең бу чорында балада барлык органнар һәм системалар формалаша, җенесе билгеле була, йөз чалымнары барлыкка килә. Шуңа күрә әлеге скринингны һичшиксез узарга һәм тумыштан булырга мөмкин зәгыйфьлекләрне, генетик тайпылышларны тикшерергә кирәк. Бала күтәрә алмаучы хатын-кызлар өчен бу аеруча мөһим. Чөнки моның сәбәбе нәкъ менә генетика белән бәйле булырга мөмкин. Ә биохимик скрининг ярдәмендә хромосома аномалияләре билгеләнә. Шуның өчен кичекмәстән исәпкә басуыгыз таләп ителә.

«Партнер белән бала табу» программасы белән кызыксынабыз. Көтеп алган беренче балабызны ирем белән икебез бергә каршы аласы, бу юлны бергә үтәсе килә. Ләкин хәзер ковид белән бәйле чикләүләр аркасында бу мөмкин түгел, диләр. Бала өчен куркынычы бармы моның? Туганнан соң ул барыбер әтисе белән дә контактка керәчәк бит.

Коронавирус инфекциясенә ике тәүлектән дә артмаган тискәре тесты булган йөкле хатын-кызларга һәм аларның ирләренә бергә бала табу рөхсәт ителә. Ләкин, барлык чикләүләргә дә карамастан, коронавирус йоктыру куркынычы барыбер саклана. Бала табучы хатын-кыз да, туачак бала да – куркыныч астында.

Партнер белән бала табу – шулкадәр шәхси һәм психологик яктан катлаулы процесс, моны карап торган ирләр аны күтәрә алмаска мөмкин. Аның хәле авыраеп китсә, медперсонал бала табучы хатын-кызга бирәсе игътибарын иргә күчерергә мәҗбүр була. Ирләрдә негатив истәлекләр дә калырга мөмкин. Ә болар киләчәктә гаилә тормышын боза, шәхси мөнәсәбәтләрдә киртә дә була ала бит. Акушер-гинеколог буларак, партнер белән бала табуга пандемия чорында гына түгел, гомумән, катгый каршы мин.

Мин – йөклелекнең 16 нчы атнасында. Ирем еш кына тәмәке тарта, ә мин аның исен бик авыр кичерәм. Аеруча хәзер. Ләкин ул тартуын ташлый алмый. Минем башым әйләнә, күңелем болгана башлый. Бу халәтем балага да күчәме? Аңа куркыныч яныймы?

Тәмәке тартучы янында басып торган кеше төтен компонентларының 80 процентын сулый. Аның зыянлы токсиннары организмга 5 секунд эчендә йогынты ясый башлый. Әлеге төтен бала табу яшендәге йөклелек чорын узучы хатын-кызларга аеруча зыянлы. Никотин сулау нәтиҗәсендә плацентада кан йөреше бозыла. Бу – кан китүгә, плацента аерылуга сәбәп була ала, бала гомеренә куркыныч яный. Никотин тәэсирендә балага кислород җитмәү дә күзәтелә.

Тәмәке исе бала тапкан хатын-кызның баш миенә зыян китерә, сөте кимүгә сәбәп була. Алай гына да түгел, токсиннар сөт белән бергә балага да күчә. Аның баш миенә дә зыян килә. Андый балалар киләчәктә начар укый, үз-үзләрен тотышы үзгәрә, иммунитеты да төшәргә мөмкин. Туачак баланың бала табу мөмкинлегенә дә зыян килүе ихтимал. Шуңа күрә бала көтү чорында ирегезгә тәмәке тартуны ташлар өчен иң кулай вакыт. Балагызны сәламәт тормыштан мәхрүм итмәгез.

Кадерле әниләр!
«Яшь әни» рубрикасына сездән сораулар кабул итәбез.
Җавап бирүче белгечләр: педиатр, гинеколог, стоматолог, невролог, хирург-ортопед, кардиолог, иммунолог-аллерголог, гастроэнтеролог, эндокринолог, офтальмолог һәм башкалар.

Балаларга кагылышлы сорауларыгызны – 8 (843) 2-22-09-77 телефоны аша, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт адресы буенча яисә ssuum@yandex.ru электрон адресына «Сорау–җавап» дип язып җибәрә аласыз.



Сорауларга педиатр Гөлнара ЗЫЯТДИНОВА җавап бирә

Улыбыз бер ел эчендә ике тапкыр бронхит, бер тапкыр пневмония белән авырды. Барысы да ОРВИдан соң өзлегү нәтиҗәсендә булды. Хәзер ул авырый башлауга, тизрәк антибиотик бирергә тырышам, аздырудан куркам. Алай эшләү дөресме?

Дөрес шикләнәсез, әмма болай эшләү дөрес түгел. Антибиотикны бары тик табиб кына билгели. Авыртуның ничек баруын, аның клиникасын күздә тотып, әлбәттә. Үз белдеклегегез белән антибактериаль препаратлар билгеләү тыела.

Бер атна элек бала табу йортыннан чыктык. Мин кызымны юындырырга куркам. Ванна бүлмәсендә барыбер салкынча, салкын тидереп авыруы бар бит. Шуңа күрә җылы суда чылатылган сөлге белән генә сөртәм. Баланы көн саен юындыру кирәкме? Алай салкын тидереп авыру куркынычы зуррак бит.

Бала юындыруны кайвакыт җылы суда чылаткан сөлге белән сөртеп алуга алыштырып була. Тик шулай да ике-өч көнгә бер тапкыр баланы тиешенчә юындырырга, ваннада коендырырга кирәк. Балагызны барлык таләпләргә туры китереп, тиешле температураны саклап юындырсагыз, салкын тию куркынычы бик түбән.

Кызыбызга 4 яшь. Ничек кенә оялса да, әле дә имезлектән баш тарта алмый. Еш булмаса да, балалар бакчасыннан кайткач та сорап ала, йоклаганда да суырып йоклап китә. Моның өчен борчылу урынлымы?

Балага зыян килмәслек итеп имезлектән акрын гына баш тартырга кирәк. Чөнки бу яшьтә имезлек суырган баланың тешләмә формалашуга зыян килергә мөмкин. Соңрак аерым авазларны әйтүдә, сөйләшүендә проблемалар туачак.

Нәниләргә күчтәнәч!

Телефон камерасын QR-кодка якынайтып, аудиоформатта язылган әкиятне балагызга тыңлатыгыз.



ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

СОРАУ–ҖАВАП

МУСКУЛЛАР БАРЫСЫН ДА СӨЙЛИ



Соңгы вакытларда сәламәтлек торышын төрлечә диагностикалау ысуллары популярлаша башлады. Шуларның берсе – кинезиология. Ул – альтернатив медицинаның бер төре. Кинезиолог мускул тукымаларын тикшерә. Ягъни аларны өйрәнеп, сәламәтлекне һәм акыл эшчәнлеген тәртипкә сала. Кинезиологияне хәрәкәт турындагы фән дип тә әйтәләр. Бу хакта тренер-кинезиолог Эльза ТИМУРШИНА белән тулырак сөйләштек.

Кинезиологиянең асылы нәрсәдә?

Кинезиология– беренче чиратта бөтен организмны диагностикалау ул. Әлеге фән организмны тулы бербөтен система итеп карый. Кинезиолог сеңер-мускуллар рефлексына тест үткәрә. Шул рәвешле авыртуның беренче сәбәпләрен таба. Мәсәлән, кеше депрессиядән интегә. Психотерапевтта дәвалану нәтиҗә бирми. Ә төп сәбәп эчәклек ялкынсынуда булырга мөмкин. Бу исә кәефкә тәэсир итә. (Серотонин – шатлык гормонының 90 проценты эчәклектә ясала.) Авыруның беренчел сәбәбен тапмый торып, авыруны дәвалап булмый, ә бары тик билгеләрен генә бетереп була.

Сеңер-мускуллар рефлексларына тест ничек уза?

Кинезиолог тәндәге төрле нокталарга басып, мускуллар көче үзгәрешенә карап, организмның хәлен ачыклый. Мускуллар кысылган яки тонуслары бик түбән икән, димәк, тәннең әлеге өлешендә проблема бар. Мускуллар кеше тәнендәге үзгәрешләргә беренчеләрдән булып реакция ясый. Шуңа күрә кинезиолог әлеге инструментны камил белергә тиеш. Һәр мускул аерым бер орган, умыртка баганасы сөяге, эмоция, рефлекс белән бәйле. Аерым бер мускулга тест үткәреп, авыруны китереп чыгарган сәбәпне табып була. Шулай ук белгеч пациентның утыруына, басып торуына, хәрәкәт итүенә карап та, кайсы орган эшчәнлеге бозылганын әйтә ала.

Мануаль терапиядән ул нәрсә белән аерыла?

Мануаль терапевт терәк-хәрәкәт аппаратын карый һәм тән белән генә эшли. Ә кинезиология «сәламәтлек өчпочмагы»на нигезләнә. Ягъни биохимия, структура һәм эмоцияләрне карый. Биохимия – тәндәге химик реакцияләр, структура – мускуллар, эмоция – кешенең кәефен үзгәртә алучы зур көч.

Кинезиологка кемнәргә барырга ярамый?

Сеңер-мускуллар рефлексларына тест үтү өчен ярамый дигән күрсәтмәләр юк. Дәвалау вакытында кулланган алымнар (төрле күнегүләр) гына бар кешегә дә ярамаска мөмкин. Кинезиологтагы бар үткәрелгән процедуралар тормыш өчен куркынычсыз.

Кинезиолог авыруны дәвалыймы?

Кинезиолог дәваламый, ә бәлки организм үз-үзен тернәкләндерсен өчен ресурс бирә. Белгеч мануаль техникалар, остеопатик, психокоррекцион, физик күнегүләр куллана.

Кинезиологка нинди проблемалар белән мөрәҗәгать итәләр?

Беренче чиратта, терәк-хәрәкәт аппаратындагы авырту синдромнары белән. Шулай ук кул чукларын көзән җыерудан, умыртка баганасы кәкрәюдән дәва эзләп киләләр. Кинезиолог тест ярдәмендә организмда паразитлар, вируслар булу-булмавын, нинди продуктка аллергия барлыгын ачыклый. Шулай ук матдәләр алмашын, баш авыртуларны, йокысызлыкны, кан басымын да җайлый. Ләкин бу бер килүдә генә дәваланып кайтып китү дигән сүз түгел.

Кинезиолог нинди органнар белән эшли?

Нигездә, сөяк-мускул системасы йә терәк-хәрәкәт аппараты белән. Шулай ук эчке органнар, аерым алганда, ашказаны-эчәк тракты белән.



БАЛЛЫ МАССАЖ

Балны еш кына сыек алтын, диләр. Аның белән косметологик процедуралар уздыру үзе бер сихәт. «Тоз»ларны чыгару өчен бал кулланып, аркага массаж ясау турында беләсездер инде. Биткә дә массаж ясыйлар. Ул тирене сәламәтләндерә: тукландыра, дымландыра, пилинг та ясый. Аннан соң бит бала тиресе кебек – бәрхет сыман була. «Моңа өстәп, бал лифтинг-эффект та бирә. Составында булган микроэлементлардан бит тиресе яшәреп китә, җыерчыклар тигезләнә», – ди массажист Ләйсән САБИТОВА. Әлеге массажны мунчага йә душка керер алдыннан атнага бер генә тапкыр ясарга кирәк. Биттә бетчә, купероз (вак кан тамырлары күренеп тору) бар икән, ул урыннарга массаж ясарга ярамый. Шулай ук балга аллергия күзәтелгән кешеләргә сак булырга киңәш ителә. Кул астында булган «алтын» белән битегезгә массаж ясап, үзегезне Клеопатра кебек хис итегез әле.



Һәрвакыттагыча, биткә массаж күкрәк өслегеннән башлана. Җылы бал ягылган кулларны сак кына күкрәктән кырыйга таба «ябыштырып» тартабыз. Шул ук хәрәкәтне муен тирәләрендә дә кабатлыйбыз.

Муенда тирән җыерчыклар булса, аны имән һәм урта бармаклар ярдәмендә аерып, икенче кулның имән бармагы белән баскалап чыгабыз. Баллы бармакны тиредән аерганда, ул, ябышып калып, тартыла. Менә шул лифтинг эффект бирә дә инде.

Ияк астын кул йөзләре белән кырыйга «тарттырабыз». Икенче ияге булган кешеләргә бу массаж хәрәкәте бигрәк тә файдалы. Ияккә әле бер кулның ике бармагы, әле икенче кул бармаклары белән «плюс ясыйбыз».

Олыгая барган саен, ирен тирәсендә вак җыерчыклар барлыкка килә. Аларны да массажлыйбыз. Бер кулның ике бармагы белән тотып, икенче кул бармагы белән баскалап барабыз. Шундый ук массаж хәрәкәтен борын тирәләрендә дә кабатлыйбыз.

Борын яныннан имән бармаклар белән, биткә тидерә-тидерә, диагональ буенча өскә йөртеп чыгабыз. Бал белән массаж ясаганда бервакытта да хәрәкәтләр аска таба булмасын. Һәм алар бик сак кына эшләнергә тиеш. Бит ул арка түгел!

Ике каш арасындагы җыерчыкка да игътибар итәргә онытмагыз. Аны да ике бармак белән аерып, сак кына баскалагыз, йә «плюс» хәрәкәте ясагыз. Даими эшләгәндә җыерчык тигезләнә төшә. Маңгайдагы горизонталь җыерчыкларны да ике бармак белән аерып, баллы бармак очлары белән йөртеп чыгыгыз.

Ике кулны да биткә куеп, бармак очларын аермыйча гына өскә таба «тарттырып», лифтинг күнегү эшлибез. Куллар турында да онытмыйбыз. Биткә массаж ясаганнан соң, калган бал белән кул йөзләрен дә сак кына «тарттырып» алабыз.

QR-код аша кереп, массажны видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



Ит рулеты



Февраль ае карлы бураннары, яз килүне искәртүче беренче ягымлы кояшы белән генә түгел, бәйрәмнәре белән дә аерылып тора. Ватанны саклаучылар көне – яклаучыларыбыз, терәгебез, өметебез булган ирләребезнең, әти-улларыбызның күңелләрен күрер өчен тагын бер уңайлы форсат. Алар күңеленә юлның кайдан ятканын беләбез ләбаса! «Бәйрәм табынына итле рулетлар ясап сыйласагыз, оттырмассыз», – ди Венера АРСЛАНОВА. Венераның сүзләренә колак салмый мөмкин түгел. Итле ризыклар гына түгел, чын ир-егетләр үстерү «рецепт»ын да яхшы белә ул. Венераның олы улы Рамил Санкт-Петербург шәһәрендә Александр Можайский исемендәге хәрби-космик академиясендә укый, тормышын хәрби хезмәт белән бәйләргә тели. 11 нче сыйныфта укучы энесе Ранель дә абыйсы янына китәргә әзерләнә. Рецептны саклап куегыз да, безнең белән бергә пешерегез. 23 февральдә никадәр тәмлерәк ризык әзерләсәң, 8 Мартны шулкадәр күңеллерәк уздырырсың, ди шаян халык сынамышлары!





Кирәк 1 рулет өчен уртача 1 тозлы кыяр / 1 чәй кашыгы горчица / 1 чәй кашыгы бал / 1 аш кашыгы соя соусы / тоз, борыч.

1 кг ит булса, аннан 6-7 рулет чыга. Ингредиентларны да шул исәптән салабыз, ягъни 6-7 гә тапкырлыйбыз.








Эш барышы

■ Итне 150 граммлы кисәкләргә бүлеп, ике ягын да яхшылап тапалыйбыз.

■ Горчица, бал, соя соусын бергә кушып, маринад ясыйбыз. Тәменчә тоз, борыч өстибез.

■ Тапаланган ит кисәкләрен маринадка салып, 10–15 минут тотабыз.

■ Итне маринадтан алабыз. Тозлы кыярны урталай кисеп, ит эченә куеп, төрәбез.

■ Рулетларны төрелгән ягы белән майлы табага тезәбез. Шулай эшләгәндә алар ачылып китми.

■ Рулетларны 180 градуслы мичтә 40 минут пешерәбез.

■ Пешкәндә рулетларның шулпасы бүленеп чыга. Табынга биргәндә рулетны кискәләп, өстенә шул шулпаны сибеп бирәбез. Яшелчә белән бизибез.

Ашларыгыз тәмле булсын!









Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.

Өйнең яме – гөлләрдә


Спатифиллум

«Хатын-кыз бәхете» дип аталган гөлнең чын исеме – **спатифиллум**. Үсемлекнең энергетикасына кагылышлы төрле фикерләр яши. Кемдер аны бәхет китерә дип саный, кемдер, киресенчә – ир-атны өйдән куа, ди. Спатифиллум белән янәшә антуриум – «ир-ат бәхете» гөлен утыртсаң, гаиләдә гармония була дигән ышану да бар.

Дөрес тәрбияләгәндә спатифиллум 2,5 айга кадәр чәчәк ата. Җылы ярата. Һава температурасы 18–25 градустан ким булмаганда гына яхшы үсә. Дымлылык югары булганда эссерәк температурага да түзә ала.

Спатифиллумның дымлылыкка да таләбе зур. Су бөркеп торганны ярата, бигрәк тә җәй көннәрендә.

Яктылыкка килгәндә, монда да бәхәсләр бар. Туры кояш нурларыннан зыян күрә – ялтыравык яфракларын пешерә, аларда көрән төстәге таплар барлыкка килә. Спатифиллум караңгырак почмакта – ясалма яктылыкта да бик яхшы үсә.

Бу гөлгә су – даими, ләкин туфракны артык чылатмый гына сибелә. Корылыкка бик сизгер, яфракларын бик тиз салындыра. Су сипкәннән соң, кабат үз халәтенә кайтса да, соңыннан, саргаеп, корый башлый.

Яшь үсемлекне – ел саен, картракларын өч-биш елга бер тапкыр күчерергә кирәк. Тик үсемлек артык үсеп, чүлмәге тарайса, моны иртәрәк тә эшләргә ярый. Чүлмәкнең исә алдагысына караганда, артык зурын алмагыз. Тамырлары чүлмәккә тарәлми торып, гөл чәчәк атмаячак.

Чәчәк атып бетергән сабакны төбеннән киссәң, үсемлек кабат чәчәк сабагы чыгара башлый. Шулай итеп аны даими чәчәк аттырырга була.

Спатифиллумны тамырдан бүлеп үрчетәләр.


Гөлләр үстерү турында тулырак.

Сансевиерия – сабаксыз мәңге яшел үсемлек. Халык телендә аны «Чуртан койрыгы» дип тә йөртәләр.

«Чуртан койрыгы» шактый коры һавада да үзен яхшы хис итә. Яктылыкка да артык мохтаҗлыгы юк. Ләкин чуар төренең яктылык туры төшмәгән очракта яфракларының төсе җетерәк, матуррак була. Ә менә яшел яфраклысы хәтта бүлмә почмагында да үсә ала. Шуңа күрә үсүе тукталмасын дисәгез, елга ике-өч тапкыр яктырак урынга күчереп куярга кирәк.

Сансевериягә су күп кирәкми, корылыкны яратарак та төшә әле. Суны туфрагы кипкәннән-кипкәнгә генә сибеп торыгыз. Җәйге ялларга киткәндә, бу гөлегез өчен борчыласыгыз юк. Бары тик көнозын кояш карый торган тәрәзә төбендә генә калдырмагыз.

Аның өчен иң кулай температура – 16–25 градус җылылык.

Сансевиерияне ике-өч елга бер тапкыр көпшәк һәм уңдырышлы туфракка күчереп утыртталар. Кактуслар өчен ярашлы туфрак аңа туры килә. Чүлмәк сайлаганда тирәнен түгел, киңен алыгыз.

Бу гөлне кыскартып кисәсе юк, карт, зәгыйфь яфракларын төптән кисеп кенә чистартып торырга кирәк.

«Чуртан койрыгы» чәчәк та ата. Артык купшы булмасалар да, хуш ислеләр. Чәчәк аттыру өчен, гөлне салкынча урынга куеп, су сибүне туктатып торалар. Бер ай шулай ял иттергәннән соң, кабат җылыга күчереп, су сибүне дәвам итәләр.

Сансевиерияне тамырчаларын бүлеп тә, яфрагыннан тамырландырып та үрчетергә мөмкин.


Сансевиерия


Миләүшә

Миләүшә чәчәгенең биологик атамасы – сенполия. «Узамбар фиалка»сы дип тә йөртәләр. Әлеге гөл өч-дүрт ел гына яши, аннары үзенең декоративлыгын югалта.

Яктылык җитәрлек булса, ел дәвамында чәчәк ата. Ләкин бу режим аны бик нык көчсезләндерә. Шуның өчен миләүшәләрне елга бер тапкыр ике айга караңгырак урынга куеп, ял иттереп алырга кирәк.

Сенполия җылы ярата. Ачык һавада үсми. Яфракларына су тидергәнне яратмый. Шуның өчен бу гөлләргә су бөркергә яки душта коендырырга ярамый, чери башлыйлар. Дымлылыкны саклау өчен, янына сулы савыт яки дымлы мүк куярга була.

Яктылыкны ятратса да, көньякка караган тәрәзә төбендә яфраклары бөгелеп килүчән. Ул көнчыгышка яки көнбатышка караган якта яхшы үсә. Күләгәне дә җиңел кичерә, хәтта төньякка караган тәрәзә төбендә дә чәчәк ата ала. Чәчәк бөреләре аз ярälса, яфрак сабаклары сузылса, ясалма яктылык бирергә мөмкин.

Сенполия кечкенә чүлмәкләрне үз итә, зур савытта артык тамыр биреп, чәчәк атудан туктый. Елга бер тапкыр туфрагын алыштырып торырга кирәк. Күчереп утыртуны март, апрельдән дә соңга калдырмасаң яхшы.

Миләүшәләрне кисеп торасы юк, корыган, сынган, көйгән яфракларыннан гына арындырасы.

Суны туфрак өсте кипкәннән соң гына сибәләр. Чүлмәк төбенә су җыелып утырырлык булмаска тиеш.

Миләүшәләрне артык ашлау белән мавыгырга ярамый, бигрәк тә азотлы ашламалар белән. Кышын тукландыруга ул бөтенләй мохтаҗ түгел.

Сенполияне яфрагын тамырландырып кына да үрчетергә мөмкин.

Фото: www.pixabay.com

тест: Үзегезгә ышанасызмы?

Сез үз-үзегезгә ышанасызмы, әллә ышанучан булып тоеласыз гынамы? Бу тест шуны күрсәтер. Сорауларга җавап сайлагыз.

1. Сезгә нинди кул кысышу ошый?
а) тиз, ләкин нык;
б) озак һәм көчле;
в) җиңелчә кагылып китү.

2. Сезнең йолдызлык?
а) Арыслан, Кучкар, Кәҗәмөгез, Үгезбозау;
б) Игезәкләр, Чаян, Сукояр, Укчы;
в) Балык, Кысла, Сөмбелә, Бизмән.

3. Сезнең тәнегез нинди?
а) махсус карау таләп итми торган;
б) сизгер түгел;
в) коры һәм сизгер.

4. Парктагы эскәмиядә үз уйларына бирелеп бер хатын утыра, ди. Аның турында ни уйлыйсыз?
а) ялгызы рәхәтләнеп утыра;
б) үзен кызгануларын тели;
в) ниндидер проблемалары бар.

5. Сезгә нәрсә хас?
а) күңелсезлекләрне, борчуларны тиз онытасыз;
б) үзегез турында гына уйламыйсыз;
в) кемнедер алдасагыз, вөҗдан газабы кичерәсез.

6. Сезгә нинди фигура ошый?
а) өчпочмак;
б) ромб;
в) түгәрәк.

7. Кайсы спорт төре белән шөгыльләнер идегез?
а) парашют спорты;
б) суга сикерү;
в) альпинизм.

Кайсы хәрефкә җавапларыгыз күбрәк булуын санагыз.

Күбесенчә «а» вариантын сайлаган булсагыз: сез үз-үзегезгә ышанучан кеше, ләкин һәрвакыт алай түгел. Шулай да бу турыда курыкмыйча әйтә аласыз, чөнки сез көчле. Теләгәнегезгә ирешү өчен сездән артык күп көч таләп ителми.

Күбесенчә «б» вариантын сайлаган булсагыз: үз-үзегезгә ышанычыгыз тотрыклы түгел. Тәҗрибәгез булган очракларда холкыгызның бу ягы кыенлык тудырмас. Ләкин таныш булмаган ситуацияләрдә куркуга бирелеп югалып калырга мөмкинсез. Нәтиҗәдә йә үз эчегезгә йомыласыз, йә үзегезгә чамадан тыш ышана башлыйсыз.

Күбесенчә «в» вариантын сайлаган булсагыз: үзегезне уңай бәяләү җитми. Бәлки, башкаларга ышанмыйсыздыр. Еш кына үткәннәр өчен үкенеп, үзегезне битәрлисез һәм тормыш тәмен тоймый каласыз. Үз-үзегезгә ышанмауның сәбәбен ачыкларга тырышыгыз. Җавапны таба алмасагыз, белгечкә мөрәҗәгать итегез.

йолдызнамә март

Кучкар. Кызыклы һәм вакыйгаларга бай ай көтә сезне. Бер чеметем генә интрига да килеп кушылырга мөмкин. Тылларыгызны ныгытсагыз, якыннарыгызга игътибарлырак булсагыз, бар да сезнең файдага тәмамланыр.

Үгезбозау. Март сезнең өчен каршылыклар ае булырга тора. Йә кара сызык, йә ак... Ләкин сез аларны оста гына ерып чыгарга сәләтле. Яхшы шансларны уңышсызларыннан тиз аерып алырсыз. Сәламәтлек тә какшатып җәфаламас бу чорда.

Игезәкләр. Шәхси үсешегез өстендә эшләргә, үзегездә яңа сәләтләр ачарга теләсәгез, шик-шөбһәләр һәм курку турында онытырга туры килер. Бу айда яңа дуслар, яңа элемтәләр булдыру белән дә мәш килерсез, аларның файдасын күрерсез.

Кысла. Март сезнең өчен кискен үзгәрешләр алып киләчәк, мөмкинлекне кулдан ычкындырмагыз. Хәлиткеч карарлар кабул итәр өчен бик кулай чор. Тормыш, бәлки, сезне уникаль кешеләр белән очраштырыр. Алар янында үзегезне башка яктан ачарсыз.

Арыслан. Хәзер сезгә компромисска барырга кирәк. Якын киләчәктә бу адымыгызның әҗерен күрерсез. Шушы чорда әҗәтләрдән котылырга мөмкинлек тә туачак. Төрле чараларда катнашудан баш тартмагыз, анда сезне яңа мөмкинлекләр көтә.

Сөмбелә. Танышулар, очрашулар, аралашулар күп булыр мартта. Бу ай эшлекле һәм шәхси мөнәсәбәтләр булдырыр өчен кулай. Киңәш сорап мөрәҗәгать итүчеләр дә булмый калмас. Ай уртасында әҗәткә акча биреп торудан тыелыгыз.

Бизмән. Бу айдагы вак-төяк эшләрегез киләчәктә шактый уңышлы проектка йә карьера үсешенә трамплин булырга мөмкин. Шулай да әлеге чор җиңел була дип көтмәгез, киртәләргә әзер торыгыз. Сезнең бер дигән гаиләгез, таянычыгыз бар, алар белән бер дулкында булсагыз, кайда да уңыш көтәр.

Чаян. Сез хәзер игътибарга, танылуга мохтаҗ. Шуңа күрә төрле чараларга, кеше күп булган урыннарга йөрергә тырышыгыз, анда игътибар үзегездә булырсыз. Ә үз-үзенә ышанган Чаян олы максатлар куеп, аларны кыю рәвештә тормышка ашырырга сәләтле.

Укчы. Айның беренче яртысы сезнең өчен аеруча уңышлы булыр. Шулай да тынгысыз Укчыларга бу чорда артыгын мавыкмау хәерле. Көчегезне һәм игътибарыгызны яхшылап план коруга юнәлтегез, көндәлек мәшәкатьләрне тәртипкә салыгыз.

Кәҗәмөгез. Стандарт булмаган фикер йөртү һәм мәсьәләне тиз хәл итә белү сәләтегез бу айда төп ярдәмчегез булыр. Шушы сыйфатларыгыз аркасында хөрмәт казанырсыз, мактау сүзләре ишетерсез. Һәр башлангычыгыз уңышлы тәмамланыр.

Сукояр. Ныклыкка сынау узарга туры килүе ихтимал. Ләкин аларның берсе дә алга баруыгызга комачауламас, тынычлыгыгызны бозмас. Иң мөһиме – күпне вәгъдә итмәгез, күбрәк эшләргә тырышыгыз.

Балык. Айның беренче яртысында ишелеп төшкән мөмкинлекләрдән файдаланып калырга ашыгыгыз. Мондый чор сирәк була. Хәтта лотерея, бүләк уйнатуда ота аласыз. Сезнең белән аралашырга теләүчеләр күп булыр, барысына да ачылып бетмәгез.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.







КАЙНАР ЭМАЛЬДӘ – САЛКЫН КЫШ

Бу иҗат төренә ул күп еллардан соң гына килгән. Улы Чыңгыз, килене Анастасия белән бергәләп «Зөя эмале» иҗат артелен дә ачкан. Баштарак Бөгелмәдә, аннары Әлмәттә үскән ир бала рәсем ясауга хирыс булган. 1968 елны Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлаган. СССР Рәссамнар берлегенең уку-тәҗрибә студиясендә дә гыйлем туплаган. Аннары графика, китап бизәү, картиналар язу, спектакльләргә декорацияләр ясау һәм кинофильмнар төшерү белән шөгыльләнгән Рәшит Сафиуллин. 1974–1975 елларда Тукай-Кырлай мемориаль ансамбленең музей зонасы интерьеры дизайнын теләп башкарган. Мәскәүгә китеп, анда зур күләмле заказларга да алынган... Ә аннары янә Казанга кайтып, бераздан Зөядә төпләнгән. Хәтта Зөя музей-тыюлыгы яңартыла башлаганчы ук... Чөнки ул чактагы утрау тынлыгы бар игътибарын җыеп, җитди, катлаулы иҗатка уңай тәэсир итәр дип тапкан, һәм кайнар эмаль ысулындагы яңа төр картиналарын, миниатюраларын иҗат итә башлаган.


«Иҗат эшләребез бакыр пластиналарда, төелгән пыяла оны белән ясала. Шуңа әлеге катлаулы иҗади процесста пейзажлар һәм абстракцияләр ешрак тууга гаҗәпләнәсе түгел... Россиядә мондый төр иҗатка алынучылар саны, гомумән, аз, – ди Рәшит әфәнде. – Беренчедән, вакыт буенча озак ясалса, икенчедән, мавыктыргыч эш, көтелмәгән нәтиҗәләргә бай технология ул кайнар эмаль! Бер бик мөһим уңай ягы да бар: мондый зәвыклы әсәрләргә куллар белән кагылырга, аларны хәтта сыйпап алырга да мөмкин. Ә менә заказларга килгәндә, әсәр янә нәкъ шушылай кабатланачак дип бер генә оста-эмальер да вәгъдә итә алмый. Чөнки бу мөмкин түгел».

Артель иҗаты Зөягә килүче бихисап туристларга таныш. Өстәвенә, Рәшит әфәнде улы Чыңгыз белән берлектә биредә, Россиядәге бердәнбер музейны – «Татар бистәсе» археологик агач музеен ачуга да үз өлешен керткән. Таштай каты агач фрагментлары кояш нурлары белән җылытылган сыман күренсен өчен, яңа төр материал да уйлап тапкан алар. Талантлы татар рәссамы «XVII гасыр Зөясе» дип аталган үтә дә озын панно-реконструкция иҗат итеп тә мәшһүрлек казанган, чөнки әлеге паннода барлыгы... 450 дән артык персонаж сурәтләнгән!

Рәссамның кайнар эмаль ысуллы матур хезмәтләренең темаларын барласак, оста-эмальер күңелле язгы ярминкәләрне яратып тасвирлый. Күп кенә миниатюраларында туган як сулыклары, төнге күк йөзе, ваемсыз балачак темасы өстенлек итә. Болар барысы да – Рәшит Тәлгать улының үз балачагында тупланган хис-халәтләр коллекциясеннән. Рәшит Сафиуллинның күпсанлы үтә күренмәле әсәрләрендә – җете төсләр дә, төшләрдән кучкән образлар да, гади һәм гадәти тормышка омтылышлы сюжетлар да байтак... Рәссам-эмальер елның кыш фасылына үзенчә бер җылы мөнәсәбәттә. Кышларны сөюен гади итеп аңлата: «Чөнки кыш аклыгы – ул Яңа елны каршылау бәйрәме белән дә бәйле, ә Яңа еллар бар кешегә дә якты өметләр алып килә!»

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА







РӘШИТ САФИУЛЛИН



Тәртип

Казан 93,1 FM
Яр Чаллы 90,2 FM

Тәртипле халык югалмый!
Татар тәртипсез була алмый!

tartip.tatar
@tartip.tatar
tartip.tatar

iOS системалы смартфоннар өчен кушымта
App Store

Android системалы смартфоннар өчен кушымта
Google Play

Реклама 6+